Ниязетдин мулла Миңлеәхмәт әл-Хәнәфи

# Әбү Хәнифәнең **«әл-Фикһ әл-Әкбәр»** китабына кыскача аңлатма

Түбән Кама 2011

ББК 86.38
© Ниязетдин мулла Миңлеәхмәт әл-Хәнәфи
e-mail: mullaniyaz@mai.ru

Тикшерделәр: Булат хәзрәт Мөлек,
Хәйдәр хәзрәт Гата

بسم الله الرحمن الرحيم

# Кереш сүз

إِنَّ الْحَمْدَ للهِ نَحْمَدُهُ وَ نَسْتَعِينُهُ وَ نَسْتَغْفِرُهُ وَ نَعُوذُ بِاللهِ مِنْ شُرُورِ أَنْفُسِنَا وَ سَيِّئَاتِ أَعْمَالِنَا مَنْ يَهْدِهِ الله فَلا مُضِلَّ لَهُ وَ مَنْ يُضْلِلِ فَلاَ هَادِيَ لَهُ وَ أَشْهَدُ أَنْ لا إِلَهَ إِلاَّ الله وَحْدَهُ لا شَرِيكَ لَهُ وَ أَشْهَدُ أَنَّ مُحَمَّداً عَبْدُهُ وَ رَسُولُه، أَمَّا بَعْد...

Хакыйкатьтә, иң хәерле сүз — *Аллаһ* тәгаләнең сүзе, вә иң хәерле юл — пәйгамбәребезнең ﷺ юлы. Барча яңалык — бидгать, вә барча бидгать — адашу һәм барча адашу утка илтә.

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا اتَّقُوا اللَّهَ حَقَّ تُقَاتِهِ وَلا تَمُوتُنَّ إِلا وَأَنْتُمْ مُسْلِمُونَ

Мәгънәсе: **«Әй мөэминнәр! Аллаһка хак тәкъвалык белән тәкъваланыгыз. Аңа итагать итегез, каршылык вә гөнаһ кылмагыз. Аны зикер кылыгыз, вә онытмагыз. Аңа шөкер итегез һәм көферлек кылмагыз, Аның хөкемнәрен бозудан бик нык сакланыгыз һәм Коръән белән гамәл кылып, чын мөселман хәлегездә генә үлегез!».** [Әли-Гыймран: 102]

يَا أَيُّهَا النَّاسُ اتَّقُوا رَبَّكُمُ الَّذِي خَلَقَكُمْ مِنْ نَفْسٍ وَاحِدَةٍ وَخَلَقَ مِنْهَا زَوْجَهَا وَبَثَّ مِنْهُمَا رِجَالا كَثِيرًا وَنِسَاءً وَاتَّقُوا اللَّهَ الَّذِي تَسَاءَلُونَ بِهِ وَالأَرْحَامَ إِنَّ اللَّهَ كَانَ عَلَيْكُمْ رَقِيبًا

Мәгънәсе: **«Әй кешеләр! Сезне бер нәфестән (Адәмнән) халык кылучы Аллаһка тәкъва булыгыз! Ул (Аллаһ), Адәмнең عليه السلام үзеннән хатын (Хәваны) яратты, вә икесеннән күп ирләрне һәм күп хатыннарны дөньяга чәчте. Янә Аллаһка тәкъвалык кылыгыз, Ул — Аллаһ исеме белән бер–берегездән сорыйсыз, ягъни Аллаһ ризалыгы өчен бир, сүземне тыңла, дисез, һәм Аллаһ ризалыгы өчен**

**сорагач кешенең кире какмаганлыгын беләсез. Шулай булгач, Аллаһны зурлагыз вә якын туганлык җепләрен өзүдән сакланыгыз! Аллаһ бит сезнең барча эшләрегезне тикшереп күзәтүче».** [Нисә: 1]

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا اتَّقُوا اللَّهَ وَقُولُوا قَوْلاً سَدِيدًا ۞ يُصْلِحْ لَكُمْ أَعْمَالَكُمْ وَيَغْفِرْ لَكُمْ ذُنُوبَكُمْ وَمَنْ يُطِعِ اللَّهَ وَرَسُولَهُ فَقَدْ فَازَ فَوْزًا عَظِيمًا

Мәгънәсе: **«Әй мөэминнәр! Аллаһка тәкъва булыгыз, вә хак булган файдалы, дөрес сүзләрне генә сөйләгез! Аллаһ әйткәнчә эш кылсагыз, Аллаһ эшләрегезне вә гамәлләрегезне төзәтер, вә гөнаһларыгызны ярлыкар. Берәү чын күңелдән Аллаһка, вә Аның расүленә итагать итсә, ул кеше һичшиксез өстенлеккә вә изге теләгенә иреште».** [Әл-Әхзәб: 70-71]

Дөреслектә, Аллаһ тәгаләнең бу өммәткә иң хәерле китабын төшерүе, иң хәерле кешене пәйгамбәр итеп җибәрүе, аларның үзләрен кешелек дөньясына килгән иң хәерле өммәт итүе, һәм бу диннең ике асылы вә саф чыганагы булган Коръән белән Сөннәтне бозылулардан вә үзгәрешләрдән алар өчен саклауы — аларга карата булган иң зур нигъмәтләреннән булды.

Шуннан соң, сахәбәләрне, тәбигыйннәрне вә аларның иярченнәрен хаклыкта вә туры юлда кылып, әгъвадан[1] вә бозыклыктан ерак кылды. Аларның иң әүвәл фәһемнәре, Коръәнне һәм Сөннәтне аңлау вә шуларга нык итеп ябышу иде.

Шуннан соң, Аллаһ тәгалә һәрбер гасырда Коръәнгә вә Сөннәткә чакыручы һәм ширек вә мәҗүсилек нәҗесләреннән пакьләнергә, бидгать вә хорафат караңгылыгыннан яктылыкка чыгарга ярдәм итүче галимнәрне бар итте.

Әбү Хәнифә, Мәлик, Шәфигый һәм Әхмәдләр ошбулардан иделәр. Алар барысы да Коръәнгә һәм Сөннәткә то-

1 Коткы

тынуга кирәклектә вә бу ике асылга хыйлаф иткән барча карашны калдыруда бердәм караштa иделәр.

Имамыбыз Әбү Хәнифә рахимәһү Аллаһ бу хакта болай диде: ***«Әгәр дә хәдис дөрес икән, ул минем мәзһәбем»*[2].**

Шулай ук: ***«Мин кайдан алып әйткәнемне белмичә торып, бирәүгә дә минем китапларымнан фәтвә бирү дөрес булмаячак»*[3].**

## Имам Әбү Хәнифәнең тәрҗемәи хәле

**Исеме:** Нүгьмән бин Сәбит бин Зүтаий әл-Хаззәз әл-Күфий.

**Күньясе[4]:** Әбү Хәнифә.

**Тууы һәм ватаны:** Имам Әбү Хәнифә рахимәһү Аллаһ һиҗри тәкъүим буенча 80нче елны Күфә шәһәрендә, кече сахәбәләр исән вакытта, Габдулмәлик бин Мәрван хәлифлек чорында дөньга килә, һәм гомеренең беренче елларын да шунда уздыра. Күфәдәге «Гумәр бин Хүрайс» дигән урында аның ефәк тукымалар вә киемнәр сату кибете була. Сәүдәдә ул бик тә ышанычлы, беркайчан да ялганламый торган әмин кеше буларак шөһрәт казана. Тора-бара аның сәүдәсе зурая һәм үсә, хәтта ул үзенә тукымалар туку буенча, эшчеләр вә сатучылар белән бергә фабрика булдыра.

**Табигый сыйфатлары:** Имам Әбү Хәнифә рахимәһү Аллаһ матур сөйләүчән, оста телле, йөзгә каракучкылга авышрак, бик чибәр, матур-пакь киемнән һәм йортын-

---

2 Хәшияһ ибен Габидийн 1/159

3 Әл-Интика‘ (ибен Габдулбәрр), Мизән әл-Күбра (әш-Шәграний)

4 Ата-анага баланың исеме белән дәшү, мәсәлән, әгәр дә бирәүнең Габдуллаһ исемле баласы булса аңа «Әбү Габдуллаһ», ягъни «Габдуллаһның әтисе», — дип әйтү, һәм шулай ук хатын-кызга әйтелә.

нан чыкса үзе күренгәнче үк аның хушбуй исе ерактан үк сизелә торган искиткеч күркәм кеше иде.

Шәкерте Әбү Юсуф аны болай дип сыйфатлады: ***«Әбү Хәнифә озын буйлы да, кыска буйлы да түгел иде. Матур сөйләүчән, оста телле бик күркәм кеше иде»[5].***

Гомәр бин Хәммәд болай дип сыйфатлады: ***«Әбү Хәнифә озынчарак буйлы, каракучкылрак йөзле, матурпакь киемле һәм хушбуйны күп кулланучы кеше иде. Хәтта йортыннан чыкса, ул үзе күренгәнче аның хушбуе ерактан ук сизелә иде»[6].***

Шәкерте Габдуллаһ бин әл-Мөбәрак болай сыйфатлады: ***«Ул күркәм кыяфәтле, күркәм йөзле һәм күркәм киемле кеше иде»[7].***

Әбү Нәгыйм әл-Фадл әйтте: ***«Әбү Хәнифә күркәм йөзле, күркәм киемле һәм аңа очраган барча кешегә дә бик игелекле һәм мәрхәмәтле иде»[8].***

**Холкы:** Әбү Хәнифәнең ﵁ холкына килгәндә, ул Аллаһ тәгалә хәрам кылган нәрсәләрнең кечкенә ноктасы да үзенә эләгүдән бик тә нык курыккан тәкъва, диндар, заһид кеше иде. Аңа дөнья байлыгы, мал-мөлкәт бирелде, әмма аның моңа исе китмәде. Казыйлык вазыйфасын һәм дә бәйтүл-мал җаваплылыгын үз өстенә алмаганы өчен, камчы белән сuктырылды вә газапка тарттырылды.

Әс-Саймәрий Рабигъ бин Гасыймнан риваять кылып болай диде: ***«Мине Язид бин Гомәр бин Һүбәйра[9] Әбү Хәнифәне алып килергә җибәрде. Әбү Хәнифә килгәч, Язид аңа бәйтүл-мал җаваплылыгын үз өстенә алуын***

---

5 «Тарих Багдад» Әбү Бәкер әл-Багдадий

6 «Тарих Багдад» Әбү Бәкер әл-Багдадий

7 «Әхбәр Әби Хәнифә вә асхәбиһи» әс-Саймәрий

8 «Әхбәр Әби Хәнифә вә асхәбиһи» әс-Саймәрий

9 Әбү Халид Язид бин Гомәр бин Һүбәйра әл-Фәзәрий, әл-Үмәүия дәүләтендә вәли һәм әмир була. Әз-Зәһәбий аның хакында: «Кыю, батыр, яхшы сәясәтче, матур сөйләүче, оста телле вәгазьче иде», — дип әйтеп уза. Һиҗри тәкъүим буенча 132нче елны Сәффәх тарафыннан үтерелә.

***сорады. Имам Әгъзам Язиднең тәкъдимен инкяр иткәч, ул аңа егерме камчы суктырырга кушты»[10].***

Шулай ук, ибен Һүбәйра Гыйракның хөкемдары булып торган вакытта Әбү Хәнифәгә Күфә шәһәренең казые булырга куша, һәм: «Әгәр дә Әбү Хәнифә инкяр итсә, мин аның башына камчы белән суктырачакмын», — дип вәгъдә кыла.

Әбү Хәнифә казый булырга баш тарта, һәм йомышчыга: «Дөньяда булган суктыру җәзасы, миңа ахирәттәге тимер таяклардан күпкә җиңелрәк. Аллаһ белән ант итәм, ул мине үтерсә дә мин риза булмаячакмын», — дип җавап бирә.

Бу сүзләрне ибен Һүбәйрага ирештерәләр, ул Әбү Хәнифәне үзенә чакыртып: «Әгәр син ризалашмасаң, мин синең башыңа камчы белән суктырып үтерергә кушачакмын», — ди. Имам Әгъзам аңа: «Үлем бер генә була», – дип җавап бирә. Язид Әбү Хәнифәнең башына егерме таяк суктырта, имам Әгъзам аңа: «Үзеңнең Аллаһ каршында басып торачагыңны уйла, һәм мине куркытма! Хакыйкатьтә, мин: «Лә иләһә иллә Аллаһ», — дип әйтәм. Аллаһ тәгалә синнән минем хакымда сораячак, һәм Ул синең җавапларыңны иллә-мәгәр хаклык белән генә хөкем итеп кабул итәчәк!», — дип әйтә.

Бу сүзләрне ишеткәч ибен Һүбәйра җәлладка[11] Әбү Хәнифәне зинданга ябырга куша. Суктырудан имам хәзрәтләренең йөзе һәм башы шешеп чыга.

Бервакыт, ибен Һүбәйра үзенең ярдәмчеләренә төш күргән сөйли: «Мин төшемдә пәйгамбәребезне ﷺ күрдем. Ул миңа: «Минем өммәтемнән булган, бер җинаять тә эшләмәгән кешене син таяк суктырасыңмы, һәм аны куркытып яныйсыңмы әллә?!», дип әйтте, — диде».

Шуннан соң, ул имам Әбү Хәнифәне зинданнан чыгарып азат итә[12].

10 «Әхбәр Әби Хәнифә вә асхәбиһи» әс-Саймәрий

11 Газаплаучы

12 «Әхбәр Әби Хәнифә вә асхәбиһи» әс-Саймәрий

Шулай ук, Габбәсиләр дәүләтенең башлыгы әл-Мансур аңа казый булырга тәкъдим итә, ләкин Әбү Хәнифә инкяр иткәч, ул имам Әгъзамны зинданга яба, һәм ул төрмәдә вафат була, Аллаһның рәхмәте булсын аңа.

Имам Әбү Хәнифәнең бу вазыйфаларны инкяр итүе берничә сәбәпкә бәйле. Шуларның берсе: кешеләр арасын хөкем итүдә гаделсезлек күрсәтүдә Аллаһ тәгаләдән куркуы. Шуның өчен дә ул ахирәттәге тимер таяклар белән газаплануга караганда, бу дөньяда башына камчы белән суктырылуны сайлады.

Шулай ук, ул вакытларда казыйлар арасында төрле низаглар барлыкка килеп, кайберләре патшаларга вә әмирләргә ялагайланып икейөзлелек күрсәтә торган иделәр. Ә инде имам Әгъзам, Аллаһ тәгаләнең кушканнарын үтәүдә вә хәрамнарыннан саклануда бер патшага да ялагайланмыйча, берninди вәзир алдында да икейөзлелек күрсәтми иде. Бәлки заһид, диндар кеше буларак күп гыйбадәт кылып, төннәрен тәһәҗҗүд намазларында үткәрә торган булды.

Гыйлемияләренең бозык солтаннарга вә патшаларга барып йөрүләрен шелтәләп килгән башка риваятьләр дә билгеле:

عَنْ أَبِى هُرَيْرَةَ رَضِيَ الله عَنْهُ قَالَ: قَالَ رَسُولُ اللَّهِ صلى الله عليه وسلم: «مَنْ بَدَا جَفَا وَمَنِ اتَّبَعَ الصَّيْدَ غَفَلَ وَمَنْ أَتَى أَبْوَابَ السُّلْطَانِ افْتُتِنَ وَمَا ازْدَادَ عَبْدٌ مِنَ السُّلْطَانِ قُرْباً إِلاَّ ازْدَادَ مِنَ اللَّهِ بُعْداً»

Мәгънәсе: Әбү Һурайрадан ﵁ риваять ителүенчә, пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Кем сахрада яшәсә — каты күңеллегә[13] әйләнә, кем аучылык белән артык мавыкса — гафил була[14], ә кем патшаларга йөрсә — фетнәгә бата. Кеше патшаларга якынайган саен, Аллаһ тәгаләдән ерагая»[15].***

13 Каты бәгырьле, мәрхәмәтсез

14 Аллаһны зикер итүдә, гыйбадәттә читләшәсең

15 Мүснәд Әхмәд, Силсилә әс-сахихә - 1272

Сүфиян бин Гуяйнәдән риваять кылуынча, Әбү Хәзим әйтте: ***«Хакыйкатьтә, галимнәр патшалар белән очрашудан качалар иде, ә патшалар галимнәр артыннан йөриләр иде. Бүгенге көндә гыйлем ияләре патшаларның ишек төпләрен таптыйлар, ә патшалар алардан качалар»[16].***

Хүзәйфә әйтте: ***«Фетнә урыннарыннан сак булыгыз!». Сорадылар: «Нәрсә ул фетнә урыннары, әй Әбү Габдуллаһ?», — дип. Ул әйтте: «Патшаларның ишекләре. Сезнең берәрегез җитәкче янына кереп аның ялганын дөрескә чыгарыр, һәм аңарда булмаган нәрсәне әйтер»[17].***

Габдуллаһ бин Мәсгуд ﷺ әйтте: ***«Хакыйкатьтә, патшаларның ишек төпләрендә кызыгырлык әйберләр бар, ләкин, Аллаһ белән ант итеп әйтәм, сез аларның дөнья малларыннан һичнәрсәләренә дә ирешә алмассыз, яки ирешсәгез алар һичшиксез сезнең динегезгә дә шулай ук ирешәчәкләр (динегезне бозачаклар)»[18].***

Яхъя бин Әбий Кәсир әйтте: ***«Гыйлем ияләре алар тоз кебек, әгәр дә берәр нәрсә бозылса ул тоз белән төзәлә, ә инде тоз бозылса ул һичнәрсә белән дә төзәлмәячәк»[19].***

Шулай ук, әл-Әгъмәш әйтте: ***«Гыйлем ияләреннән ерак булган патшалар вә җитәкчеләр — иң явызлары вә бозыклары, ә инде иң бозык гыйлем ияләре — патшаларга вә җитәкчеләргә якын булганнары».***

Сүфиян әс-Сәүрий болай дип әйтә торган иде: ***«Мин кешенең дөнья яратканлыгын, патшаларга, байларга сәлам бирүеннән белә идем»[20].***

Бервакыт, Хәсән әл-Бәсъри гыйлем ияләренең, җитәкче ибен һәбиранең ишек төбендә керергә көтеп утырганнарын күреп, болай диде: ***«Әгәр дә сез аларда булган***

16 «Әл-Хүлйә» Әбү Нүгайм
17 Мүсаннаф Габдурраззак
18 Мүсаннаф Габдурраззак
19 «Әл-Хүлйә» Әбү Нүгайм
20 «Әл-Хүлйә» Әбү Нүгайм

***нәрсәләрдән читләшсәгез, ул җитәкчеләр сездә булган нәрсәне эстәрләр иде, ләкин сез алардагы нәрсәләрне эстисез, шуңа да алар сездәге нәрсәләрдән (гыйлемнән) читләшәләр[21]».***

Әбү Хәнифә рахимәһү Аллаһ бик тә юмарт, киң күңелле, гаиләсенә җиләк-җимешләрме яки берәрнәрсә ала торган булса, иң әүвәле вә иң яхшыларын гыйлем ияләренә бүләк итә торган иде. Шулай ук, мохтаҗларга вә фәкыйрьләргә игелекле булып, һәрвакытта да ярдәмнәр һәм садакалар бирә иде, хәтта Әбү Юсуфны гаиләсе белән бергә егерме ел үзе карамагына алды.

Шәрик болай диде: ***«Әгәр дә гыйлем эстәүчеләр фәкыйрь булса, Әбү Хәнифә аларга ярдәм итә иде. Ә инде алар укуларын тәмамлагач, аларга: «Син хәләл белән хәрамны белеп байлыкның иң зурысына ирешетең», — дия торган иде»[22].***

Әл-Фадыйл бин Гыядъ әйтте: ***«Әбү Хәнифә аз сүзе вә күп гамәле һәм гыйлем ияләренә карата юмартлыгы белән билгеле иде»[23].***

Әбү Хәнифәнең холкы хакындагы сүзләребезне аның шәкерте Әбү Юсуф һәм Габбасилар дәүләте хәлифе Һарун Рашид арасындагы кара-каршы сөйләшү белән тәмамлыйбыз:

«Бервакыт Һарун Рашид Әбү Юсуфка болай диде: «Әй Әбү Юсуф! Миңа Әбү Хәнифәнең әхлаклары хакында сөйлә әле!». Әбү Юсуф әйтте: **«Хакыйкатьтә, Аллаһ тәгалә болай диде: «Нинди генә сүз әйтелмәсен, мәгәр шул ук вакытта аның янында сүзләрен язып торучы фәрештә булыр».** (Каф: 18). Минем белүемчә, Әбү Хәнифә хәрамнардан бик тә нык саклана, Аллаһ тәгаләнең динендә гыйлемсез сүз сөйләргә курка, Раббысына гөнаһ кылмыйча итагать итәргә ярата иде. Шулай ук, ул дөнья әһелләреннән ерак булып, байлык өчен алар белән ярышмый иде. Аз сүзле,

21 «Әл-Хүлйә» Әбү Нүгайм

22 «Әхбәр Әби Хәнифә вә асхәбиһи» әс-Саймәрий

23 «Әхбәр Әби Хәнифә вә асхәбиһи» әс-Саймәрий

дәимән фикер итүче, соралган сорауга җавабын белсә җавап бирә, белмәсә эзләнә иде. Һәрвакытта да байлыгын да, гыйлемен дә кешеләргә тарата, һәм беркайчан да башкалардан ярдәм эстәп аларга таянмый иде. Гайбәттән читләшеп, һәрвакытта да кешеләрне яхшылык белән генә искә ала иде».

Бу сүзләрне Һарун Рашид ишеткәч, Әбү Юсуфка: «Бу тугры-салих кешеләрнең әхлагы», — диде, һәм үзенең язу-сызу эшләрен алып баручыга: «Бу сыйфатларны язып ал һәм минем улыма өйрәт», — диде[24].

**Гыйлем ала башлавы:** Әбү Хәнифә кечкенә вакытында Әнәс бин Мәлик, Габдуллаһ бин Әбий Әүфә, Сәһел бин Сәгъд һәм Әбү Туфайл кебек дүрт сахәбәне күрүгә иреште.

Билгеле булганча, ул кечкенәдән сәүдә белән шөгыльәнеп, аны төпле гыйлем алуга өндәүче булмый. Ләкин, көннәрнең берендә аның тормышы үзгәреп китә. Бу хакта ул үзе менә нәрсә әйтә: «Бервакыт, мин Шәгъбий[25] яныннан узып барганда ул миңа: «Кемнәр янына йөрисең?», — дип сорады. Мин аңа: «Базарга йөрим, фәлән исемле остазым сәүдәгә өйрәтә», — дип җаваплыдым. Ул: «Мин синең базарга йөрүеңне сорамыйм, ә нинди галимнәргә йөрисең дип сорыйм?», — диде. Мин: «Галимнәр янына бик йөри алмыйм», – дидем. Ул миңа: «Син алай эшләмә, ә бәлки галимнәр янына йөре, аларның гыйлем мәҗлесләрендә гел дә булырга тырыш. Хакыйкатьтә, мин синдә гыйлемгә хирыслык күрәм», — диде. Аның бу сүзләре минем йөрәгемә керде, һәм мин базарга йөрүне ташладым да, бик нык итеп гыйлем алуга керештем. Шәгъбийнең сүзләре сәбәбендә Аллаһ тәгалә миңа бик зур файдалар бирде»[26].

**Әбү Хәнифәнең иң мәшһүр остазлары:** Әл-Миззий «Тәһзиб әл-Кәмәл» китабында Әбү Хәнифәнең илле шәехын

24 «Әхбәр Әби Хәнифә вә асхәбиһи» әс-Саймәрий
25 Гамир бин Шәрахил әш-Шәгъбий, билгеле тәбигыйн
26 «Мәнәкыйб Әби Хәнифә» әл-Мәккий

(остазын) искә алып үтте. Без инде иң мәшһүрләрен генә әйтеп узабыз: Хәммәд бин Әбий Сүләймән, Зәйд бин Гали бин Хүсәйн бин Гали бин Әбий Талиб, Гата бин Әбий Рабәх, Габдулмәлик бин Әби әл-Мухарикъ, Гадий бин Сәбит әл-Әнсарий әл-Күфий, Катәдә бин Дәгамә, Кайс бин Мүслим, Мүхәммәд бин Гали бин Хүсәйн бин Гали бин Әбий Талиб, Мүхәммәд бин әл-Мүнкәдир, Нәфигъ әбү Габдуллаһ әл-Курашний.

**Әбү Хәнифәнең иң мәшһүр шәкертләре:** Җәрир бин Габдулхәмид әл-Күфий, әл-Хәсән бин Зияд әл-Лү'лү'үий, Хәфс бин Гыяс әл-Күфий, Хәммәд бин Әбий Хәнифә, әл-Хәкәм бин Габдуллаһ Әбү Мүтыйгь әл-Бәлхий, Зүфәр бин әл-Һүзәйл, Габдуллаһ бин әл-Мүбәрак, Мүхәммәд бин әл-Хәсән, Нүх бин Әбий Мәрьям әл-Мәрузий, Ягъкуп бин Ибраһим Әбү Юсуф.

**Кайбер гыйлем әһелләренең Әбү Хәнифә хакында сүзләре:**

**1)** Әл-Фадыйл бин Гыядъ: ***«Әбү Хәнифә фәкыйһ, бик тә диндар кеше иде. Иртә дә, кич тә сабырлык белән гыйлем эсти, аз сүзле, хаклыкка өндәүче һәм патшалардан читләшүче иде»[27],*** — диде.

**2)** Ибен Җүрәйҗ: ***«Миңа Әбү Хәнифәнең бик тә диндар, дине вә гыйлеме хакында бик борчылучан һәм беркайчан да дөньяны ахирәттән өстен куймаганлыгы билгеле иде»[28],*** — диде.

**3)** Имам Шәфигый: ***«Кем дә кем фикһ гыйлемен өйрәнергә теләсә, Әбү Хәнифә вә аның шәкертләреннән өйрәнсен. Хакыйкатьтә, кешеләр фикһ гыйлемендә барсы да аңа бәйле»[29],*** — диде.

**4)** Габдуллаһ бин әл-Мүбәрак: ***«Әбү Хәнифә иң фәкыйһ кеше»[30],*** — диде.

---

27 «Тарих Багдад» Әбү Бәкер әл-Багдадий
28 «Әхбәр Әби Хәнифә вә асхәбиһи» әс-Саймәрий
29 «Тарих Багдад» Әбү Бәкер әл-Багдадий
30 «Сияр әгъләм ән-нүбәлә'» әз-Зәһәбий

**5)** Хәфс бин Гыясъ: ***«Фикһта Әбү Хәнифәнең сүзе чәчтән дә нечкәрәк вә төгәлрәк»[31], —*** диде.

**6)** Әз-Зәһәбий: ***«Фикһ гыйлеменең имамлыгы вә нечкәлеге Әбү Хәнифәгә бирелгән»[32], —*** диде.

**7)** Әхмәд бин Хәнбәл: ***«Ул гыйлемдә, диндарлыкта, ахирәтне эстәүдә зур урын алып тора. Әбү Җәгьфар әл-Мансурда казыйлыкны инкяр иткәне өчен камчылар белән суктырылды. Аллаһның рәхмәте булсын Әбү Хәнифәгә»[33], —*** диде.

**8)** Шүгьбә бин әл-Хәҗҗәҗ Әбү Хәнифәнең вафат булуын ишеткәч: ***«Аның белән бергә әл-Күфәнең фикһы китте, Аллаһ тәгалә безгә дә, аңа да рәхмәтен бирсен»[34],*** — диде. һ.б.

**Вафат булуы:** Әбү Хәнифә рахимәһү Аллаһ һиҗри тәкъүим буенча 150нче елның шәгъбән аенда вафат булып, Багдад шәһәрендә җирләнде.

---

31 «Сияр әгьләм ән-нүбәлә‘» әз-Зәһәбий
32 «Сияр әгьләм ән-нүбәлә‘» әз-Зәһәбий
33 «Гукүд әл-җүмән» Мүхәммәд бин Юсуф әш-Шәфигый
34 «Әл-Интика‘» Ибен Габдулбәрр

# Иманның нигезләре

أَصلُ التوحيدِ وما يصحُ الاعتقادُ عليهِ يجبُ أنْ يقولَ: ءامنتُ باللهِ،

**Тәүхиднең нигезе, һәм аңа бәйле инану дөрес булсын өчен ошбу сүзләр әйтелергә тиеш: Иман китердем Аллаһка**

---

**Төшенчәләр: (Нигез)** корылачак вә төзеләчәк нинди дә булса нәрсәнең иң төп терәге булып хезмәт иткән корылма, фундамент.

**Шәрех:**[35] Әбү Хәнифә рахимәһү Аллаһ сүзен игътикад бүлегендә иң мөһим булган һәм ансыз игътикад дөрес булмаячак нәрсәләрне бәян итеп башлап җибәрде. Тәүхиднең нигезе булып, кешенең **«Иман китердем Аллаһка»,** — дигән сүзләре тора. Бу сүзләрне әйтүнең мәгънәсе, кеше үзенең Аллаһка иман китерүен сүз белән әйтеп таный вә раслый.

Тәүхид, ул — гыйбадәттә бер Аллаһны гына тану, вә Ул гына гыйбадәткә лаек дип белү, һәм ул өч төрле:

**Беренчесе:** Тәүхид рубубия.

Хакыйкатьтә, бу галәмдә халикъ кылу да, ризык бирү дә, патшалык та, идарә итү дә Аллаһ карамагында.

هَلْ مِنْ خَالِقٍ غَيْرُ اللَّهِ يَرْزُقُكُمْ مِنَ السَّمَاءِ وَالْأَرْضِ

Мәгънәсе: **«Әллә Аллаһтан башка күктән һәм җирдән сезгә ризык бирүче зат бармы? Әлбәттә юк».** (Фәтыйр: 3)

Гомүмән алганда, барча мүхлуклар да бу төр тәүхидне раслыйлар, һәм ул «тәүхид рубубия» дип атала. Мәхлукларның Аллаһтан башка бер Раббысы да юк.

35 Нәрсәгә дә булса бирелгән аңлатма, комментарий

**Икенчесе:** Тәүхид үлүһия.

Хакыйкатьтә, бер *Аллаһ* кына хакыйкый гыйбадәткә лаек дип тану вә раслау. Бу инде «*Лә иләһә иллә Аллаһ*», — дип шәһәдәт китерүнең таләбеннән чыккан тәүхид, чөнки ул барча иләһләрне батыл кылып вә юкка чыгарып, бер *Аллаһ*ка гына гыйбадәт кылуны раслый вә ныгыта.

ذَلِكَ بِأَنَّ اللَّهَ هُوَ الْحَقُّ وَأَنَّ مَا يَدْعُونَ مِنْ دُونِهِ هُوَ الْبَاطِلُ

Мәгънәсе: **«Бу шуның өчен, чөнки Аллаһ — Ул хак, ә мөшрикләрнең Аллаһтан башкага гыйбадәт кылган нәрсәләре — батыл».** (Хаҗ: 62)

Гыйбадәт кылуда бер *Аллаһ*ны гына танып, намаз, ураза, хаҗ, нәзер, корбан чалу, өметләнү, курку, теләү, тәвәккәл кылу һәм башка барча гыйбадәтне дә *Аңа* гына сарыф итү тиешле. Кем дә кем гыйбадәтнең бер генә өлешен булса да *Аллаһ*тан башкага сарыф итә икән, ул ширек кылган була.

**Өченчесе:** Тәүхид әл-әсмәә вә әс-сыйфаат.

*Аллаһ* тәгалә Үзен Коръәндә һәм пәйгамбәребез ﷺ *Аны* сөннәтендә сыйфатлаган күркәм исемнәр вә камил сыйфатлар белән сыйфатлау. Бу сыйфатларны без мәхлуклар сыйфатына, һәм *Аллаһ*ны мәхлукларга охшатырга тиеш түгел. Шулай ук, бу сыйфатларга бернинди үзгәрешләр дә, бозыклыклар да, кимчелекләр дә һәм аларны хакыйкый мәгънәләреннән чыгара торган мәгънәләр дә бирергә тиеш түгелбез.

لَيْسَ كَمِثْلِهِ شَيْءٌ وَهُوَ السَّمِيعُ الْبَصِيرُ

Мәгънәсе: **«Аллаһка охшаган һичнәрсә юк, вә Ул Ишетүче, вә Күрүче».** (Шүра: 11)

Бу аятьтә, *Аллаһ*ны мәхлукларга охшашлыктан пакьләү һәм камил сыйфатларны раслау чагыла.

Шулай итеп, **«*Лә иләһә иллә Аллаһ*»**ның мәгънәсе ошбулардан гыйбарәт:

**1)** Без Аллаһ тәгаләгә генә буйсынырга, Ул хәрам кылган нәрсәләрне генә хәрам кылырга һәм Ул хәләл иткәннәрне генә хәләл итәргә тиеш.

**2)** Ислам шәригате булган, Коръән һәм Сөннәт шәригатеннән башка һичнәрсәне дә кабул итмәскә.

**3)** Исламга каршы килгән бер төрле низам белән дә риза булмаска.

**«Лә иләһә иллә Аллаһ»ның шартлары:**

**1) Гыйлем:** Барча иләһләрнең дөрес түгеллеген исбатлап, һәм Аллаһны гына раслап килгән **«Лә иләһә илләАллаһ»** кәлимәсе мәгънәсенең гыйлеме.

**2) Йәкыйн (ныклы инану):** Ул, барча шикләрне вә шөбһәләрне юкка чыгара торган ныклы инану, ышану.

إِنَّمَا الْمُؤْمِنُونَ الَّذِينَ آمَنُوا بِاللَّهِ وَرَسُولِهِ ثُمَّ لَمْ يَرْتَابُوا

Мәгънәсе: **«Хакыйкатьтә мөэминнәр, алар чын күңелдән Аллаһка, вә Аның рәсүленә ныклап иман китерделәр, моннан соң иман китерүләренә һич шикләнмәделәр».** (Хүҗүрат: 15)

**3) Ихлас:** Ул, ширекне юкка чыгара торган ихлас.

وَمَا أُمِرُوا إِلَّا لِيَعْبُدُوا اللَّهَ مُخْلِصِينَ لَهُ الدِّينَ حُنَفَاءَ

Мәгънәсе: **«Алар Исламнан башка барча диннәрдән дә баш тарткан хәлдә, бер Аллаһка гына ихлас күңелдән гыйбадәт кылырга боерылдылар».** (Бәйинә: 5)

**4) Тугрылык:** Ул, ялганны юкка чыгара торган һәм икейөзлелектән, монафикълыктан тыючы тугрылык.

وَمِنَ النَّاسِ مَنْ يَقُولُ آمَنَّا بِاللَّهِ وَبِالْيَوْمِ الْآخِرِ وَمَا هُمْ بِمُؤْمِنِينَ ۞
يُخَادِعُونَ اللَّهَ وَالَّذِينَ آمَنُوا وَمَا يَخْدَعُونَ إِلَّا أَنْفُسَهُمْ وَمَا يَشْعُرُونَ

Мәгънәсе: **«Кешеләр арасында шундыйлары бар, алар үзләре ышанмаса да: «Без Аллаһка һәм ахирәт көненә ышандык», — диләр, ләкин алар ышанучылар түгел. Ул монафыйкълар Аллаһны һәм мөселманнарны алдамак-**

**чы булалар, ләкин алар үзләре дә сизмичә фәкать үзүзләрен генә алдыйлар».** (Бәкара: 8-9)

**5) Мәхәббәт:** Ул, ошбу кәлимәгә һәм ул ишарәт кылган нәрсәләргә мәхәббәт.

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا مَنْ يَرْتَدَّ مِنْكُمْ عَنْ دِينِهِ فَسَوْفَ يَأْتِي اللَّهُ بِقَوْمٍ يُحِبُّهُمْ وَيُحِبُّونَهُ

Мәгънәсе: **«Әй, мөэминнәр! Әгәр сезнең арагыздан берәү хак динен ташлап мөртәт булса, Аллаһ алар урынына Үзе сөйгән һәм Аллаһны сөюче кавемне тиздән китерер».** (Мәидә: 54)

**6) Буйсыну:** Ул, Аллаһның ризалыгын өмет итеп ошбу кәлимә белән бәйле хөкемнәрдә тулаем буйсыну.

وَمَنْ يُسْلِمْ وَجْهَهُ إِلَى اللَّهِ وَهُوَ مُحْسِنٌ فَقَدِ اسْتَمْسَكَ بِالْعُرْوَةِ الْوُثْقَى

Мәгънәсе: **«Берәү изгелекләр кылып үзен тулаем Аллаһка буйсындырса, ул кеше бик ышанычлы, беркайчан да өзелми вә какшамый торган тоткага тотынды».** (Локман: 22)

**7) Кабул итү:** Ул, ошбу кәлимәне кабул итми торган тәкәбберлекне вә тискәрелекне юкка чыгара торган кабул.

إِنَّهُمْ كَانُوا إِذَا قِيلَ لَهُمْ لَا إِلَهَ إِلَّا اللَّهُ يَسْتَكْبِرُونَ

Мәгънәсе: «**Аларга: «Аллаһтан башка бернинди иләһ юк», — дип әйтелсә, алар (бу кәлимәне кабул итмичә) тәкәбберләнәләр».** (Саффәт: 35)

**8) Инкяр итү, ышанмау:** Ул, Аллаһтан башка нәрсәләргә гыйбадәтне инкяр итү, һәм ул иләһләргә ышанмау.

فَمَنْ يَكْفُرْ بِالطَّاغُوتِ وَيُؤْمِنْ بِاللَّهِ فَقَدِ اسْتَمْسَكَ بِالْعُرْوَةِ الْوُثْقَى

Мәгънәсе: **«Берәү Аллаһка иман китереп, Аннан башканы иләһ тотуны инкяр итсә вә аларга ышанмаса, ул мөэмин һич тә өзелми-сынмый торган тоткага ябышты».** (Бәкара: 256)

ومَلائكتِهِ، وكُتُبِهِ، ورُسُلِهِ،

**Аның фәрештәләренә, Аның китапларына, Аның расүлләренә (пәйгамбәрләренә)**

---

**Төшенчәләр: (Фәрештәләр)** Берлек санда — фәрештә. Фәрештәләр алар нурдан яратылган Аллаһ тәгаләнең мәхлуклары. Ашамыйлар, эчмиләр һәм Аллаһка буйсынып, Аның кушканнарын гына үтиләр. **(Расүлләр)** Берлек санда — расүл. Аларга Аллаһтан шәригат иңдереледе һәм алар ошбу шәригатне барчасына да җиткерү белән боерылдылар.

**Шәрех:**

**Фәрештәләргә иман китерү** — Иман нигезләренең бер рөкене булып тора. Алар Аллаһка гыйбадәт кылу һәм Аның әмерләрен башкару белән йөкләнгәннәр. Һәркайсының үз вазыйфасы билгеләнгән. Фәрештәләргә иман китерү гомуми дә[36], һәм тәфсыйлләп тә[37] фарыз. Нинди фәрештәләрнең исемнәре яки гамәлләре тәгаенләп искә алынмаган икән, без аларга гомуми ышанырга тиеш, ә кайсыларыныкы аерым тәгаенләп искә алынган булса, без аларга тәфсыйлләп, яки ничек искә алынган икән, шулай ышанырга тиеш. Корьән Кәрим фәрештәләрне бик күп урыннарда искә алды. Мәсәлән: Җибрил, Микәил, Исрафил – алар барысы да тереклек белән йөкләнгән фәрештәләр. Җибрил – ул, йөрәкләрнең вә җаннарның тереклеге булган вәхи белән йөкләнгән. Микәил – ул, җирнең, үләннәрнең вә хайваннарның тереклеге булган яңгыр белән йөкләнгән, ә Исрафил – ул, мәхлуклар үлгәннән соң Кыяматтә кире терелүгә сәбәп булган Сурга өрү белән йөкләнгән. Шулай ук фәрештәләр арасыннан Гарешне күтәрү белән, барча гамәлләрне язып тору белән, саклау белән, Җәһәннәм уты һәм Җәннәт сакчылары, җаннарны алу вә кабердә

36 Барча фәрештәләргә бергә

37 Җентекләп, аерым-аерым билгеләп

кешенең дине, Раббысы вә пәйгамбәре хакында сорау алу белән йөкләнгәннәре бар. Боларның барсына да тәфсыйлләп ышану тиешле.

❁ Иман нигезләренең тагын бер рөкене – Аллаһ тәгаләнең кайбер расүлләренә иңдергән китапларына иман китерү. Ул китапларда Аллаһның шәригате һәм бәндәләргә вәгазь вә гыйбрәт. Аларга гомуми, ә искә алынган вә билгеле булганнарына тәфсыйлләп иман китерү тиешле. Тәфсыйлләп иман китерү тиешлеләре; Тәүрат, Инҗил, Зәбүр, Ибраһимга һәм Мусага бирелгән сахифәләр һәм Коръән.

Коръән иң хәерлесе вә иң ахыргысы булып тора. Ул Аллаһ тәгаләнең сүзе һәм анда ялган да, батыл да юк, бәлки ул – хак.

❁ Иман нигезләренең тагын бер рөкене – Аллаһ тәгаләнең расүлләренә иман китерү. Аллаһ тәгалә бәндәләргә бу дөньяда да, ахирәттә дә бәхеткә ирешү өчен туры юлны күрсәтүче, Үзенең шәригатен ирештерүче пәйгамбәрләр җибәрде.

اللَّهُ يَصْطَفِي مِنَ الْمَلائِكَةِ رُسُلا وَمِنَ النَّاسِ

Мәгънәсе: **«Аллаһ фәрештәләрдән вә кешеләрдән расүлләр ихтыяр итәр».** (Хаҗ: 75)

رُسُلًا مُبَشِّرِينَ وَمُنْذِرِينَ لِئَلَّا يَكُونَ لِلنَّاسِ عَلَى اللَّهِ حُجَّةٌ بَعْدَ الرُّسُلِ

Мәгънәсе: **«Расүлләр үзләренең бурычларын үтәгәннән соң, ахирәттә динсезләр: «Әй Аллаһ, безгә китап иңдермәдең, расүлләр күндермәдең», — дип аклану булмасын өчен, Аллаһ тәгалә Аңа итагать итүче хак мөэминнәрне Җәннәт белән шатландыручы һәм Аллаһка итагать итмәүчеләргә Җәһәннәм газабы булачагы белән хәбәр бирүче пәйгамбәрләрне җибәрде».** (Нисә: 165)

Пәйгамбәрләр, кешеләр арасыннан иң хәерлеләре. Без аларның кайсыларын беләбез, ә кайсыларындыр белмибез.

وَرُسُلًا قَدْ قَصَصْنَاهُمْ عَلَيْكَ مِنْ قَبْلُ وَرُسُلًا لَمْ نَقْصُصْهُمْ عَلَيْكَ

Мәгънәсе: **«Янә, элек сиңа кайбер пәйгамбәрләрне бәян иттек һәм кайбер пәйгамбәрләрне сиңа бәян итмәдек».** (Нисә: 164)

Коръәндә искә алынган пәйгамбәрләр егерме биш: Адәм, Идрис, Нух, Һуд, Салих, Ибраһим, Лут, Йунус, Исмәгыйль, Исхакъ, Ягъкуб, Йусуф, Әйүб, Шүгайб, Муса, Һарун, Әлясәгъ, Зүл-Кифел, Давыд, Зәкәрия, Сөләймән, Ильяс, Яхъя, Гыйсә һәм аларның ахыргысы вә иң хәерлесе Мөхәммәд ﷺ. Без аларга тәфсыйлләп иман китерергә тиеш. Кем дә кем берсенең генә булса да пәйгамбәрлеген инкяр итсә, ул көферлек кылган була. Ә калган пәйгамбәрләргә гомуми иман китерәбез. Аларның барчасын да яратабыз һәм берсеннән-берсен аерып билгеләмибез.

والبعثِ بعدَ الموتِ والقدرِ خيرِهِ وشرِّهِ منَ اللهِ تعالى،

**Үлемнән соң кубарылуга һәм тәкъдирнең яхшысы да, яманы да Аллаһтан икәнлегенә**

---

**Төшенчәләр: (Кубарылу)** Үлгәннән соң терелү.

**Шәрех:**

❁ Без, **үлгәннән соң кубарылуга** иман китерергә вә ышанырга тиеш. Аллаһ тәгалә кешеләрне үлгәннән соң яңадан тергезә һәм дөньядагы гамәлләре өчен хисап кыла вә тиешле җәзаларын бирә. Кубарылу җаннар белән тәннәргә кагыла, ягъни Аллаһ тәгалә кешеләрне ничек әүвәлге тапкыр халикъ кылган булса, шулай ук икенче тапкыр да тергезә һәм Аңа бу бик тә җиңел.

Кубарылуда шикләнгәннәргә җавап итеп Аллаһ тәгалә болай диде:

أَيَحْسَبُ الإِنْسَانُ أَلَّنْ نَجْمَعَ عِظَامَهُ ❁ بَلَى قَادِرِينَ عَلَى أَنْ نُسَوِّيَ بَنَانَهُ

Мәгънәсе: **«Кеше әллә Без аның сөякләрен җыя алмабыз дип уйлыймы? Әлбәттә, Без аның хәтта кечкенә бармак очларын да кире җыярга көчебез җитә».** (Әл-Кыямәһ: 3-4)

Үлгәннән соң терелүне инкяр итүчеләрнең көферлеген билгеләп болай диде:

زَعَمَ الَّذِينَ كَفَرُوا أَنْ لَنْ يُبْعَثُوا قُلْ بَلَى وَرَبِّي لَتُبْعَثُنَّ
ثُمَّ لَتُنَبَّؤُنَّ بِمَا عَمِلْتُمْ وَذَلِكَ عَلَى اللَّهِ يَسِيرٌ

Мәгънәсе: **«Кәферләр үзләренчә «үлгәннән соң терелү булмый» дип исәплиләр. Син аларга әйт: «Бәлки, әлбәттә, терелерсез. Раббымның исеме илә ант итеп әйтәмен, әлбәттә, терелеп каберләрегездән кубарылып чыгачаксыз, соңра кылган эшләрегездән үзегезгә хәбәр бирелмеш булырсыз. Бу эш Аллаһка бик җиңел».** (Тәгабүн: 7)

Аллаһ тәгалә Кыямәт Көнендә барчасын да кубарып, гамәлләренә карата тиешле җәза бирүе хакында болай диде:

يَوْمَ يَبْعَثُهُمُ اللَّهُ جَمِيعًا فَيُنَبِّئُهُمْ بِمَا عَمِلُوا أَحْصَاهُ
اللَّهُ وَنَسُوهُ وَاللَّهُ عَلَى كُلِّ شَيْءٍ شَهِيدٌ

Мәгънәсе: **«Аллаһ Кыямәт Көнне аларның барчасын кубарыр вә кылган эшләреннән хәбәр бирер, алар эшләп оныткан гамәлләрне Аллаһ барын да санаган һәм язган. Аллаһ һәрнәрсәгә шаһит, Аңа һичнәрсә яшерен түгел».** (Мүҗәдәлә: 6)

❁ **Тәкъдиргә иман,** Иман нигезләренең иң четереклесе вә катлаулысы булып тора.

**Тәкъдирнең (кадар) мәгънәсе:**

**Кадар** – ул, барча мәхлукларны да бар кылганчы белгән, Аллаһ тәгаләнең гыйлеме, һәм Үзенең гыйлеменә карата теләге вә кодрәте белән, ул мәхлукларны халикъ кылуы.

**Тәкъдиргә иман китерүнең ике шарты бар:**

**Беренче:** Бәндәләрне халикъ кылганчы Аллаһ тәгалә аларның яхшы яки начар гамәл кыласыларын белә иде, һәм алар, Аңарда Ләүхул-Мәхфузда язылган, дип иман китерү.

**Икенче:** Аллаһ тәгалә бәндәләрнең барча гамәлләрен халикъ кылды, һәм алардан шуны теләде, дип иман китерү.[38]

Яки моны икенче төрле әйткәндә, тәкъдирнең мәртәбәләре, дип дүрткә бүлергә була:

**1) Гыйлем.** Аллаһ тәгалә күкләрдә һәм җирдә, Үзенә хас булган һәм мәхлукларның фигыльләреннән булган, барча нәрсәне дә белә, Аннан һичнәрсә дә яшеренеп кала алмый, дип инану (ныклы ышану) тиешле.

إِنَّ اللَّهَ لا يَخْفَى عَلَيْهِ شَيْءٌ فِي الأَرْضِ وَلا فِي السَّمَاءِ

38 65нче биттә аңлатмасы була

Мәгънәсе: **«Аллаһка, әлбәттә, җирдә һәм күкләрдә һичнәрсә яшерен түгел».** (Әли-Гыймран: 5)

وَمَا يَعْزُبُ عَنْ رَبِّكَ مِنْ مِثْقَالِ ذَرَّةٍ فِي الأَرْضِ وَلا
فِي السَّمَاءِ وَلا أَصْغَرَ مِنْ ذَلِكَ وَلا أَكْبَرَ

Мәгънәсе: **«Дәхи Раббыңнан җирдә вә күкләрдә тузан бөртеге хәтле нәрсә дә яшерен булмас. Булсын ул зур, яки кечкенә».** (Йунус: 61)

Имам Тахауий үзенең гакыйдә китабында болай диде: ***«Аларны (мәхлукларны) халикъ кылганчы ук, Аннан һич яшерен нәрсә юк иде. Аларны халикъ кылганчы ук, Ул нинди гамәл кыласыларын белә иде»[39].***

**2) Китәбә,** яки барча нәрсәнең дә Аллаһ тәгаләдә Ләүхул-Мәхфузда язылуы. Аллаһ тәгалә барча мәхлукларның да язмышын Үзендә Ләүхул-Мәхфузда язды, дип инану.

مَا أَصَابَ مِنْ مُصِيبَةٍ فِي الأَرْضِ وَلا فِي أَنْفُسِكُمْ إِلا فِي كِتَابٍ مِنْ قَبْلِ أَنْ نَبْرَأَهَا

Мәгънәсе: **«Җирдә вә үзегездә нинди генә бәла-каза булмасын — Без аны барлыкка китергәнче үк, ул Ләүхул Мәхфузда язылгандыр».** (Әл-Хәдид: 22)

Имам Тахауий гакыйдәсендә болай диде: ***«Ләүхул-Мәхфузга, каләмгә һәм анда язылганның барчасына да ышанабыз. Әгәр бөтен мәхлуклар бергә җыелып, Аллаһ тәгалә булырга язган әйбергә киртә куеп, булдырмаска тырышкан булсалар, максатларына ирешә алмаслар иде; әгәр дә бөтенесе җыелып, Аллаһ тәгалә тәкъдиргә язмаган әйберне булдырып караган булсалар, булдыра алмаслар иде. Кыямәт көненә кадәр булачакның өстеннән каләм кипкән инде»[40].***

---

39 Тахауия гакыйдәсе
40 Тахауия гакыйдәсе

Бу ике мәртәбә турында түбәндәге аятьне китерергә мөмкин:

أَلَمْ تَعْلَمْ أَنَّ اللَّهَ يَعْلَمُ مَا فِي السَّمَاءِ وَالْأَرْضِ إِنَّ ذَٰلِكَ فِي كِتَابٍ إِنَّ ذَٰلِكَ عَلَى اللَّهِ يَسِيرٌ

Мәгънәсе: **«Әллә белмәдеңме Аллаһның җирдәге вә күкләрдәге нәрсәләрне белгәнлеген? Алар барчасы да Ләүхүл-Мәхфуздагы китапта язылган, сезне хөкем итү вә һәрнәрсәне белү, Аллаһка җиңел».** (Әл-Хаҗ: 70)

Аллаһ тәгалә беренче һәрнәрсәне белгәнлеген хәбәр итте, аннары ул нәрсәләрнең барысы да Ләүхүл-Мәхфузда язылган дип бәян кылды.

**3) Ирадә, яки теләк.** Барча нәрсә Аллаһның теләге буенча. Ул нәрсәнең булуын теләсә — шул була, ә нәрсәнең булуын теләмәсә — ул булмый. Моңа түбәндәге аятьләрне китерергә мөмкин:

لِمَنْ شَاءَ مِنْكُمْ أَنْ يَسْتَقِيمَ ۞ وَمَا تَشَاءُونَ إِلَّا أَنْ يَشَاءَ اللَّهُ رَبُّ الْعَالَمِينَ

Мәгънәсе: **«Сезләрдән туры юлга күнергә теләге булган кешеләр. Юк туры юлга күнүне тели алмассыз, илләмәгәр барча галәмнәрне тәрбия итүче Аллаһ тәгалә теләсә генә».** (Әт-Тәкүир: 28-29)

وَلَوْ شِئْنَا لَآتَيْنَا كُلَّ نَفْسٍ هُدَاهَا

Мәгънәсе: **«Әгәр Без теләсәк, һәр кешегә иманны вә һидәятне бирер идек».** (Сәҗдә: 13)

وَلَوْ شَاءَ رَبُّكَ لَجَعَلَ النَّاسَ أُمَّةً وَاحِدَةً

Мәгънәсе: **«Әгәр Раббың теләсә иде, бөтен кешеләрне дә бер диндә кылыр иде».** (Һүд: 118)

Имам Тахауий үзенең гакыйдә китабында болай диде: ***«Барча нәрсә дә Аллаһның билгеләгән тәкъдире вә теләге белән. Аның теләгәне булыр. Бәндәләрнең теләгәне илләмәгәр Аллаһ теләге белән генә бу-***

***лыр. Аларга нәрсә булуын теләсә — булыр, ә нәрсәне теләмәсә — булмас»[41].***

**4) Халикъ кылу.** Барча нәрсәне дә Аллаһ тәгалә халикъ кылды (булдырды) дип инану. Булсын ул җирдә яки күкләрдә, кешеләрнең гамәлләре хәтта кешенең үзе артыннан тормышның юклыгын алып килә торган үлемне дә, Аллаһ халикъ кылды.

الَّذِي خَلَقَ الْمَوْتَ وَالْحَيَاةَ لِيَبْلُوَكُمْ أَيُّكُمْ أَحْسَنُ عَمَلا

Мәгънәсе: **«Ул үлемне һәм тереклекне халикъ кылды, кайсыларыгыз яхшырак гамәлле икәнлеген йөкләмәләр йөкләп, сезне сынамак өчен».** (Әл-Мүлк: 2)

وَاللَّهُ خَلَقَكُمْ وَمَا تَعْمَلُونَ

Мәгънәсе: **«Сезнең үзегезне вә кылган гамәлләрегезне Аллаһ халикъ итте».** (Әс-Саффәт: 96)

Имам Тахауий гакыйдәсендә әйтте: ***«Колларның эшләрен халикъ кылучы — Аллаһ, ә коллар — кәсеп итүче»[42].***

Халикъ вә тәкъдир кылу бер Аллаһка гына хас. Ул безгә мөмкинчелек вә теләк бирде, шуңа да безнең гамәлләребез – ошбу ике әйбернең нәтиҗәсе, һәм шуның өчен дә сoралачакбыз[43].

41 Тахауия гакыйдәсе

42 Тахауия гакыйдәсе

43 Тахауия гакыйдәсенә ибен Әбү әл-Гыйз әл-Хәнәфинең яки башка сөннәт әһелләреннән булган гыйлем ияләренең аңлатмасын кара

والحسابِ، والميزانِ،

## Хисапка һәм мизанга

---

**Төшенчәләр: (Хисап)** Исәпләү, санау вә тиешлесен алу. **(Мизан)** Үлчәү, бизмән.

**Шәрех:**

❁ Сөннәт әһелләре хисапка иман китерәләр. Аллаһ тәгалә кешеләрне Кыямәт көнендә кубара һәм гамәлләрен хисап кылып һәрберсенә тиешле җәзасын бирә. Бу инде, Кыямәт көнендә буласы иң олуг күренешләрдән.

فَأَمَّا مَنْ أُوتِيَ كِتَابَهُ بِيَمِينِهِ ❁ فَسَوْفَ يُحَاسَبُ حِسَابًا يَسِيرًا

Мәгънәсе: **«Әмма гамәл дәфтәре уң тарафтан бирелгән кеше. Җиңел хисап ителер».** (Әл-Иншикакъ: 7,8)

فَحَاسَبْنَاهَا حِسَابًا شَدِيدًا وَعَذَّبْنَاهَا عَذَابًا نُكْرًا

Мәгънәсе: **«Без аларны каты хисап белән хисап кылдык, вә аларны куркынычлы ут газабы белән газап кылдык».** (Әт-Таләкъ: 8)

❁ Шулай ук, алар Мизанга иман китерәләр. Ул Мизан, Кыямәт көнендә бәндәләрнең гамәлләрен үлчи торган ике кәсәле хакыйкый үлчәү. Кемнең изгелекләре авыр килсә — бәхеткә иреште, ә кемнең гөнаһлары авыр килсә — хәсрәткә иреште.

وَنَضَعُ الْمَوَازِينَ الْقِسْطَ لِيَوْمِ الْقِيَامَةِ فَلا تُظْلَمُ نَفْسٌ شَيْئًا وَإِنْ
كَانَ مِثْقَالَ حَبَّةٍ مِنْ خَرْدَلٍ أَتَيْنَا بِهَا وَكَفَى بِنَا حَاسِبِينَ

Мәгънәсе: **«Кыямәт Көне өчен Без гадел үлчәүне куярбыз, савабы киметелеп яки гөнаһы арттырылып, һичкемгә золым итү булмас, гәрчә яхшылыгы хардал[44] орлыгы хәтле генә булса да аны үлчәүгә куярбыз. Хисап итеп җәза бирмәк өчен Без җитәрбез!».** (Әл-Әнбия: 47)

---

44 Горчич орлыгы

Имам Тахауий гакыйдәсендә әйтте: ***«Һәм үлгәннән соң кире терелүгә (кубарылуга), Кыямәт Көнендә һәр эшкә җәза бирелүгә, тезелеп бастырылуга, хисапка, гамәл дәфтәрләрен укуга, савап һәм җәзага, сират күпере һәм үлчәүгә ышанабыз»[45].***

45 Тахауия гакыйдәсе

والجنةِ، والنارِ، وذلكَ حقٌ كُلُّهُ

## Җәннәткә вә Җәһәннәмгә һәм боларның барсы да хак икәненә ышанабыз

---

**Төшенчәләр:**

**Шәрех:**

Сөннәт әһелләренең Кыямәт Көненә иман белән бәйле тагын иң зур нәрсәләрнең берсе, Җәннәт һәм Җәһәннәмгә иман. Җәннәт — ул, тәкъва, салих вә яхшы бәндәләрнең савап һәм рәхмәт йорты. Анда мәңгелек нигъмәт. Җәһәннәм — кәферләрнең, монафикъларның һәм фасикъларның җәза һәм газап йорты. Анда бернинди дә хәерлелек юк, ә бәлки каты газап кынадыр.

Җәннәт белән Җәһәннәм искә алынган Коръән аятьләре бихисап.

وَمَنْ يُطِعِ اللَّهَ وَرَسُولَهُ يُدْخِلْهُ جَنَّاتٍ تَجْرِي مِنْ تَحْتِهَا الأَنْهَارُ
خَالِدِينَ فِيهَا وَذَلِكَ الْفَوْزُ الْعَظِيمُ ۞ وَمَنْ يَعْصِ اللَّهَ وَرَسُولَهُ
وَيَتَعَدَّ حُدُودَهُ يُدْخِلْهُ نَارًا خَالِدًا فِيهَا وَلَهُ عَذَابٌ مُهِينٌ

Мәгънәсе: **«Берәү Аллаһка һәм Аның расүленә итагать итсә, Аллаһ аны асларыннан елгалар агучы Җәннәтләргә кертер, алар анда мәңге калырлар. Моңа ирешү — өстенлекнең иң олысыдыр. Берәү Аллаһка вә расүленә карышып гасый булса, һәм Аллаһ чигеннән үтеп китсә, Аллаһ аны мәңгелеккә Җәһәннәмгә кертер һәм аңа рисвай итүче газап булыр».** (Ән-Нисә: 13,14)

وَمَنْ يُطِعِ اللَّهَ وَرَسُولَهُ يُدْخِلْهُ جَنَّاتٍ تَجْرِي مِنْ تَحْتِهَا الأَنْهَارُ

Мәгънәсе: **«Берәү Аллаһка вә расүленә итагать итсә, Аллаһ ул кешене асларыннан елгалар агучы Җәннәтләргә кертер».** (Әл-Фәтх: !7)

إِنَّا أَعْتَدْنَا جَهَنَّمَ لِلْكَافِرِينَ نُزُلا

Мәгънәсе: **«Тәхкыйк, Без Җәһәннәмне кәферләр өчен иңәчәк урын кылдык».** (Әл-Кәһф: 102)

وَسِيقَ الَّذِينَ اتَّقَوْا رَبَّهُمْ إِلَى الْجَنَّةِ زُمَرًا

Мәгънәсе: **«Раббыларына тәкъвалык кылган мөэминнәрне төркеме белән Җәннәткә озатырлар».** (Әз-Зүмәр: 73)

وَسِيقَ الَّذِينَ كَفَرُوا إِلَى جَهَنَّمَ زُمَرًا

Мәгънәсе: **«Кәферләрне төркемнәре белән Җәһәннәмгә куарлар».** (Әз-Зүмәр: 71)

Болар һәммәсе дә хак, һәм барчасына да иман китерелергә тиеш, ә кем инде бу нәрсәләрнең бер генә өлешенә булса да ышанмаса вә инкяр итсә, ул Аллаһка көферлек кылган була.

Имам Тахауий гакыйдәсендә болай диде: ***«Җәннәт һәм Җәһәннәм яратылган әйберләр. Алар мәңге бетмәячәкләр һәм юкка чыкмаячаклар. Аллаһ Җәннәт һәм Җәһәннәмне мәхлукларны бар иткәнче барлыкка китерде һәм икесенә дә ияләрен билгеләде; теләгәнен хөрмәт итеп Җәннәт әһеле итте, теләгәнен Үзенең гаделлеге белән Җәһәннәм әһеле кылды»[46].***

**Кыскача нәтиҗә:**

Кеше иман китерергә тиеш булган Иманның нигезе ошбулар; Аллаһка иман, Аның фәрештәләренә иман, Китапларына иман, Расүлләренә иман, Ахирәт көненә вә андагы Җәннәткә, Җәһәннәмгә, Мизанга, Сыйратка иман, һәм Тәкъдирнең яхшысына да, яманына да иман.

**Сораулар:**

1) Иманның нигезләрен әйтеп уз?

2) Кыямәт көненең кайбер күренешләрен әйтеп уз?

46 Тахауия гакыйдәсе

# Аллаһ тәгаләнең берлеге

واللهُ تعالى واحدٌ لا مِنْ طريقِ العددِ، ولكنْ من طريقِ أنهُ لا شريكَ لهُ، لم يَلِدْ ولم يُولَدْ، ولم يكنْ له كفُواً أَحَد. لاَ يُشبِهُ شيئاً مِنَ الأشياءِ مِنْ خَلقه، ولا يشبهه شيءٌ مِن خلقِهِ، لم يزلْ ولا يزالُ بأسمائه وصفاته الذاتية والفِعليّة

**Аллаһ тәгалә — Бер, сан ягыннан түгел, ләкин Аның тиңдәше юклыгыннан. Ул тудырмады һәм тудырылмады вә һичкем Аңа тиң булмады. Ул мәхлукларның һичнәрсәсенә охшамаган һәм алар да Аңа һичнәрсәдә охшаш түгел. Туктамады һәм туктамаячак Үзенең зат вә фигыль сыйфатларында**

---

**Төшенчәләр: (Тиң)** Охшаш, тигез, иш. **(Зат сыйфатлары)** Аның затына хас сыйфатлар. **(Фигыль сыйфатлары)** Аның теләге белән бәйле сыйфатлар.

**Шәрех:** Аллаһ тәгалә Бер, икенең яртысы бер дигән сан мәгънәсендә түгел, ләкин Аның рубубияттә да[47], иләһияттә дә[48] һәм күркәм исемнәрендә вә камил сыйфатларында да[49] тиңдәше юклыгы мәгънәсендә Ул бердән Бер. Ә инде Аллаһ тәгалә белән мәхлуклар ара-

---

47 **Тәүхид рубубия.** Ул — Аллаһ тәгалә барча нәрсәне халикъ кылучы, ризыкландыручы, тергезүче вә үлекләндерүче — дип, Аңа ныклы ышану. Чөнки «Раббы нәрсәне теләсә, шуны эшли», — дип иман китерү була. Пәйгамбәребез ﷺ вакытында, хәтта Мәккә мөшрикләре дә бу тәүхидне таныйлар иде, мәгънәсе: **«Әгәр син алардан: «Сезне кем халикъ кылды?», — дип сорасаң, алар, әлбәттә: «Аллаһ халикъ кылды», — диячәкләр».**

48 **Тәүхид үлүһия.** Ул: «Хакыйкатьтә, бер Аллаһ кына гыйбадәткә лаек», — дип ышану һәм кабул итү. Ошбу тәүхидне мөшрикләр кабул итмәделәр һәм шушы тәүхидтә пәйгамбәрләр белән алар арасында каршылык чыкты.

49 **Тәүхид әл-әсмәә вә әс-сыйфаат.** Ул — Аллаһны, Үзен Коръәндә һәм пәйгамбәребез ﷺ Аны сөннәтендә сыйфатлаган күркәм исемнәр вә камил сыйфатлар белән сыйфатлау.

сында уртак искә алынган исемнәр вә сыйфатлар, алар тел ягыннан гына бер мәгънәле сүзләр генә.

Мәсәлән:

إِنَّ اللَّهَ كَانَ سَمِيعًا بَصِيرًا

Мәгънәсе: **«Хакыйкатьтә, Аллаһ — ишетүче, күрүче».** (Ән-Нисә: 58)

Кеше хакында болай диелде:

فَجَعَلْنَاهُ سَمِيعًا بَصِيرًا

Мәгънәсе: **«Без аны ишетүче, күрүче иттек».** (Әл-Инсән: 2)

Әмма, исемнең хакыйкате вә сыйфатның хакыйкате һәм ничеклеге, Аллаһның заты мәхлукның затыннан ничек аерыла торган булса, шулай ук аерылып тора.

Аллаһның сыйфатыннан:

لَمْ يَلِدْ وَلَمْ يُولَدْ ۞ وَلَمْ يَكُنْ لَهُ كُفُوًا أَحَدٌ

Мәгънәсе: **«Ул тудырмады һәм тудырылмады вә һичкем Аңа тиң булмады».** (Әл-Ихлас: 3,4)

Ул – Аллаһ, Аның баласы булудан һәм Аның тудыручысы булудан пакь!

Чөнки, тудыру вә тудырылу, бер нәрсәнең юктан барлыкка килеп чыгуында башкага мохтаҗлы була, ярдәм эсти. Мондый нәрсә мәхлукларда гына булырга мөмкин, ә инде Аллаһ хакында мондый нәрсәләр уйлау мөмкин түгел. Аллаһ тәгалә мәхлукларның һичберсенә дә охшаш түгел һәм алар да Аңа һичберсе охшаш түгел. Бу хакта Ул болай диде:

لَيْسَ كَمِثْلِهِ شَيْءٌ وَهُوَ السَّمِيعُ الْبَصِيرُ

Мәгънәсе: **«Аллаһка охшаган һичнәрсә юк, вә Ул Ишетүче, Күрүче».** (Әш-Шүра: 11)

Бәлки, Ул — Аллаһ тәгалә, әүвәлге — Аннан алда һичнәрсә юк, ахыргы — Аннан соң һичнәрсә юк. Ул Үзенең күркәм исемнәре, камил зат вә фигыль сыйфатлары белән әүвәлге һәм ахыргы. Зат сыйфатлары Аның затына әүвәлдән вә ахырдан лязем булды һәм Аның теләге белән бәйле түгел, мәсәлән; **Тереклек** сыйфаты кебек. Әмма фигыль сыйфатлары, алар теләк белән бәйле, әгәр дә Аллаһ теләсә була, мәсәлән; **Ачу, Ризалык** кебек. Фигыль сыйфатлары теләк белән бәйле булса да, төре буенча әүвәлге, ә инде зат сыйфатлары мотлак рәвештә әүвәлге.

Сыйфатларны затныкына һәм фигыльнекенә бүлү, Сөннәт вә җәмәгать әһелләрендә билгеле-мәшһүр нәрсә[50].

50 Әл-Бәйһәкыйның «әл-Әсмә вә әс-Сыйфат», «әл-Игътикад» китаплары, әз-Зәһәбинең «әл-Гулүү» китабы һәм башкалар

## Зат һәм фигыль сыйфатлары

أما الذاتيةُ: فالحياة والقدرة والعلم والكلام والسمع والبصر والإرادة. وأما الفعليةُ: فالتخْليقُ والترزِيقُ والإنشاءُ والإبداعُ والصنعُ، وغيرُ ذلكِ من صفاتِ الفعلِ. لم يزلْ ولا يزالُ بصفاتِهِ، وأسماؤُهُ صفةٌ لهُ، لم يحدُثْ لهُ صفةٌ ولا اسمٌ

**Зат сыйфатлары: Тереклек (الحياة), кодрәт (القدرة), гыйлем (العلم), сөйләү (الكلام), ишетү (السمع), күрү (البصر), теләк (الإرادة)... Әмма фигыль сыйфатлары: халикъ кылу (التخليق), ризыкландыру (الترزيق), бар итү (الإِنْشَاء), булдыру (الإِبْدَاع), барлыкка китерү (الصّنع) һәм башка фигыль сыйфатлары. Ул Үзенең сыйфатларында вә исемнәрендә туктамады һәм туктамаячак, һәм Аның сыйфаты вә исеме яңармас**

---

**Төшенчәләр: (Халикъ кылу)** Мәхлукларны халикъ кылу. **(Ризыкландыру)** Барча нәрсәне ризыкландыру.

**Шәрех:** Шуннан соң Әбү Хәнифә рахимәһү Аллаһ кайбер зат сыйфатларын бәян итеп узды. Мәсәлән, тереклек сыйфаты хакында Коръәндә болай диелде:

وَتَوَكَّلْ عَلَى الْحَيِّ الَّذِي لا يَمُوتُ

Мәгънәсе: **«Бәлки һәрвакыт тере, һич үлми торган Раббыңа тәвәккәл ит!».** (Әл-Фуркан: 58)

(الْحَيّ الْقَيُّوم)

Мәгънәсе: **«Һәрвакыт тере, барча тереклекне тотып торучы».** (Әл-Бәкара: 255).

Сөйләү сыйфаты:

قَالَ يَا مُوسَى إِنِّي اصْطَفَيْتُكَ عَلَى النَّاسِ بِرِسَالاتِي وَبِكَلامِي

Мәгънәсе: **«Аллаһ Мусага әйтте: «Әй, Муса! Кешеләр арасыннан сине расүллек вә Үзем белән сөйләшүгә ихтыяр кылдым».** [Әл-Әгъраф: 144]

وَ كَلَّمَ مُوسَى تَكْلِيماً

Мәгънәсе: **«Һәм Аллаһ Муса белән (камил) сөйләшү белән сөйләште».** [Ән-Нисә: 164]

Кодрәт сыйфаты:

إِنَّ اللَّهَ عَلَى كُلِّ شَيْءٍ قَدِيرٌ

Мәгънәсе: **«Хакыйкатьтә, Аллаһ һәрнәрсәгә кадир».** [Әл-Бәкара: 20]

Ишетү һәм күрү сыйфаты:

إِنَّ اللَّهَ كَانَ سَمِيعًا بَصِيرًا

Мәгънәсе: **«Хакыйкатьтә, Аллаһ — Ишетүче, Күрүче».** [Ән-Нисә: 58]. Теләк сыйфаты:

فَمَنْ يُرِدِ اللَّهُ أَنْ يَهدِيَهُ يَشْرَحْ صَدْرَهُ لِلْإِسْلَام وَمَنْ
يُرِدْ أَنْ يُضِلَّهُ يَجْعَلْ صَدْرَهُ ضَيِّقًا حَرَجًا

Мәгънәсе: **«Аллаһ тәгалә, бер кешене һидәяткә — диндә туры юлга салырга теләсә, Ислам дине өчен аның күкрәген ачыр, янә Аллаһ, бер кешене хак диннән адаштырырга теләсә, ул кешенең күкрәген тар, кысык кылыр».** [Әл-Әнгам: 125]

Шулай ук, имам Әбү Хәнифә, кайбер фигыль сыйфатларын искә алып узды, мәсәлән халикъ кылу:

اللَّهُ خَالِقُ كُلِّ شَيْءٍ

Мәгънәсе: **«Хакыйкатьтә, Аллаһ барча нәрсәне халикъ кылучы».** [Әз-Зүмәр: 62]. Ризыкландыру сыйфаты:

وَمَا مِنْ دَابَّةٍ فِي الأَرْضِ إِلا عَلَى اللَّهِ رِزْقُهَا

Мәгънәсе: **«Җирдәге һәр җан иясенең ризыгы Аллаһ кулында».** (Һуд: 6). Бар итү (الإِنْشَاء) сыйфаты:

وَهُوَ الَّذِي أَنْشَأَ لَكُمُ السَّمْعَ وَالأَبْصَارَ وَالأَفْئِدَةَ

Мәгънәсе: **«Ул — Аллаһ, сезгә ишетүне, күрүне вә йөрәкне бар итте».** (Әл-Мүэминүн: 78). Булдыру (الإِبْدَاع) сыйфаты:

بَدِيعُ السَّمَاوَاتِ وَالأَرْضِ

Мәгънәсе: **«Ул — Аллаһ, күкләрне вә җирне булдырды».** (Әл-Әнгам: 101). Барлыкка китерү (الصّنع) сыйфаты:

وَتَرَى الْجِبَالَ تَحْسَبُهَا جَامِدَةً وَهِيَ تَمُرُّ مَرَّ السَّحَابِ صُنْعَ اللَّهِ الَّذِي أَتْقَنَ كُلَّ شَيْءٍ

Мәгънәсе: **«Син урыннарында таза торалар дип уйлаган тауларны ул көндә күрерсең, болытлар кебек күктә очып йөрерләр. Аллаһның, барча нәрсәне мөкәммәл итеп барлыкка китерүе шушылайдыр».** (Ән-Нәмел: 88)

Аллаһ тәгалә исемнәрендә вә сыйфатларында әүвәлге һәм бөтен исемнәре вә сыйфатлары бар иде, Аңа моңа кадәр булмаган исем дә, сыйфат та өстәлмәде.

**Кыскача нәтиҗә:**

Аллаһ бер һәм Аның затта да, фигыльләрендә дә, исемнәрендә дә һәм сыйфатларында да тиңдәше юк. Ул башлангычысыз әүвәлге, һәм Аның барча сыйфатлары да элек-электән мәңге Аныкы.

**Сораулар:**

1) Аллаһның барча нәрсәдән дә әүвәлге икәненә нинди дәлил китерә аласың?

2) Аллаһның сыйфатлары элек-электән мәңге Аныкы идеме, әллә яңадан бар булдымы?

3) Өч зат сыйфатын һәм өч фигыль сыйфатын әйтеп уз!

## Аллаһның сыйфатлары әзәлге[51]

لم يزلْ عالماً بعلمِهِ، والعلمُ صفتُهُ في الأزلِ. قادراً بقدرتِهِ، والقدرةُ صفةٌ لهُ في الأزَلِ. وخالِقاً بتخليقِهِ، والتخليقُ صفةٌ لهُ في الأزلِ. وفاعلاً بفعلِهِ، والفعلُ صفةٌ لهُ في الأزلِ، والفاعلُ هوَ اللهُ تعالى، والفعلُ صفتُهُ في الأزلِ، والمفعولُ مخلوقٌ، وفعلُ اللهِ تعالى غيرُ مخلوقٍ

**Гыйлеме белән галим булудан туктамады, һәм гыйлем әзәлге сыйфат. Кодрәте белән кадир булудан туктамады, һәм кодрәт әзәлге сыйфат. Сөйләве (кәләме) белән сөйләүче булудан туктамады, һәм сөйләү (кәләм) әзәлге сыйфат. Халикъ кылуы[52] белән халикъ (яратучы, булдыручы) булудан туктамады, һәм халикъ кылу әзәлге сыйфат. Фигыле[53] белән эш итүче булудан туктамады, һәм фигыль әзәлге сыйфат. Эш итүче, ул — *Аллаһ*! Фигыль әзәлге сыйфат, һәм мәфгульләр (эшләнгәннәр) алар мәхлуклар, ә *Аллаһның* фигыле мәхлук түгел**

---

**Төшенчәләр: (Әзәлге)** Элек-электән мәңге.

**Шәрех:**

Хакыйкатьтә, *Аллаһ* галим (белүче) һәм *Аннан* һичнәрсә дә яшеренеп кала алмый, һәм бу хакта *Ул* болай диде:

إِنَّ اللَّهَ عَالِمُ غَيْبِ السَّمَوَاتِ وَالأَرْضِ إِنَّهُ عَلِيمٌ بِذَاتِ الصُّدُورِ

---

51 Элек-электән мәңге

52 Яратуы, булдыруы

53 Эш, хәрәкәт, гамәл (урысча: действие)

Мәгънәсе: **«Хакыйкатьтә, Аллаһ күкләрдәге вә җирдәге яшерен нәрсәләрне белүче, вә Ул кешеләрнең күкрәкләре эчендәге нәрсәләрне шиксез белүче».** (Әл-Фәтыйр: 38)

إِنَّ اللَّهَ لا يَخْفَى عَلَيْهِ شَيْءٌ فِي الأَرْضِ وَلا فِي السَّمَاءِ

Мәгънәсе: **«Аллаһка, әлбәттә, җирдә һәм күкләрдә һичнәрсә яшерен түгел».** (Әли-Гыймран: 5)

Аллаһның гыйлеме, Аның затының сыйфаты һәм ул булмаганнан соң бар булган сыйфат түгел, ә бәлки әүвәлге вә әзәлге сыйфат. Кем дә кем, Аллаһ тәгалә Үзен барча нәрсәне дә белүче иткәнчегә кадәр белми иде, аннары Ул Үзен барча нәрсәне белүче иттерде дип әйтсә, мондый кеше диннән чыгып китеп, кәфер була. Чөнки, ул кеше Аллаһның билгеле сыйфатын инкяр итеп Аны кимчелек вә җитешсезлек белән пычраткан була.

❁ Аллаһ тәгалә барча нәрсәгә кадир, көче җитүче:

إِنَّ اللَّهَ عَلَى كُلِّ شَيْءٍ قَدِيرٌ

Мәгънәсе: **«Хакыйкатьтә, Аллаһ һәрнәрсәгә кадир».** (Әл-Бәкара: 20)

Аллаһны һичнәрсә гаҗиз итә алмас:

وَمَا كَانَ اللَّهُ لِيُعْجِزَهُ مِنْ شَيْءٍ فِي السَّمَوَاتِ وَلا فِي الأَرْضِ

Мәгънәсе: **«Җирдә вә күкләрдә Аллаһны һичбер нәрсә гаҗиз, көчсез итә алмый».** (Фәтыйр: 44)

Аллаһның кодрәте, зат сыйфаты һәм ул булмаганнан соң бар булган сыйфат түгел, ә бәлки әүвәлге вә әзәлге сыйфат. Кем дә кем, Аллаһ тәгалә башта кадир түгел иде, аннары Ул барча нәрсәгә кадир булды һәм бу сыйфатны Үзенә башта булмаганнан соң булдырды дип әйтсә, мондый кеше диннән чыгып китеп, кәфер була. Чөнки, ул кеше Аллаһның билгеле сыйфатын инкяр итеп Аны кимчелек вә җитешсезлек белән пычраткан була.

❁ Шулай ук, кәләм (сөйләү) сыйфаты да әүвәлге вә әзәлге сыйфат, һәм аның белән сөйләгәнче үк сыйфатланды.

وَ كَلَّمَ مُوسَى تَكْلِيماً

Мәгънәсе: **«Һәм Аллаһ Муса белән (камил) сөйләшү белән сөйләште».** (Ән-Нисә: 164)

وَ كَلَّمَهُ رَبُّهُ

Мәгънәсе: **«Һәм Раббысы аның белән сөйләште».** (Әл-Әграф: 143)

Аллаһ тәгалә нәрсә теләсә һәм кайчан теләсә, шулай сөйләшә һәм Ул сөйләүче булудан беркайчан да туктамады вә туктамаячак. Аның сөйләве кешеләрнекенә охшаш түгел, ә инде кем дә кем кәләм (сөйләү) сыйфатын инкяр итсә, ул кеше кәфер була.

❁ Аллаһның сыйфатларыннан, Ул фигыле белән эш итүче. Әгәр дә берәрнәрсә эшләргә теләсә, эшли. Һәм фигыль сыйфаты, әүвәлге вә әзәлге сыйфат. Теләгән нәрсәсен эш итүче булудан туктамады һәм туктамаячак.

فَعَّالٌ لِمَا يُرِيد

Мәгънәсе: **«Теләгән эшен кылучы».** (Әл-Бүруҗ: 16)

Кем дә кем бу сыйфатның Аллаһныкы булуын инкяр итсә, кәфер була. Фигыль әзәлге сыйфат һәм мәфгульләр (эшләнгәннәр) алар мәхлуклар, ә Аллаһның фигыле мәхлук түгел.

❁ Шулай ук, Аның сыйфатларыннан, Ул барча нәрсәне халикъ кылучы һәм ул әүвәлге вә әзәлге сыйфат.

اللَّهُ خَالِقُ كُلِّ شَيْءٍ

Мәгънәсе: **«Аллаһ барча нәрсәне халикъ кылучы».** (Әз-Зүмәр: 62)

# Коръән хакында сүз

وصفاتُهُ في الأزلِ غيرُ محدثةٍ ولا مخلوقةٍ، فمن قالَ إنها مخلوقةٌ أو محدثةٌ أو وقفَ أو شكَ فيها فهوَ كافرٌ باللهِ و القرآنُ كلامُ اللهِ تعالى في المصاحِفِ مكتوبٌ، وفي القلوبِ محفوظٌ، وعلى الألسُنِ مقروءٌ، وعلى النبيِّ عليهِ الصلاةُ والسلامُ مُنـزَّلٌ، ولفظُنا بالقرءانِ مخلوقٌ، وكتابتُنا لهُ مخلوقةٌ، وقراءتُنا لهُ مخلوقةٌ، والقرءانُ غيرُ مخلوقٍ

**Аның сыйфатлары әзәлдә. Ясалган да, мәхлук та түгел. Кем дә кем ул сыйфатлар мәхлук яки ясалган дисә, яки ул сыйфатларда дәшми калса яки шикләнсә, ул кеше Аллаһка көферлек кылган була. Коръән – Аллаһ тәгаләнең кәләме[54], мусхафларда[55] язылган, йөрәкләрдә сакланылган, телләрдә укылган һәм пәйгамбәргә иңдерелгән. Безнең Коръән белән ләфызыбыз, безнең язуыбыз һәм укуыбыз – мәхлуклар, ә Коръән – мәхлук түгел.**

---

**Төшенчәләр: (Ләфыз)** сүз

**Шәрех:**

❁ Имам Тахауий үзенең гакыйдә китабында болай диде: ***«Юктан бар итүдән элек, Аллаһның бөтен сыйфатлары әүвәлдән бар иде һәм нәрсәне булса да яратканнан соң Аңа моңа кадәр булмаган сыйфат өстәлмәде. Бу сыйфатлар элек-электән мәңге Аныкы булган кебек, киләчәктә дә мәңге Аныкы булып кала. Аллаһ тәгалә булмаган әйберләрне халикъ кылганнан соң гына «Халикъ кылучы (الخالق)» исеме белән аталмады һәм мәхлукатны булдырганнан соң гына «Булдыручы (الباري)» исемнә лаек***

54 Сүзе
55 Китапларда

***булмады. Аңа тәрбияләнүче түгел, ә тәрбияче сыйфаты хас. Мәхлук түгел, ә халикъ кылучы сыйфаты хас. Ул, беренче тапкыр тергезгән кебек мәетләрне кабат тергезүче һәм бу исемгә Ул аларны тергезгәнче үк лаек иде. Шулай ук, Халикъ кылучы исеменә Ул мәхлукларны бар кылганчы лаек булды.***

Аллаһ тәгаләнең барча сыйфатлары да әзәлге, ясалган да, мәхлук та түгелләр. Кем дә кем ул сыйфатлар мәхлук яки ясалган дисә, яки ул сыйфатларда дәшми калса яки шикләнсә, ул кеше Аллаһка көферлек кылган була.

۞ Коръән, Аллаһ тәгаләнең сүзе һәм бу хакта Ул болай диде:

وَإِنْ أَحَدٌ مِنَ الْمُشْرِكِينَ اسْتَجَارَكَ فَأَجِرْهُ حَتَّى يَسْمَعَ كَلامَ اللَّهِ ثُمَّ أَبْلِغْهُ مَأْمَنَهُ

Мәгънәсе: **«Әгәр дә берәр мөшрик килеп синнән иминлек хокукы сораса, Аллаһ тәгаләнең сүзләрен ишетсен өчен аңа иминлек бир. Аннары аны куркынычсыз урынга ирештереп куй».** (Әт-Тәүбә: 6)

Хаклыкта вә дөрес юлда булган барча кемсәләр дә Коръәннең Аллаһ сүзе икәнлегенә, ә кем аны инкяр итсә кәфер булуына килештеләр. Ул, мосхафларда язылган, йөрәкләрдә сакланылган, телләрдә укылган һәм пәйгамбәребезгә ﷺ иңдерелгән, һәм туры юлда булучылар ошбу караshта.

وَإِنَّهُ لَتَنزِيلُ رَبِّ الْعَالَمِينَ ۞ نزلَ بِهِ الرُّوحُ الأَمِينُ ۞ عَلَى قَلْبِكَ لِتَكُونَ مِنَ الْمُنْذِرِينَ ۞ بِلِسَانٍ عَرَبِيٍّ مُبِينٍ

Мәгънәсе: **«Бу Коръән галәмнәрне тәрбия итүче Аллаһтан иңдерелгән Китап, аның белән имин булган Җәбраил фәрештә инде. Ул Җәбраил Коръәнне синең йөрәгеңә иңдерде, кешеләрне Аллаһ газабы белән куркытучы булмаклыгың өчен. Коръән ачык итеп гарәп телендә иңдерелде».** (Әш-Шүгара: 192-195)

تَبَارَكَ الَّذِي نزلَ الْفُرْقَانَ عَلَى عَبْدِهِ لِيَكُونَ لِلْعَالَمِينَ نَذِيرًا

Мәгънәсе: **«Галәмнәргә нәзир[56] булсын өчен, Үзенең колы Мөхәммәдкә ﷺ хаклык белән батыл арасын аера торган Коръәнне иңдерүче Аллаһ һәрнәрсәдән мөбәрак булды».** (Әл-Фүркан: 1)

Коръән укыганда укучының тавыш белән әйтүе — аның фигыле. Укучының тавышы, теленең хәрәкәте — мәхлук. Коръән язучының язуы, колның фигыле буларак — мәхлук. Укучының укуы, колның фигыле буларак — мәхлук. Ә Коръән үзе мәхлук түгел, бәлки ул Аллаһның сүзе.

**«Безнең Коръән белән ләфызыбыз — мәхлук»** — дигәне, сөннәт әһелләре юлы түгел, бәлки кәләм әһелләре юлы һәм бу сүзләр Әбү Хәнифә рахимәһү Аллаһ сүзләре түгел, чөнки **«тавыш белән әйтү (اللفظ)»** мәсьәләсе ибен Күлләб[57]: ***«Аллаһ тәгаләнең сүзе, Аның затында булган ишетелми торган бер мәгънә, эчке сүз (الكلام النفسي)»***, — дигәннән соң гына барлыкка килде.

Имам Тахауий үзенең гакыйдә китабында болай диде: ***«Хакыйкатьтә, Коръән — Аллаһ сүзе, Аннан без белмәгән рәвештә сүз булып чыкты һәм Ул аны илчесенә вәхи итеп иңдерде. Мөэминнәр аның дөрес, хак булуын, чын Аллаһ сүзе икәнлеген, кеше сүзе кебек мәхлук түгеллеген таныдылар вә расладылар. Ә Коръәнне ишетеп, аны кеше сүзе дип уйлаучы — кәфер булды. Андый кешене Аллаһ шелтәләде, кисәтте һәм Сәкар тәмугына салырга вәгъдә итте:***

سَأُصْلِيهِ سَقَرَ

Мәгънәсе: **«Тиздән аны Сәкар тәмугына салырмын».** (Әл-Мүдәссир: 26)

***Һәм бу вәгъдә:***

---

56 Аллаһ газабы белән куркытучы, кисәтүче

57 Габдуллаһ бин Сәгыйд бин Күлләб. Һиҗри тәкъүим буенча 240нчы елдан соң вафат була. Ул үз вакытында Басра шәһәрендә мүтәкәллимнәрнең башлыгы булып тора.

إِنْ هَذَا إِلا قَوْلُ الْبَشَرِ

Мәгънәсе: **«Бу Коръән кеше сүзе генә».** (Әл-Мүдәссир: 25) ***— дип әйтүчегә тиешле булды. Без, Коръән кешеләрне Халикъ кылучының сүзе икәненә, һәм кеше сүзенә охшамаганлыгына ныклы инандык».***

وما ذكرَهُ اللهُ في القرءانِ حكايةً عن موسى وغيرِهِ منَ الأنبياءِ، وعن فِرْعَوْنَ وإبليسَ، فإنَّ ذلك كلّه كلامُ اللهِ تعالى إخباراً عنهم، وكلامُ اللهِ تعالى غيرُ مخلوق وكلامُ موسى وغيرِهِ منَ المخلوقينَ مخلوقٌ، والقرءانُ كلامُ اللهِ تعالى فهوَ قديمٌ، لاَ كلامُهُم. وسمِعَ موسى كلامَ اللهِ تعالى:{ وكلَّمَ اللهُ موسى تكليماً}

**Аллаһ тәгаләКорьәндә Муса, башка пәйгамбәрләр, фиргавен вә иблис турында сөйләве, болар бар-сы да, алар хакында хәбәр итүче Аллаһ тәгаләнең сүзе. Аллаһ тәгаләнең сүзе мәхлук түгел, ә Мусаның һәм башкаларның сүзләре — мәхлуклар. Корьән — Аллаһ тәгаләнең сүзе һәм ул — элек-электән мәңге, ә аларныкы — юк. Һәм Муса ﷺ Аллаһ тәгаләнең сүзен ишетте:**

وَ كَلَّمَ مُوسَى تَكْلِيماً

Мәгънәсе: **«Һәм Аллаһ Муса белән (камил) сөйләшү белән сөйләште»**[58]

---

**Төшенчәләр:**

**Шәрех:** Аллаһ тәгалә Корьәндә Муса ﷺ яки башка пәйгамбәрләр хакында хикәят итеп искә алган сүзләр, алар әйткән сүзләр. Яки, Корьәндә фиргавен сүзенең төреннән булган:

أَنَا رَبُّكُمُ الأَعْلَى

**«Мин сезнең бөек раббыгыз»**[59]

Һәм иблис сүзеннән булган:

مَا نَهَاكُمَا رَبُّكُمَا عَنْ هَذِهِ الشَّجَرَةِ إِلَّا أَنْ تَكُونَا مَلَكَيْنِ

**«Раббыгыз сезне бу агачтан иллә-мәгәр сез фәрештәләр булмас өчен генә тыйды...»**[60]

58 ән-Нисә 164
59 ән-Нәзигат 24
60 әл-Әгьраф 20

дигән сүзләр һәм шулай ук, расүлләрен ялганга чыгарып сөйләгән башка өммәтләрнең барча сүзләре, боларның барысын да Аллаһ тәгалә алар хакында хәбәр итеп хикәят кылды. Аллаһның сүзе мәхлук түгел, әмма Мусаның ﷷ үзе әйткән вакытындагы сүзе, һәм фиргавеннең, иблиснең вә башка мәхлукларның сүзләре — алар барысы да мәхлук, чөнки колларның фигыльләре мәхлук, ләкин Аллаһ тәгаләнең алар хакында сөйләве — Аның сүзләре, ә Аллаһның сүзләре мәхлук түгел. Кем дә кем Коръәндә бер генә хәреф булса да мәхлук дип уйласа, Ул кеше Аллаһка көферлек кылган була.

Аллаһ тәгалә Муса ﷷ белән сөйләшкәндә, Муса Аның сүзләрен үзенең колаклары белән чынлыкта ишетте,

وَ كَلَّمَ مُوسَى تَكْلِيماً

Мәгънәсе: **«Һәм Аллаһ Муса белән (камил) сөйләшү белән сөйләште»**[61]

وَلَمَّا جَاءَ مُوسَى لِمِيقَاتِنَا وَكَلَّمَهُ رَبُّهُ

Мәгънәсе: **«Һәм Муса Без билгеләгән микатькә килгәч, Раббысы аның белән сөйләште»**[62]

Һәм ул хакыйкый сүз, тавыш вә хәреф белән. Муса ﷷ аны чынлыкта ишетте.

**Кыскача нәтиҗә:**

Аллаһ әзәлдә (элек-электән мәңге) бар нәрсәне белүче, әзәлдә бар нәрсәгә кадир, әзәлдә сөйләүче һәм әзәлдә халикъ кылучы. Коръән — Аллаһның сүзе һәм ул мәхлук түгел. Аллаһ тәгалә Коръәндә мәхлукатлардан хикәят кылган сүзләр, Аның алар хакында хәбәр иткән сүзләре.

**Сораулар:**

1) Коръән мәхлукмы? Һәм аны мәхлук дип әйтүченең хөкеме нинди?

2) Аллаһ тәгалә Коръәндә кәферләр хакында хикәят кылган сүзләр Аныкымы әллә юкмы?

61 ән-Нисә 164
62 әл-Әгъраф 143

وقدْ كانَ اللهُ تعالى متكلماً، ولم يكُنْ كلمَ موسى، وقدْ كانَ اللهُ تعالى خالقاً في الأزلِ ولم يخلقْ الخلقَ، فلما كلمَ اللهُ موسى، كلمَهُ بكلامِهِ الذي هوَ لهُ صفةٌ في الأزلِ، وصفاتُهُ كلُها بخلافِ صفاتِ المخلوقينَ، يعلمُ لا كعلمِنا، يَقْدِرُ لا كقدرَتِنا، يَرَى لا كرؤيَتِنا

**Аллаһ тәгалә Муса белән сөйләшкәнче үк, Ул мөтәкәллим (сөйләүче) иде, шулай ук, Аллаһ тәгалә мәхлукларны халикъ кылганчы ук, әзәлдә (элек-электән мәңге) халикъ кылучы иде. Ә инде Аллаһ Муса белән сөйләшкәндә, Ул Үзенең әзәлдә булган сүз сыйфаты илә сөйләште. Аның барча сыйфатлары да мәхлукларның сыйфатларыннан аермалы; Ул белә — безнең белүебез кебек түгел, Ул кодрәтле — безнең кодрәтебез кебек түгел, Ул күрә — безнең күрүебез кебек түгел,**

---

**Төшенчәләр:**

**Шәрех:** Аллаһ тәгалә Муса белән сөйләшкәнче үк инде мөтәкәллим (сөйләүче) иде, чөнки кәләм (сүз) Аның әзәл (элек-электән мәңге) сыйфаты. Аллаһ чын-хакыйкый сүз илә сөйләүче, һәм Аның кәләме (сүзе) мәхлукларныкы кебек түгел. Ул Үзе теләгән вакытында сөйләште һәм сөйләшә, Муса белән сөйләшкәнче вә аннан соң да Ул мөтәкәллим (сөйләүче). Кәләм сыйфаты Анда булмаганнан соң барлыкка килмәде, Муса белән сөйләгәндә дә Ул Үзенең әзәл (элек-электән мәңге) булган сүз сыйфаты белән сөйләште һәм Муса Аны чынлыкта ишетте.

Һәм шушылай, Аллаһ тәгаләнең барча сыйфатлары да әзәлге (элек-электән мәңге) һәм алар мәхлукларның сыйфатларына охшаш түгел, Аллаһ әйтте:

لَيْسَ كَمِثْلِهِ شَيْءٌ وَهُوَ السَّمِيعُ الْبَصِيرُ

Мәгънәсе: **«Аллаһка охшаган һичнәрсә юк, вә Ул Ишетүче, Күрүче»**[63]

---

63 әш-Шура 11

Кем дә кем Аллаһ тәгаләнең сыйфатлары мәхлукларның сыйфатлары кебек дип уйласа, һәм Аллаһ тәгалә мәхлукларның берәрсенә охшаган дип уйласа яки берәрсе Аңа охшаган дип уйласа, ул кеше Бөек Аллаһка көферлек кылучы кәфер була.

Аллаһның барча сыйфатлары да әзәлге (элек-электән мәңге) һәм алар чын-хакыйкый мәгънәгә күрсәтә, ләкин ничеклеге Аллаһ тәгаләгә хас һәм бу ничеклекнең чынлыгын-хакыйкатен Аллаһтан башка белүче юк, бәлки Аллаһ тәгалә аңа Үзенең гыйлеме белән хуҗа булды.

Аллаһ тәгалә барча нәрсәне белә; кечкенәне вә зурны, кисәкчек-бөртекләрне һәм тулы-бөтенне:

إِنَّ اللَّهَ بِكُلِّ شَيْءٍ عَلِيمٌ

Мәгънәсе: **«Дөреслектә, Аллаһ барча нәрсәне белүче»[64]**

Аллаһның гыйлеме мәхлукларның гыйлеменә караганда камил гыйлем — Аннан һичнәрсә гаеп[65] булмый, мотлак[66] гыйлем — Аннан кечкенә генә бөртек тә яшеренеп калмый. Дөреслектә, мәхлуклардан һичнәрсә Аллаһка охшаш түгел; Аның сыйфаты мәхлуклар сыйфаты кебек түгел, Аллаһ тәгалә кадир һәм Аның кодрәте мотлак кодрәт, Аны һичнәрсә гаҗиз итә алмый:

إِنَّ اللَّهَ عَلَى كُلِّ شَيْءٍ قَدِيرٌ

Мәгънәсе: **«Хакыйкатьтә, Аллаһ һәрнәрсәгә кадир»[67]**

Аның кодрәте мәхлукларныкы кебек түгел.

Аллаһ сөбханәһү вә тәгалә бар нәрсәне күрә һәм Аңа мәхлукларының бернәрсәсе дә яшерен булып калмый:

قَالَ لَا تَخَافَا إِنَّنِي مَعَكُمَا أَسْمَعُ وَأَرَى

---

64 эл-Мүҗәдәлә 7

65 Яшерен

66 Һичшиксез, абсолют рәвештә

67 эл-Бәкара 20

Мәгънәсе: **«Әйтте: Курыкмагыз! Хакыйкатьтә, Мин сезнең белән, Ишетәм һәм Күрәм»**[68]

Аллаһ тәгаләнең күрү сыйфаты хакыйкый мәгънәгә күрсәтсә дә, мәхлукларның күрү сыйфаты кебек түгел, һәм аның ничеклеген Аллаһтан башка белүче юк. Һәм шушылай, Аның барча сыйфатлары да, Аннан башка аларның ничеклеген белүче юк, иллә-мәгәр Аллаһ Үзе генә белә, һәм Аллаһ тәгалә аңа Үзенең гыйлеме белән хуҗа булды.

68 әл-Бәкара 20

يتكلمُ لا ككلامِنا، ويسمعُ لا كسمعِنا. نحنُ نتكلمُ بالآلاتِ والحروفِ، واللهُ تعالى يتكلمُ بلا حروفٍ ولا آلةٍ. والحروفُ مخلوقةٌ، وكلامُ اللهِ تعالى غيرُ مخلوقٍ، وهو شيءٌ لا كالأشياءِ، ومعنى الشيءِ إثباتُهُ بلا جسمٍ ولا جوهرٍ ولا عَرَضٍ، ولا حدَّ لهُ، ولا ضدَّ لهُ، ولا ندَّ له، ولا مِثْلَ لهُ

**Ул сөйләшә — безнең сөйләшүебез кебек түгел, Ул ишетә — безнең ишетүебез кебек түгел. Без сөйләү әгъзалары һәм хәрефләр ярдәмендә сөйләшәбез, ә Аллаһ тәгалә бернинди матдәсез һәм хәрефсез сөйләшә. Хәрефләр мәхлук, ә Аллаһ тәгаләнең кәләме (сүзе) мәхлук түгел. Ул — шәй, башка шәйләр кебек түгел. Шәйнең мәгънәсе, Ул җисемсез, җәүһәрсез[69], гарадсыз[70] сабит булуы, һәм Аның билгеләмәсе (чиге), капма-каршысы, тиңе вә охшашы юк**

---

**Төшенчәләр: (Җәүһәр)** Бер нәрсәнең җәүһәре — аның заты, хакыйкате. Фәлсәфәчеләрдә, башка нәрсәгә мохтаҗ булмыйча үзеннән-үзе торган әйберне аңлата. **(Гарад)** Җәүһәрнең капма-каршысы, ягъни башка нәрсә ярдәмендә торган әйберне аңлата.

**Шәрех:** Аллаһ тәгалә сөйли, ләкин кешеләрнең кәләме кебек түгел, бәлки Аның кәләме Үзенә генә хас ничеклектә. Ул ишетә, ләкин кешеләрнең ишетүе кебек түгел, бәлки Аның Үзенә генә хас рәвештә.

Әмма: **«Аллаһ тәгалә бернинди коралсыз һәм хәрефсез сөйләшә. Хәрефләр мәхлук»,** — дигән сүзләр, болар һич тә Әбү Хәнифәнең رضي الله عنه сүзләре түгел, ә Коръән мәхлук дип сөйләгән мөтәкәллимнәрнең бидгате. Чөнки Коръән хәрефләре мәхлук дигән бидгәть караш «эчке сүз» (الكلام النفسي) дигән бидгать карашка бәйләнеп төзелгән. Ә бидгать булган «эчке сүз» карашы, һиҗри җәдвәл буенча 150нче елны вафат булган Әбү Хәнифә заманында булмады, бәлки ул караш һиҗри буенча 241нче елда ибен

69 Субстанциясыз
70 Акциденциясыз

Күлләб заманында булды. Аннары, әһлүс-сүннәһ вәл-җәмәгаһ гакыйдәсе буенча, Коръән барча хәрефләре белән Аллаһның сүзе, Ул Үзенең тавышы вә хәрефләре белән сөйләде. Аның кәләме мәхлукларның кәләме кебек булмаган кебек, шулай ук тавышы да мәхлукларның тавышы кебек түгел, һәм кәләм иллә-мәгәр хәреф һәм тавыш белән генә була.

Әмма: **«җисемсез, җәүһәрсез, гарадсыз...»,** — дигән сүзләр, шулай ук Әбү Хәнифәнең сүзләре түгел, ә мөтәкәллимнәрнең сүзләреннән. Бу сүзләргә инкяр белән дә, исбат белән дә җавап бирелми, ә бәлки аңа дәшмәү җавап була.

**Кыскача нәтиҗә:**

Аллаһ тәгалә Үзе теләгән вакытта һәм Үзе теләгәнчә без белмәгән рәвештә (ничек дигән сораусыз) сөйләшә. Аның сүзе башкаларның сүзенә охшаш түгел, Ул тавыш вә хәреф илә сөйләшә һәм Аның кәләме-сүзе мәхлук түгел.

**Сораулар:**

1) Аллаһ тәгалә сүзенең тәгаенләнгән рәвеше бармы?

2) Аллаһ тәгаләнең сүзе тавыш һәм хәреф беләнме, әллә юкмы?

3) Аллаһ сүзен мәхлуклар сүзе белән охшатучының хөкеме нинди?

# Сыйфатлар хакында сүз

ولهُ يدٌ ووجهٌ ونفسٌ كما ذكرَهُ اللهُ تعالى في القرءانِ، فما ذكرَهُ اللهُ تعالى في القرءانِ، منْ ذكرِ الوجهِ واليدِ والنفسِ فهو لهُ صفةٌ بلا كيفٍ، ولا يقالُ إنّ يدَهُ قدرتُهُ أو نعمتُهُ، لأنَّ فيهِ إبطالُ الصفةِ، وهوَ قولُ أهلِ القَدَرِ والإعتزالِ، ولكنْ يدُهُ صفتُهُ بلا كيفٍ، وغضبُهُ ورضاهُ صفتانِ من صفاتِهِ بلا كيفٍ

**Аллаһ тәгаләә Коръәндә искә алып узганча, Аның кулы, йөзе һәм нәфсе бар. Ул Коръәндә искә алып узган йөз, кул һәм нәфс — болар барсы да, «ничек» дигән сораусыз Аның сыйфатлары. Аның кулы, ул — Аның кодрәте яки нигъмәте дип әйтелми, чөнки болай әйтүдә сыйфатны инкяр итү вә юкка чыгару була, ә бу кадарийлар һәм мөгтәзиләләрнең карашы. Ләкин, Аның кулы — «ничек» дигән сораусыз Аның сыйфаты, Аның ачуы һәм ризасы – «ничек» дигән сораусыз Аллаһ тәгаләнең сыфатларыннан булган ике сыйфат**

---

**Төшенчәләр: (Кадарийлар)** Ислам диненә япсарылган, гакыйдәдә ялгыш карашлар, күзаллаулар һәм тәкъдирдә хата аңлаулар белән билгеле булган мөтәкәллимнәрнең бер төркеме. Алар кешеләрнең гамәлләрен үз көч-кодрәтләренә бәйләп, Аллаһ тәгаләнең монда бер катнашы да юк диләр. Шулай ук, сыйфатларда да бик күп хаталар белән билгеле булдылар. **(Мөгтәзиләләр)** әл-Үмәүий чоры ахырында башланып Габбасилар чорында ныгый. Алар кайбер фәлсәфәләр белән тәэсирләнеп Ислам гакыйдәсен аңлауда коры гакылга гына таяналар, һәм бу аларны әһлүс-сүннәһ вәлҗәмәгаһ гакыйдәсеннән читләштереп адаштыра. Алар-

га шулай ук төрле исем-атамалар бирәләр: кадарийлар, гадлиләр, гадел һәм тәүхид әһелләре, үәгыйдияләр һ.б.

**Шәрех:** Аллаһ тәгалә Коръәндә Үзенә кул сыйфатын билгеләде:

يَدُ اللَّهِ فَوْقَ أَيْدِيهِمْ

Мәгънәсе: **«Аллаһның кулы — аларның кулы өстендә»**[71]

һәм йөз сыйфатын билгеләде:

كُلُّ شَيْءٍ هَالِكٌ إِلَّا وَجْهَهُ

Мәгънәсе: **«Аның йөзеннән башка, һәрнәрсә һәлак булучы»**[72]

һәм нәфс сыйфатын билгеләде:

وَيُحَذِّرُكُمُ اللَّهُ نَفْسَهُ

Мәгънәсе: **«Аллаһ сезне Үзенең нәфсеннән кисәтә»**[73]

Барча бу сыйфатлар да Аллаһ тәгаләгә «ничек» дигән сораусыз билгеләнде. Аллаһ тәгалә Үзенә сыйфат билгеләде һәм безгә дә Аңа ул сыйфатларны билгеләү тиешле. Ул безгә ничеклеген искә алмады, шулай булгач без ул хакта дәшмәскә тиеш, чөнки ул Аллаһка гына билгеле булган яшерен гыйлем. Кешеләр арасында кайбер төркемнәр адашып Аның сыйфатларын хакыйкатьтән-чынлыктан чыгарып тәэүил кылдылар һәм кул ул — кодрәт яки нигъмәт вә ихсән диделәр. Әбү Хәнифә боларны инкяр итте, чөнки сыйфатларны тәэүил кылу аларны инкяр итү вә юкка чыгару була һәм бу кадария-мөгтәзиләләрнең карашы дип бәян итте. Шулай ук, ул кул сыйфаты «ничек» дигән сораусыз Аллаһ тәгаләнең хакыйкый-чын сыйфаты икәнлеген һәм ачу вә риза да шулай ук Аның сыйфатларыннан булган «ничек» дигән сораусыз ике сыйфаты икәнлеген бәян итте.

---

71 әл-Фәтех 10
72 әл-Касас 88
73 әли Гыймран 28

Аллаһ тәгалә ачу сыйфатын белгеләп болай диде:

وَغَضِبَ اللَّهُ عَلَيْهِ وَلَعَنَهُ وَأَعَدَّ لَهُ عَذَابًا عَظِيمًا

Мәгънәсе: **«Аллаһ аңа ачуланды һәм аңа олы газаб хәззерләде»**[74]

Һәм риза сыйфатын белгеләп болай диде:

رَضِيَ اللَّهُ عَنْهُمْ وَرَضُوا عَنْهُ

Мәгънәсе: **«Аллаһ алардан риза булды һәм алар Аннан риза булдылар»**[75]

Болар Әбү Хәнифәнең ﵁ ысулы вә сыйфатлар мәсьәләсендә аның мәзһәбе ап-ачык, һәм ул ошбуларны үзенә ала:

а) Аллаһның Коръәндә һәм Сөннәттә килгән барча сыйфатлары вә исемнәре бернинди охшатусыз вә үзгәртүсез кабул ителергә тиеш.

б) Сыйфатны икенче сыйфат белән тәэүил кылырга ярамый.

в) Кем дә кем бер сыйфатны икенче сыйфат белән тәэүил кылса, ул аны үзгәртте һәм бозды.

**Кыскача нәтиҗә:**

Аллаһ тәгалә сыйфатлары, аларны чын-хакыйкый мәгънәсеннән чыгара торган бернинди тәэүилләрсез һәм бернинди бозусыз вә тәгаенле рәвешсез, ничек-бар шулай кабул ителергә тиеш.

**Сораулар:**

1) Әһлүс-сүннәһ вәл-җәмәгаһның Аллаһ тәгаләнең сыйфатларында булган ысул-юлы нинди?

2) Исемнәр вә сыйфатлар бүлегендә иң адашкан төркемнәр кемнәр?

3) Аллаһ тәгалә сыйфатларын тәэүил кылган кешенең хөкеме нинди?

---

74 ән-Нисә 93

75 әл-Бәийнә 8

# Тәкъдир хакында сүз

خلقَ اللهُ تعالى الأشياءَ لا منْ شىءٍ، وكانَ اللهُ تعالى عالماً في الأزَلِ بالأشياءِ قبلَ كونِـها، وهوَ الذي قدّرَ الأشياءَ وقضاها، ولا يكونُ في الدنيا ولا في الآخرةِ شىءٌ إلا بمشيئتِهِ وعلمِهِ وقضائِهِ وقدرِهِ وكتْبِهِ في اللوحِ المحفوظِ ولكنْ كتبُهُ بالوصفِ لا بالحكم. والقضاءُ والقدرُ والمشيئةُ صفاتُهُ في الأزلِ بلا كيفٍ، يعلمُ اللهُ تعالى المعدومَ في حالِ عدمِهِ معدوماً، ويعلمُ أنهُ كيفَ يكونُ إذا أوجدَهُ، ويعلمُ اللهُ تعالى الموجودَ في حالِ وجودِهِ موجوداً، ويعلمُ أنهُ كيفَ يكونُ فناؤُهُ، ويعلمُ اللهُ تعالى القائمَ في حالِ قيامِهِ قائماً، وإذا قعَدَ عَلِمَهُ قاعداً في حالِ قعودِهِ منْ غيرِ أنْ يتغيرَ علمُهُ، أو يحدُثَ لهُ علمٌ، ولكنّ التغيرُ واختلافَ الأحوالِ يحدثُ في المخلوقينَ

**Аллаһ тәгалә (барча) нәрсәне юктан халикъ кылды һәм ул нәрсәләр булганчы ук Аллаһ алар хакында әзәлдә (элек-электән мәңге) белүче иде, һәм Ул аларны тәкъдир вә када кылды. Бу дөньяда да, ахирәттә дә Аның теләгеннән, гыйлеменнән, кадасыннан, тәкъдиреннән вә әл-Ләүх әл-Мәхфузда язуыннан башка һичнәрсә дә булмый. Ләкин, Ул аны анда әмер итеп түгел, ә сыйфатлап язды. Када, тәкъдир вә теләк — «ничек» дигән сораусыз, Аның әзәлдәге (элек-электән мәңге) сыйфатлары. Аллаһ тәгалә юкны, аның юк хәләтендә — булмаганда белә, һәм әгәр аны булдырса, ничек булганлыгын белә. Аллаһ барны, аның бар хәләтендә булганда белә һәм аның ничек бетүен белә. Аллаһ басып торучыны, аның басып торган хәләтендә басып торганда белә, ә әгәр ул утырса аның утырган хәләтен утыручы итеп белә, һәм бу Аллаһның гыйлемендә бернинди үзгәреш тә вә яңарыш та чагылдырмый. Чөнки, үзгәреш вә төрләнү-алышыну мәхлукларда гына чагыла**

**Төшенчәләр: (Тәкъдир һәм када)** Боларның аермасын билгеләүдә гыйлем ияләре төрле карашларга аерылдылар һәм ике төркемгә бүленделәр. Берәүләре, тәкъдир белән када арасында бернинди дә аерма юк, икесе дә бер мәгънәдә диделәр, һәм бу караш дөресрәк дип табылды. Чөнки аларны аеручыларның Коръәннән һәм сөннәттән бернинди дә ачык кына дәлилләре юк, шулай ук берсе урынына икенчесен куллану аларның аермалары юк дигәнне билгели һәм аларны аерудан бер файда да юк. Икенчеләр, бу сүзләрне аеручылар аларны аңлатуда зур капма-каршылыкларга керделәр, һәм алар аңлатканның иң яхшысы: када, ул — булганга (трмышка ашканга) әйтелә, ә тәкъдир (кадар) — әле булмаганга (әле тормышка ашмаганга) әйтелә. Аллаһү әгъләм.

**Шәрех:** *Аллаһ* тәгалә әйберләрне нәрсәдәндер түгел, ә юктан халикъ кылды һәм *Ул* бернәрсәгә дә мохтаҗ түгел. *Аллаһ* тәгаләнең барча нәрсәләрне белә торган гыйлеме, бу нәрсәләр булганчы кадим әзәлге (элек-электән мәңге) гыйлем, һәм *Аның* әзәлге гыйлеме хакында сүз булды инде. *Аллаһ* барча нәрсәләрне тәкъдир вә када кылды, ягъни әүвәлге бүлекләрдә аңлатылганча, *Ул* аларны белде, аннары язды, аннары теләде һәм бар итеп халикъ кылды. Барча бар яки юк нәрсә — *Аллаһ*ның када вә тәкъдире белән, һәм бу дөньяда да яки ахирәттә дә бернәрсә дә *Аның* теләге, гыйлеме, кадасы вә тәкъдиреннән башка булмый. *Аллаһ* тәгалә бу нәрсәләрне тәкъдир вә када кылды, һәм аларны *Үзенең* белгән гыйлеме рәвешендә булуын теләде, һәм аларны әл-*Ләүх* әл-Мәхфузда язды. *Аллаһ ул* нәрсәләрне әмер итеп, ягъни мәсәлән (Зәйд мөэмин булсын) дигән кебек кенә язмады, чөнки болай гына булуы *Аннан* җәберлек дип уйланыр иде. *Аллаһ* әмер иткән барча нәрсә, ул шиксез була. Бәлки, *Ул* аларны әл-*Ләүх* әл-Мәхфузда ничек булачагын сыйфатлап язды.

Када, тәкъдир һәм теләк — барчасы да «ничек» дигән сораусыз әзәлге (элек-электән мәңге) сыйфатлар. *Аллаһ*

тәгалә булмаган-юк нәрсәләрне һәм аларның ничек икәнлеген белде. Шулай ук, әгәр дә Ул аларны ничек кенә бар итсә дә, булганлыгын белде. Аллаһ бар-булган нәрсәләрне булган хәләтләрендә аларның ничеклеген белде. Аллаһ барча нәрсәләрнең бетү тәкъдире җиткәч, ничек беткәнлекләрен белде, һәм Ул басып торучының басып торган хәләтендә аның ничеклеген белде. Әгәр дә бу басып торучы утырса, Аллаһ аның утырган хәләтен утырганда һәм утырганчы белде. Болар барчасы да Аңа, гыйлеме үзгәрмичә һәм булмаганнан соң барлыкка килеп яңармыйча билгеле, чөнки Аның гыйлеме әзәлге (элек-электән мәңге). Аллаһ тәгаләнең гыйлеме барча нәрсәгә кадәр һәм ул мәхлук түгел. Дөреслектә, үзгәрешләр вә төрләнү-алышынулар (белмәгәннән соң белүләр) мәхлукларда була, ә халикъ кылучыда һәм Аның сыйфатларында ул нәрсәләрнең булуы мөмкин түгел. Алда әйтеп узганыбызча, күп кенә гыйбарәләр (әйтемнәр) сәләфләр вакытында һәм Әбү Хәнифә заманында юк иде, һәм алар мөтәкәллимнәр тарафыннан кертелгән әйтемнәр булуы бик тә ихтимал.

**Кыскача нәтиҗә:**

Аллаһ тәгалә барча нәрсәләрне юктан халикъ кылды, һәм бу яшәештә Аның рөхсәтеннән вә халикъ кылуыннан башка һичнәрсәдә дә була алмый.

**Сораулар:**

1) Аллаһ барча әйберләрне нәрсәдән халикъ кылды?

2) Аллаһ тәгаләнең рөхсәтеннән башка берәр нәрсә була аламы?

3) Аллаһның гыйлеме үзгәрәме вә яңарамы?

# Аллаһ кешеләрне фитрый кылган хәләт

خلقَ الخَلْقَ سليماً منَ الكفرِ والإيمانِ، ثمَّ خاطبَهُم وأمرهُم ونهاهُم، فكفرَ منْ كفَرَ بفعلِهِ وإنكارِهِ وجحودِهِ الحَقَّ بخِذلانِ اللهِ تعالى إياهُ، وءامنَ منْ ءامنَ بفعلِهِ وإقرارِهِ وتصديقِهِ بتوفيقِ اللهِ تعالى إياهُ ونَصرتِهِ لهُ. أخرجَ ذريةَ ءادمَ عليهِ السلامُ من صُلبهِ على صُورِ الذَّرِ، فجعَلَهم عُقَلاء، فخاطبَهُم وأمرَهُم بالإيمانِ ونهاهُم عن الكفرِ فأقَروا لهُ بالربوبيةِ فَكانَ ذلك منهُم إيماناً، فهُم يولدونَ على تلكَ الفطرةِ، ومنْ كفرَ بعدَ ذلكَ فقدْ بدّلَ وغيّرَ، ومَنْ ءامنَ وصدّقَ فقدْ ثبتَ عليهِ وداومَ

**Аллаһ тәгалә мәхлукларны көферлектән һәм иманнан ирекле (хөр) итеп халикъ кылды, аннары Ул аларга әмер вә тыюлар белән мөрәҗәгать итте. Кемнәрдер Аллаһ тәгаләдән аңа тәүфыйк булмыйча үзләренең гамәлләре белән һәм хаклыкны инкяр итеп вә кабул итмичә — көферлек кылдылар. Ә кемнәрдер Аллаһтан аңа тәүфыйк вә ярдәм булып үзләренең гамәлләре белән һәм хаклыкны икърар кылып вә кабул итеп — иман китерделәр. Ул Адәмнең нәселен аның сыртыннан[76] чыгарды һәм аларны гакыллы кылды, шуннан соң Иманга боерып һәм көферлектән тыеп аларга мөрәҗәгать итте. Алар Аның Раббы булуын таныдылар вә икърар кылдылар һәм бу алар тарафыннан иман китерү булды. Шулай итеп алар ошбу фитрый хәләттә туалар. Кем моннан соң көферлек кылса, ул әүвәлге фитрый хәләтен үзгәрткән вә алыштырган була, ә кем иман китерсә вә тугры булса, ул фитрый хәләтендә ныклы тотынды вә дәвамлы булды**

---

76 Умырткалык

**Төшенчәләр: (Тәүфыйк)** Аллаһ тәгалә Үзе яраткан һәм риза булган нәрсәгә, колының гамәлен туры китерүе. **(Фитрый хәләт)** Бу сүзне аңлатуда гыйлемияләренең төрле карашлары билгеле булды. Ибен Кәсир әйтүенчә: «Кеше дөньяга туганда ислам динен кабул итәргә әзер булган ниндидер билгеле сыйфатлар вә үзенчәлекләр белән туа. Әгәр дә аны үз-үзенә калдырсаң, ул һичшиксез үзенең шушы тумыш сыйфатларына (ислам диненә) иярәчәк, ә диннән читләшүче иллә-мәгәр башка кешеләр яки йолалар тәэсирендә генә читләшә». Ибен Хәҗәр әйтүенчә: «Фитрый хәләтне аңлауда гыйлем ияләре арасында бердәмлек булмады. Ләкин иң киң таралган аңлатмага караганда, ул — Исламны аңлата».

**Шәрех:** Шәех Әбү Хәнифә хәзрәтләренең, **«Аллаһ тәгалә мәхлукларны көферлектән вә иманнан ирекле (хөр) итеп халикъ кылды»** диюен тикшереп карау тиешле. Дөреслектә, Аллаһ тәгалә кешеләрне фитрый хәләттә һәм беренче гаһедне икърар кылган хәлдә халикъ кылды. Ул аларны, Үзенең тәүхидлегенә (берлегенә) икърар иткән хәлдә һәм халикъ кылуда, патшалыкта, ризык бирүдә, идарә итеп тәртиптә тотуда һәм башка нәрсәләрдә Аның Бер Үзе генә икәнлеген таныган хәлдә, бар итте. Аннары, аларны шушындый хәләттә бар иткәч, Аллаһ тәгалә аларны пәйгамбәрләре аша иманга вә итагатькә боерып һәм көферлектән вә яманлыктан тыеп мөрәҗәгать итте. Кемнәрдер, Аллаһ Коръәндә әйткәнчә:

فَاسْتَحَبُّوا الْعَمَى عَلَى الْهُدَى

Мәгънәсе: **«Алар һидәятькә караганда сукырлыкны яхшырак дип исәпләделәр»**[77]

үзләренең ихтыярлы гамәлләре белән вә хаклыкны инкяр итеп вә кабул итмичә һәм пәйгамбәрләрнең чакыруын инкяр кылып — кәфер булдылар. Болар һәммәсе аларга Аллаһтан тәүфыйк булмаганлыктан. Ул аларны

77 Фүссыйләт 17

тәүфыйктан мәхрүм иткәч, шәйтаннар аларны котырттылар һәм диннәреннән яздырдылар. Аларның барча бу кыланышлары Аллаһ тәгаләнең тәкъдире, кадасы һәм теләге белән.

Ә кемнәрдер Аллаһтан аңа тәүфыйк вә ярдәм булып үзләренең гамәлләре белән һәм хаклыкны икърар кылып вә кабул итеп — иман китерделәр. Чөнки Аллаһ аларны тәүфыйксыз итеп шәйтанга калдырмады, һәм аңа нәфесен, һәвәсен вә шәйтаннарын җиңәргә ярдәм итте. Аллаһ Коръәндә әйткәнчә, иман китерүчеләр дә, көферлек кылучылар да берсе дә Аның теләгеннән чыга алмый:

وَمَا تَشَاءُونَ إِلَّا أَنْ يَشَاءَ اللَّهُ رَبُّ الْعَالَمِينَ

Мәгънәсе: **«Галәмнәр Раббысы Аллаһ теләгеннән башка, сез аны тели алмассыз»[78]**

Аллаһ Адәм нәселен халикъ кылганда аларны аның сыртыннан гакыллы итеп чыгарды, һәм аларга Аңа тәүхид вә иман китерү белән, һәм Аңа ширек кылуны тыеп мөрәҗәгать итте. Һәм Аллаһ Коръәндә әйткәнчә, алар Аны Раббы итеп таныдылар вә икърар кылдылар:

وَإِذْ أَخَذَ رَبُّكَ مِنْ بَنِي آدَمَ مِنْ ظُهُورِهِمْ ذُرِّيَّتَهُمْ وَأَشْهَدَهُمْ
عَلَى أَنْفُسِهِمْ أَلَسْتُ بِرَبِّكُمْ قَالُوا بَلَى شَهِدْنَا

Мәгънәсе: **«Янә хәтерләгез, синең Раббың Адәм балаларының сыртларыннан аларның нәселен алды һәм аларны үз-үзләренә каршы шәһидлек кылдырды: «Әлләә Мин сезнең Раббыгыз түгелме?» Алар: «Әлбәттә! Без шәһидлек иттек», — диделәр»[79]**

Алар тарафыннан булган бу тану вә икърар кылу — бу иң беренче гаһед — иман китерү иде, һәм алар ошбу фитрый хәләттә тудылар, аннары кемнәредер моны көферлеккә үзгәртеп алыштырдылар. Ә кемнәредер пәйгамбәрләрнең чакыруларын кабул итеп Аллаһка

78 эт-Тәкүир 29
79 эл-Әгъраф 172

иман китерделәр һәм беренче гаһедкә сабит (ныклы) булып калдылар. Пәйгамбәребезнең ﷺ хәдисендә болай диелде:

كُلُّ مَوْلُودٍ يُولَدُ عَلَى الْفِطْرَةِ، فَأَبَوَاهُ يُهَوِّدَانِهِ أَوْ يُنَصِّرَانِهِ أَوْ يُمَجِّسَانِهِ، كَمَثَلِ الْبَهِيمَةِ تُنْتَجُ الْبَهِيمَةَ، هَلْ تَرَى فِيهَا جَدْعَاءَ

***— «Һәрбер бала фитрый хәләттә туа, аннары аның әти-әниләре аны яки яһүд кылалар, яки нәсара итәләр, яки мәҗүси итәләр. Нәкъ шулай ук хайваннар да имгәтелмәгән-бозылмаган булып дөньяга киләләр, син аларның берәрсендә (туганда) колагы киселгәнне күрәсеңме?!»[80]***

Барча нәрсә дә Аллаһ тәгаләнең тәкъдире вә теләге белән.

---

80 Бохари 1359

ولم يُجبرْ أحداً من خلقِهِ على الكفرِ ولا على الإيمانِ. ولا خُلقَهُم مؤمناً ولا كافراً، ولكنْ خلقَهُم أشخاصاً، والإيمانُ والكفرُ فعلُ العبادِ، يعلمُ اللهُ تعالى مَنْ يكفرْ في حالِ كفرِهِ كافراً فإذا ءامنَ بعدَ ذلك علمَهُ مؤمناً في حالِ إيمانِهِ، من غيرِ أنْ يتغيرَ علمُهُ وصفتُهُ. وجميعُ أفعالِ العبادِ منَ الحركةِ والسكونِ كسبُهُم على الحقيقةِ، واللهُ تعالى خالقُها، وهيَ كلُها بمشيئتِهِ وعلمِهِ وقضائِهِ وقَدَرِهِ

**Ул мәхлукларының берсен дә көферлеккә яки иманга мәҗбүр итмәде, һәм аларны мөэмин вә кәфер итеп халикъ кылмады, бәлки шәхесләр итеп халикъ кылды, ә иман белән көферлек — колларның гамәле. Аллаһ тәгалә көферлек кылучыны аның көферлек хәләтендә кәфер буларак белә, әгәр моннан соң иман китерсә аны иманлы хәләтендә мөэмин буларак белә вә аны ярата, һәм болардан Аның гыйлеме дә, сыйфаты да үзгәрми. Колларның барча гамәлләре; булсын хәрәкәттән һәм хәрәкәтсезлектән — чынлыкта аларның кәсепләреннән. Аллаһ тәгалә аларны халикъ кылучы, һәм алар барысы да Аның теләге, гыйлеме, кадасы вә тәкъдире белән**

---

**Төшенчәләр:**

**Шәрех:** Аллаһ тәгалә мәхлукларның берсен дә көферлеккә дә, иманга да мәҗбүр кылмады, бәлки Коръәндә әйткәнчә аларны фитрый хәләттә халикъ кылды:

فَأَقِمْ وَجْهَكَ لِلدِّينِ حَنِيفًا فِطْرَةَ اللَّهِ الَّتِي فَطَرَ النَّاسَ عَلَيْهَا

Мәгънәсе: **«Йөзеңне дингә хәниф (мүвәххид, мөэмин-мөселман) буларак юнәлдер. Аллаһ кешеләрне барлыкка китергән фитрый хәләт шушыдыр»[81]**

Хәдистә болай диелде:

وَإِنِّى خَلَقْتُ عِبَادِى حُنَفَاءَ كُلَّهُمْ

81 әр-Рум 30

***— «Һәм Мин Үземнең колларымны барысын да хәниф (мүвәххид, мөэмин-мөселман) итеп халикъ кылдым»[82]***

Иман һәм көферлек колларның гамәлләре вә кәсебләре дигән белән, боларның барысы да Аллаһ тарафыннан халикъ кылынган вә Аннан тәкъдир ителгән дигән арасында бернинди капма-каршылык та юк. Аллаһ тәгаләнең гыйлеме барча нәрсәне үзенә ала. Ул кәферне көферлек хәләтендә белә, һәм аның ничек иманлы булуын иман китергәнче үк белә. Болар барысы да Аллаһның гыйлеме вә теләге белән. Китапта искә алынган кайбер гыйбарәләр-әйтемнәр Әбү Хәнифәнең сүзләреннән түгел, чөнки кайбер урыннарда имам Әгъзам заманында сәләфләр тәфсыйлләп сөйләшмәгән темаларга керелә.

Нәрсә генә булмасын, Аллаһ тәгалә аны гыйлемендә бернинди үзгәрешсез белә, һәм Аның гыйлеме әзәлге (элек-электән мәңге). Ул нәрсә булганны, нәрсә буласын һәм нәрсә булмаганны әгәр дә ул ничек булса, барысын да белә.

Имам Тахауий үзенең гакыйдә китабында болай диде: ***«Аңа аларны халикъ кылганчы һичнәрсә дә яшерен булмады, һәм аларны халикъ кылганчы нәрсә эшләселәрен белде»***

**Кыскача нәтиҗә:**

Аллаһ тәгалә мәхлукларының берсен дә иманга да, көферлеккә дә мәҗбүр итмәде, ә бәлки аларны фитрый хәләттә халикъ кылды. Ул гыйлемендә бернинди үзгәрешсез нәрсә булганны һәм нәрсә буласын белә.

**Сораулар:**

1) Аллаһ тәгалә мәхлукларның берәрсен иманга яки көферлеккә мәҗбүр иттеме?

2) Аллаһ тәгалә мәхлукларны иман беләнме яки көферлек беләнме халикъ кылды?

3) Аллаһ тәгалә бер нәрсәне булган чорындамы әллә аңа кадәр үк беләме?

82 Мөслим 2865

# Итагатьләр — Аллаһка сөйкемле, Гөнаһлар — тәкъдир кылынган һәм алар Аллаһка сөйкемле түгел

والطاعاتُ كلُها كانتْ واجبةً بِأمرِ اللهِ تعالى وبمحبتهِ وبِرضائهِ وعلمِهِ ومشيئتِهِ وقضائِهِ وتقديرهِ، والمعاصي كلُّها بعلمِهِ وقضائِهِ وتقديرِهِ ومشيئتِهِ لا بمحبتِهِ ولا برضائِهِ ولا بأمرِهِ

**Барча итагатьләр дә Аллаһ тәгаләнең әмере, мәхәббәте, ризалыгы, гыйлеме, теләге, кадасы һәм тәкъдире белән вәҗиб-тиешле булды. Ә барча гөнаһлар да Аның гыйлеме, кадасы, тәкъдире һәм теләге белән, ләкин Аның мәхәббәте, ризалыгы вә әмер-боерыгы беллән түгел**

---

**Төшенчәләр:**

**Шәрех:** Дөреслектә, сүзләрдән вә гамәлләрдән булган итагатьләр Аллаһ тәгаләнең шәргый әмере белән һәм Аның бу итагатьләрне яратуы вә алардан разый булуы белән, вәҗиб-тиешле.

وَإِنْ تَشْكُرُوا يَرْضَهُ لَكُمْ

Мәгънәсе: **«Әгәр сез шөкер итсәгез, Ул сезгә аны разый кылыр»**[83]

Шулай ук, бу итагатьләр Аллаһның гыйлеме, теләге, кадасы вә тәкъдире белән. Чөнки Аллаһ тәгалә колларның барча гамәлләрен дә белде, теләде, када вә тәкъдир

83 әз-Зүмәрр 7

кылды. Бу яшәештә барча нәрсә дә Аллаһның теләге вә тәкъдире белән генә була:

وَاللَّهُ خَلَقَكُمْ وَمَا تَعْمَلُونَ

Мәгънәсе: **«Аллаһ сезне һәм сез кылган гамәлләрне халикъ кылды»[84]**

Янә әйтте:

وَمَا تَشَاءُونَ إِلَّا أَنْ يَشَاءَ اللَّهُ رَبُّ الْعَالَمِينَ

Мәгънәсе: **«Галәмнәр Раббысы Аллаһ теләгеннән башка, сез аны тели алмассыз»[85]**

Янә әйтте:

كَلَّا إِنَّهُ تَذْكِرَةٌ ۞ فَمَنْ شَاءَ ذَكَرَهُ ۞ وَمَا يَذْكُرُونَ إِلَّا
أَنْ يَشَاءَ اللَّهُ هُوَ أَهْلُ التَّقْوَى وَأَهْلُ الْمَغْفِرَةِ

Мәгънәсе: **«Юк! Бәлки ул нәсыйхәт. Теләгән кеше аны искә алыр. Ләкин алар искә алмаслар, иллә-мәгәр Аллаһ теләсә генә. Ул — Аллаһ, тәкъвалык тиешле вә мәгьфирәт кылучы зат»[86]**

Бу яшәештә булган гөнаһлар, шулай ук Аллаһның гыйлеме белән:

إِنَّ اللَّهَ لَا يَخْفَى عَلَيْهِ شَيْءٌ فِي الْأَرْضِ وَلَا فِي السَّمَاءِ

Мәгънәсе: **«Хакыйкатьтә, Аллаһка җирдә һәм күкләрдә бернәрсә дә яшерен түгел»[87]**

Аллаһ тәгалә гөнаһларны яратмаса да вә алардан разый булмаса да, Коръәндәге гомуми аятьләрдән вә хәдисләрдән билгеле булганча, аларны када вә тәкъдир кылып булуын теләде:

إِنْ تَكْفُرُوا فَإِنَّ اللَّهَ غَنِيٌّ عَنْكُمْ وَلَا يَرْضَى لِعِبَادِهِ الْكُفْرَ

---

84 әс-Саффәт 96
85 әт-Тәкүир 29
86 әл-Мүдәссир 54-56
87 әли Гыймран 5

Мәгънәсе: **«Әгәр сез көферлек кылсагыз, хакыйкатьтә Аллаһ сезгә мохтаҗ түгел, һәм Ул колларына көферлекне хупламый (разый булмый)»**[88]

Шулай ук, Аллаһ тәгалә гөнаһларга шәргый әмер белән боерык кылмады:

وَإِذَا فَعَلُوا فَاحِشَةً قَالُوا وَجَدْنَا عَلَيْهَا آبَاءَنَا وَاللَّهُ أَمَرَنَا بِهَا قُلْ إِنَّ اللَّهَ لَا يَأْمُرُ بِالْفَحْشَاءِ أَتَقُولُونَ عَلَى اللَّهِ مَا لَا تَعْلَمُونَ

Мәгънәсе: **«Әгәр алар фәхишәлек кылсалар: «Без аталарыбызның шулай эшләгәнен күрдек, һәм Аллаһ безгә моның белән боерды», — диделәр. Әйт аларга: «Дөреслектә, Аллаһ фәхешлек белән боермый. Ничек сез белмәгәнегезне Аллаһка ифтира кыласыз (ялган сөйлисез)?»**[89]

Шулай итеп, итагатьләрне Аллаһ шәргый теләде[90], алардан разый булды һәм шәргый боерык белән әмер итте, һәм ул итагать булса, шулай ук Аның кәүни теләге белән булды. Әмма гөнаһлар Аллаһның кәүни теләге белән генә була, һәм алар Аның шәргый теләге белән дә, шәргый боерыгы белән дә, ризалыгы белән дә вә мәхәббәте белән дә түгел.

88 әз-Зүмәрр 7

89 әл-Әгъраф 28

90 Аллаһ тәгаләнең теләге бар һәм ул теләк ике төрлегә бүленә: 1-Шәргый теләк, 2-Кәүни теләк. А) Кәүни теләк – Аллаһ яраткан нәрсә булса да, яратмаган нәрсә булса да аны халикъ кылуы вә булдыруы белән бәйле. Әмма Шәргый теләк – Аллаһ яраткан нәрсәгә генә хас, һәм Ул Үзе ратканны гына шәргый тели. Б) Кәүни теләктә – Шәргый теләккә караганда морад ителгән нәрсә һичшиксез була, мәсәлән: **«Әгәр Аллаһ кешеләргә яманлык теләсә, бернәрсә дә аны тоткарлый алмый»** (әр-Рагьд 11) Ягъни, яманлык булса да ул һичшиксез булырга тиеш, бу кәүни теләк. Әмма Шәргый теләк, мәсәлән **«Аллаһ сезгә җиңеллек тели»** (әл-Бәкара 185) дигән кебек аять. Әгәр безгә шәргый әмер, шәригатьтә бер төрле гамәл авырайса – ул җиңеләйтелә: мөсафир сәфәрдә ашый, чирле кешегә таһәраттә вә намазда җиңеллек бирелә һ.б. Аллаһ тәгалә барча кешенең дә тәкъва-мөэмин булуын шәргый теләк белән теләде, шуның өчен дә төрле аермалар күрәбез. Кешеләрнең кайберләре бөтенләй мөэмин түгел, ә кайсылары тәкъва түгел. (Күбрәк беләсең килсә, «Әгләм әс-сүннәһ әл-мәншүраһ», Габдуррахман әл-Мәхмүднең «әл-Када үәл-кадәр фи дау‘ әл-китәб үәс-сүннәһ», Мөхәммәд әл-Хәмднең «әл-Имән бил-када үәл-кадәр» китапларын кара)

# Пәйгамбәрләрнең мәгъсум[91] булулары хакында сүз

والأنبياءُ عليهِمُ الصلاةُ والسلامُ كلُّهُم مُنَـزَّهونَ عن الصغائِرِ والكبائِرِ والكفرِ والقبائِحِ وقدْ كانتْ مِنْهُم زَلَّاتٌ وخَطِيئَاتٌ

**Пәйгамбәрләр ﷺ барчасы да кечкенә вә зур гөнаһлардан, көферлектән һәм кабахәтлектән пакьлар. Бәлки, аларның кайбер ялгышлыклары вә хаталары булды**

---

**Төшенчәләр:**

**Шәрех:** Пәйгамбәрләрнең мәгъсум булу мәсьәләсендә һәм алар гөнаһ кылырга мөмкинме әллә юкмы, дигән сорауда, кешеләр төрле карашларга бүленделәр. Кайбер галимнәр сәләфләрнең карашын искә алып, болай диде: «Пәйгамбәрләр ﷺ кечкенә гөнаһлардан тыш зур гөнаһлардан гына мәгъсум диючеләрнең карашы, күпчелек Ислам галимнәренең һәм барча таифәләрнең карашы. Хәтта, бу күпчелек кәләм әһелләренең карашы... Сәләфләрдән, гыйлем ияләреннән, сахәбәләрдән һәм тәбигыйннәрдән, иллә-мәгәр шушы фикергә муафыйк карашлар билгеле булды»[92]

Коръән һәм сөннәттән билгеле булган әсәрләр бу карашка муафыйк булып килә. Кайбер пәйгамбәрләр ялгышлык белән хаталансалар да, Раббылары аларны кисәткәч тә, алар хаталарыннан кайталар. Ул пәйгамбәр хатаны юри кылмый, һәм Раббысы аңа бу хатаны икърар кылып язмый. Әмма, көферлеккә һәм

91 Гөнаһсыз, саф

92 Мәҗмүгь әл-фәтәүә

зур гөнаһларга килгәндә, алар бу нәрсәләрдән мотлак[93] рәвештә мәгъсумнар.

Пәйгамбәрләрнең кайбер ялгышлык эшләргә мөмкин булуларына ошбу аять һәм башкалар ишарәтли:

وَعَصَى آدَمُ رَبَّهُ فَغَوَى

Мәгънәсе: **«Адәм Раббысына гыйсъянлык[94] кылды һәм ялгышты»[95]**

Аллаһ тәгалә Юныс хакында болай диде:

لَا إِلَهَ إِلَّا أَنْتَ سُبْحَانَكَ إِنِّي كُنْتُ مِنَ الظَّالِمِينَ

Мәгънәсе: **«Синнән башка иләһ юк! Син һәр кимчелектән пакь! Дөреслектә, мин золым кылучылардан булдым!»[96]**

Шулай ук, пәйгамбәребез ﷺ әйтте:

***— «Әй Аллаһ! Минем хаталарымны, белмәгәнлегемне һәм гамәлләремдәге исрафлыкны гафу ит»[97]***

**Кыскача нәтиҗә:**

Пәйгамбәрләр көферлектән, зур гөнаһлардан һәм юри кечкенә гөнаһ кылудан мотлак рәвештә мәгъсумнар. Әгәр алар ялгышлык-хата кылсалар, аның өчен соралмыйлар.

**Сораулар:**

1) Пәйгамбәрләр көферлек вә зур гөнаһлар кылулары мөмкинме?

2) Пәйгамбәрләр кечкенә гөнаһ кылганнары өчен, аларга нинди хөкем?

---

93 Һичшиксез, абсолют рәвештә

94 Тыңламады

95 Таһә 121

96 әл-Әнбия 87

97 Мөслим 2719

## Пәйгамбәр ﷺ хакында сүз

وَمُحَمّد عَلَيْهِ الصَّلَاة وَالسَّلَام حَبِيبه وَعَبده وَرَسُوله وَنبيه وَصفيه ونقيه وَلم يعبد الصَّنَم وَلم يُشْرك بِاللَّه تَعَالَى طرفَة عين قطّ وَلم يرتكب صَغِيرَة وَلَا كَبِيرَة قطّ

**һәм Мөхәммәд ﷺ Аның сөеклесе һәм колы, расүле һәм нәбие, сайланган кешесе һәм саф-пагы. Ул күз ачып йомган мизгелгә генә дә һичкайчан Аллаһ тәгаләгә ширек кылмады, потларга табынмады һәм беркайчан да зур вә кечкенә гөнаһ кылмады**

---

**Төшенчәләр:**

**Шәрех:** Дөреслектә, хәдистә риваять ителгәнчә, Мөхәммәд ﷺ Аллаһ тәгаләнең хәлиле (иң сөеклесе):

***— «Дөреслектә, Аллаһ тәгалә Ибраһимны Үзенең хәлиле итеп алган кебек, мине дә Үзенең хәлиле итеп алды»[98]***

һәм ул Аның колы:

وَإِنْ كُنْتُمْ فِي رَيْبٍ مِمَّا نَزَّلْنَا عَلَى عَبْدِنَا فَأْتُوا بِسُورَةٍ

Мәгънәсе: **«Әгәр дә сез колыбыз** *Мөхәммәдкә* **Без иңдергән** *Коръәндә* **шикләнәсез икән,** *Коръән* **сүрәсенә охшаш бер сүрә китерегез...»[99]**

Ул ﷺ Аллаһның сайланган кешесе, аны барча кешеләр арасыннан сайлады һәм Аның саф-пагы, аны Раббысы кимчелек-җитешсезлекләрдән пакьләде, саф кылды. Мөхәммәд ﷺ беркайчан да, хәтта пәйгамбәр булганчы да потларга табынмады һәм күз ачып йомган мизгелгә генә дә, һичкайчан Аллаһ тәгаләгә ширек кылмады. Шулай

98 Мөслим 532
99 әл-Бәкара 23

ук, ул беркайчан зур гөнаһ кылмады һәм беркайчан юри, яки белеп, яки кисәткәннән соң кечкенә хата ясамады:

لِيَغْفِرَ لَكَ اللَّهُ مَا تَقَدَّمَ مِنْ ذَنْبِكَ وَمَا تَأَخَّرَ وَيُتِمَّ
نِعْمَتَهُ عَلَيْكَ وَيَهْدِيَكَ صِرَاطًا مُسْتَقِيمًا

Мәгънәсе: **«Аллаһ тәгалә синең элекке вә киләсе гөнаһларыңны гафу итсен өчен һәм сиңа Үзенең нигъмәтен ирештереп тәмам кылсын өчен һәм сине туры юлга һидәят кылсын өчен»**[100]

Пәйгамбәрләр шулай ук, ялган, кабахәтлек, юньсезлек һәм шуңа охшаш нәрсәләрдән пакьләр, ә Мөхәммәд ﷺ бу пакьлектә Аллаһ тарафыннан иң югары ноктага иреште.

Имам Тахауий үзенең гакыйдә китабында болай диде: ***«Дөреслектә, Мөхәммәд Аллаһның сайланган колы, ихтыяр кылынган пәйгамбәре һәм рәсүле. Һәм ул пәйгамбәрләрнең мөһере, тәкъваларның имамы, расүлләрнең әфәндесе һәм галәмнәр Раббысының сөеклесе»***

**Кыскача нәтиҗә:**

Мөхәммәд пәйгамбәр ﷺ Аллаһның хәлиле һәм сайланган кешесе, һәм күз ачып йомган мизгелгә генә дә, һичкайчан Аллаһка ширек кылмады, беркайчан да зур гөнаһ яки юри кечкенә гөнаһ та кылмады.

**Сораулар:**

1) Пәйгамбәребезнең ﷺ Аллаһ каршында булган урынын әйт.

2) Пәйгамбәребездән ﷺ гөнаһлар чагылдымы?

100 эл-Фәтх 2

# Сахәбәләр ﷺ арасында өстенлек

وَأفضل النَّاس بعد النَّبيين عَلَيْهِم الصَّلَاة وَالسَّلَام أَبُو بكر الصّديق ثمَّ عمر بن الْخطاب الْفَارُوق ثمَّ عُثْمَان بن عَفَّان ذُو النورين ثمَّ عَليّ بن أبي طَالب المرتضى رضوَان الله عَلَيْهِم أَجْمَعِينَ

**Һәм пәйгамбәрләрдән ؏ соң иң хәерле кешеләр; Әбү Бәкер әс-Сыйддикъ, аннары Гомәр бин әл-Хаттаб әл-Фәрукъ, аннары Госман бин Гаффән зүн-Нүрайн, аннары Гали бин Әбий Талиб әл-Мүртәда — аларның җәмгысыннан да Аллаһ разый булсын**

---

**Төшенчәләр:**

**Шәрех:** Расүлебез Мөхәммәднең ﷺ сахәбәләре ﷺ — пәйгамбәрләрдән соң иң хәерле кешеләр. Сахәбәләрнең иң хәерлесе — Әбү Бәкер әс-Сыйддикъ ﷺ. Ул пәйгамбәребездән соң иң беренче хәлиф, ир-атлардан иң беренче иман китерүче вә иң иманлысы вә тугрысы. Ул пәйгамбәребезнең һиҗрәтендә аның юлдашы һәм расүлебезгә иң сөекле кешесе. Пәйгамбәребез ﷺ әйтте:

***— «Әгәр мин үземә хәлил ала торган булсам, Әбү Бәкерне хәлил итеп алыр идем. Ләкин ул минем кардәшем һәм сахәбәм (иярченем-юлдашым)»[101]***

Аннан соң, Гомәр бин әл-Хаттаб әл-Фәрукъ ﷺ. Ул икенче хәлиф, һәм Әбү Бәкердән соң бу өммәтнең иң хәерле кешесе. Аның кулы белән Аллаһ тәгаләә бөек җиңүләр вә ачышлар китерде. Пәйгамбәребез ﷺ аның хакында болай диде:

---

101 Бохари 3656

***— «Сезгә кадәр булган өммәтләрдә илһамлы кешеләр бар иде. Әгәр дә минем өммәтемдә дә андый берәр кеше булса, ул — Гомәр»***[102]

Гомәрдән соң фазыйләт буенча Госман бин Гаффән зүн-Нүрайн килә. Пәйгамбәребезнең ﷺ ике кызының ире һәм өченче хәлиф, аның хакында расүлебез болай диде:

***— «Фәрештәләр оялган кешедән (ягъни, Госманнан) мин ничек инде оялмыйм?!»***[103]

Госманнан соң фазыйләт буенча, арыслан сугышчы, пәйгамбәребезнең ﷺ кызы булган Фатыйманың ире, Җәннәттә яшьләрнең әфәнделәре булган Хәсән белән Хөсәеннең әтисе — Гали бин Әбий Талиб ؓ килә. Пәйгамбәребез ﷺ аның хакында болай диде:

***— «Син әллә, Һәрун Муса янында алган кебек урынны минем янымда алырга риза түгелме? Иллә-мәгәр миннән соң пәйгамбәр юк!»***[104]

Бу дүрт хәлифне пәйгамбәребез ﷺ Җәннәт әһелләре булуларын ачыктан-ачык әйтеп узды. Без аларның барысыннан да риза булып, дәрәҗәләрен вә фазыйләтләрен белеп һәм дә яхшылык белән генә искә алырга тиешбез.

---

102 Бохари 3689
103 Мөслим 2401
104 Бохари 3706, 4416

# Мөселман гөнаһны хәләл кылмаса, аны эшләгән өчен генә көферлеккә чыгарылмый

عابدين ثابِتين على الْحق وَمَعَ الْحق نتولاهم جَمِيعًا وَلَا نذْكر أحدا من أَصْحَاب رَسُول الله إِلَّا بِخَير وَلَا نكفر مُسلما بذنب من الذُّنُوب وَإِن كَانَت كَبِيرَة إِذا لم يستحلها وَلَا نزيل عَنهُ اسْم الْإِيمَان ونسميه مُؤمنا حَقِيقَة وَيجوز ان يكون مُؤمنا فَاسِقًا غير كَافِر

**Алар гыйбадәт кылучылар, хаклыкта сабитлар (нык торучылар) һәм хаклык белән булдылар. Барчасын да яратабыз һәм Аллаһ расүленең бер генә сахәбәсен дә яхшылыктан башка нәрсә белән искә алмыйбыз. Һәм бер генә мөселманны да гөнаһы өчен көферлек кылмыйбыз, хәтта зур гөнаһ булса да, әгәр ул аны хәләл кылмаса. Без аны иман исеменнән мәхрүм итмибез, һәм чынлыкта да мөэмин дип атыйбыз. Ул фасыйк мөэмин булырга мөмкин, ләкин кәфер түгел**

---

**Төшенчәләр: (Фасыйк)** Аллаһка итагать итүдән һәм изгелектән бозыклыкка чыгучы. Шулай ук, тычкан (الفأرة) гарәпчә фүәйсика (فويسقة) дип тә исемләнде, һәм пәйгамбәребезнең ﷺ хәдисендә риваять ителгәнчә; хәрам җирендә дә, гади җирдә дә үтерергә яраган биш төрле җан ияләре үзләренең ояларыннан бозыклык кылырга чыкканнары өчен «фәүәсикъ» дип аталды (Бохари 1829)

**Шәрех:** Сахәбәләр Аллаһка ﷻ гыйбадәт кылучылар, хаклыкта нык торучылар иде, һәм алар даимән хаклык белән булып, ялганнан вә батылдан читләштеләр. Без аларның барысын да яратабыз һәм яхшылык белән генә искә алабыз, ә кем аларга сүз тидерсә, аңа нәфрәт белдерәбез. Пәйгамбәребез ﷺ әйтте:

***— «Минем сахәбәләремне сүкмәгез!»***[105]

Имам Тахауий үзенең гакыйдә китабында болай диде: ***«Һәм пәйгамбәрнең ﷺ сахәбәләрен яратабыз. Аларның аерым берсен яратуда ифрат[106] кылмыйбыз һәм берсеннән дә ваз кичмибез. Аларны сөймәүчегә һәм яманлап искә алучыга нәфрәтләнәбез. Сахәбәләрне яхшылык белән генә искә алабыз. Аларны сөю, ул — дин, иман һәм ихсан. Аларны сөймәү — көферлек, монафикъльлык һәм гөнаһ».***

Әгәр дә мөселман гөнаһларны хәләл кылмаса, Сөннәт әһелләре аны гөнаһлары өчен генә, хәтта зур гөнаһ эшләсә дә, хавариҗлар кебек көферлеккә чыгармыйлар. Ә инде гөнаһны хәләл кылса, хәләлгә чыгаруы белән кәфер була, иллә-мәгәр җәһел-надан булса аңа аңлатыла вә бәян кылына, аннан соң да фикере үзгәрмәсә — көферлек кылган була.

Сөннәт әһелләре гөнаһ кылучы мөселманны иман исеменнән мәхрүм итмиләр. Хавариҗлар зур гөнаһ кылучыны көферлеккә чыгарсалар, мөгтәзиләләр аны көферлек белән иман арасында булучы хәлдә диделәр, һәм икеләре дә аны иман исеменнән мәхрүм кылдылар. Әмма Сөннәт әһелләре аны, гөнаһлары сәбәпле иманы нәкыс[107] булса да, чынлыкта мөэмин дип атыйлар. Дөреслектә, иман итагатьләр белән арта, һәм гөнаһлар белән кими.

---

105 Бохари 3673

106 Чамадан тыш, кирәгеннән артык

107 Ким

Шулай ук, билгеле булганча мөэмин Исламнан чыкмыйча, зур гөнаһ эшләү сәбәпле Аллаһка итагать итүдән чыгуы мөмкин. Аллаһ тәгалә әйтте:

وَالَّذِينَ يَرْمُونَ الْمُحْصَنَاتِ ثُمَّ لَمْ يَأْتُوا بِأَرْبَعَةِ شُهَدَاءَ فَاجْلِدُوهُمْ
ثَمَانِينَ جَلْدَةً وَلا تَقْبَلُوا لَهُمْ شَهَادَةً أَبَدًا وَأُولَئِكَ هُمُ الْفَاسِقُونَ

Мәгънәсе: **«Дүрт шаһит китермичә саф хатын-кызларны гаепләүчеләрне сиксән тапкыр сугыгыз һәм аларның шаһитлык кылуларын беркайчан да кабул итмәгез, чөнки алар фасыйклар»**[108]

Аллаһ бу кешеләрне кылган гамәлләре өчен көферлеккә чыгармыйча, фасыйклык белән хөкем итте. Бу мәсьәлә бик тә мөһим мәсьәләләрнең берсе булып тора, шуның өчен дә бик игътибарлы бул, чөнки күп кенә таифәләр ошбу мәсьәләдә адаштылар. Аллаһ тәгалә тәүфыйк бирсен.

Имам Тахауий үзенең гакыйдә китабында болай диде: ***«Гөнаһны хәләл кылмаган кыйбла әһелләрен гөнаһ кылган өчен берсен дә без көферлеккә чыгармыйбыз»***

**Кыскача нәтиҗә:**

Сахәбәләрнең иң фазыйләтлеләре; Әбү Бәкер, Гомәр, Госман һәм Гали. Барча сахәбәләрне дә яратабыз һәм яхшылык белән генә искә алабыз. Гөнаһларны хәләл кылмаган бер мөселманны да көферлеккә чыгармыйбыз.

**Сораулар:**

1) Пәйгамбәребездән ﷺ соң иң хәерле сахәбәләр ؓ кемнәр?

2) Сахәбәләрне яхшы булмаган нәрсә белән искә алырга ярыймы?

3) Мөселман гөнаһ кылганы өчен көферлеккә чыгамы? Гөнаһны хәләл кылган мөселманның хөкеме нинди?

---

108 ән-Нур 4

# Сөннәт әһелләренең гакыйдәләреннән кайбер мәсьәләләр

وَالْمسح على الْخُفَّيْنِ سنة والتراويح فِي لَيَالِي شهر رَمَضَان سنة وَالصَّلَاة خلف كل بر وَفَاجِر جَائِزَة وَلَا نقُول إِن الْمُؤمن لَا تضره الذُّنُوب وَلَا نقُول إِنَّه لَا يدْخل النَّار وَلَا نقُول إِنَّه يخلد فِيهَا

**Читекләргә мәсех кылу — сөннәт, Рамазан ае кичләрендә тәраүих — сөннәт, һәм һәрбер игелекле вә гөнаһлы артыннан намаз уку — рөхсәт ителә. Без: «Мөэмингә гөнаһлары зыян итми», — дип әйтмибез, һәм: «Ул Утка керми», — димибез. Шулай ук әйтмибез: «Ул анда мәңге кала дип**

---

**Төшенчәләр:**

**Шәрех:** Читекләргә мәсех кылу пәйгамбәребездән ﷺ килгән сабит сөннәт. Коръәннән ул (أَرْجُلِكُمْ) сүзен кәсра белән укучыларда ошбу аять белән сабит:

وَأَرْجُلَكُمْ إِلَى الْكَعْبَيْنِ

Мәгънәсе: **«һәм аякларыгызны тубыкка кадәр»**[109]

Шулай ук пәйгамбәребездән ﷺ килгән хәдисләр белән сабит, һәм алар мүтәүәтир дәрәҗәсендә, вә бик күп. Мүгыйра бин Шүгьбәдән риваять ителгән хәдистә, пәйгамбәребез таһәрат алганда ул аның читеген салдырырга теләгәч, расүлебез аңа: ***«Калдыр аларны,***

109 әл-Мәидә 6

***дөреслектә, мин аларны таһәратле килеш кидем», —*** диде, һәм аларга мәсех кылды[110].

Хәсән әл-Бәсърий болай диде: «Пәйгамбәребез ﷺ читекләренә мәсех кылды дип, миңа аның җитмеш сахәбәсе сөйләде».

Имам Әхмәд әйтте: «Минем күңелемдә мәсех кылу хакында бернинди шик тә юк, ул хакта пәйгамбәребездән кырык хәдис риваять ителә».

Габдуллаһ бин әл-Мүбәрак әйтте: «Читекләргә мәсех кылу хакында сахәбәләр арасында бернинди дә хыйлаф юк».

Сөннәт әһелләре читекләргә мәсех кылуны гакыйдәләренең асылыннан саныйлар, ә рафидалар һәм хавариҗлар кебек бидгать таифәләре бу мәсьәләдә аларга каршы булдылар, һәм читеккә мәсех кылуны инкяр итеп яланаякка мәсех кылу тиеш диделәр.

Имам Тахауий үзенең гакыйдә китабында болай диде: ***«Һәм әсәрләрдә килгәнчә, читекләргә мәсех кылуны сәфәрдә һәм сәфәрдә булмаганда дөрес дип саныйбыз»***

Рамазан кичләрендә тәраүих уку пәйгамбәребезнең ﷺ һәм сахәбәләрнең гамәлләреннән сабит сөннәт булып килде. Шулай ук, расүлебез ﷺ әйтте:

***— «Кем Рамазан кичләрендә иман белән һәм әҗер эстәп намазларын торгызса, аның үткән гөнаһлары гафу ителер»***[111]

Кыйбла әһелләреннән булган һәрбер игелекле вә гөнаһлы имам артыннан һәм Сөннәт әһеле имамы булмаганда бидгате көферлеккә чыгармый торган бидгатьче артыннан намаз уку рөхсәт ителә. Әгәр бидгате көферлеккә чыгара торган бидгатьче булса (кубурийлар кебек) яки адаштыру бидгатенә чакыручы булса — рөхсәт ителми. Имам Тахауий үзенең гакыйдә кита-

110 Бохари 206, Мөслим 274

111 Бохари 37 (Бу шулай ук рафидаларга кагыла, чөнки алар Рамазан аенда өстәмә-нәфел намазларын инкяр итәләр)

бында болай диде: ***«Кыйбла әһелләреннән һәрбер игелекле яки гөнаһлы артыннан намаз укуны, һәм аларның үлгәннәренә җеназа укуны дөрес дип саныйбыз»***

Сөннәт әһелләре мөрҗи'әләр кебек: «Мөэмингә гөнаһлары зыян итми», — дип әйтмиләр, бәлки: «Гөнаһлар иманга зыян итә вә иманны киметә, һәм дөреслектә, иман гөнаһлар белән кими», — диләр. Имам Тахауий үзенең гакыйдә китабында болай диде: ***«Һәм без, гөнаһ эшләүченең гөнаһы Иманга зыян итми, дип әйтмибез»***

Шулай ук, Сөннәт әһелләре: «Дөреслектә, мөэминнең гөнаһлары изгелекләренә караганда артып өстен чыкса, Утка керүе ихтимал, иллә-мәгәр Аллаһ башкача теләсә генә кермәскә мөмкин. Чөнки, аның иманының асылы булса да, гөнаһлары сәбәпле иманы нәкыс вә кимегән була. Ул гөнаһларының микъдәренә карата Утта газапланганнан соң, аннан чыгарылып Җәннәткә кертелә», — диделәр. Әмма хавариҗлар, зур гөнаһ кылган кешене көферлеккә чыгарып мәңгелек Ут белән хөкем иттеләр. Мөгтәзиләләр, андый кешене иманнан чыгардылар, ләкин көферлек белән хөкем итмәделәр, бәлки ул кеше көферлек белән иман арасында булучы хәлдә диделәр, лщкин аны хавариҗлар кебек мәңгелек Ут белән хөкем кылдылар.

Имам Тахауий үзенең гакыйдә китабында болай диде: ***«Һәм кыйблабыз әһелләрен, пәйгабәребез ﷺ алып килгән нәрсәне танып дәвамлы булсалар – мөселманнар вә мөэминнәр дип атыйбыз»***

وَإِن كَانَ فَاسِقًا بعد أن يخرج من الدُّنْيَا مُؤمنا وَلَا نقُول إِن حَسَنَاتنَا مَقْبُولَة وسيئاتنا مغفورة كَقَوْل المرجئة وَلَكِن نقُول من عمل حَسَنَة بِجَمِيع شرائطها خَالِيَة عَن الْعُيُوب الْمفْسدَة وَلم يُبْطِلهَا بالْكفْر وَالرِّدَّة والأخلاق السَّيئَة حَتَّى خرج من الدُّنْيَا مُؤمنا فَإِن الله تَعَالَى لَا يضيعها بل يقبلهَا مِنْهُ ويثيبه عَلَيْهَا

**хәтта ул фасыйк булса да, ләкин бу дөньядан мөэмин булып китсә. һәм без мөрҗиʻәләр кебек: «Безнең изгелекләребез – кабул, һәм гөнаһларыбыз – мәгьфур», — димибез, бәлки әйтәбез: «Кем, (гамәлләрне) боза торган кимчелекләрсез, барча шартлары белән изгелек кылса һәм дөньядан мөэмин булып чыгып киткәнче аларны көферлек, мөртәдлек һәм яман әхлаклар белән батыл кылмаса, дөреслектә, Аллаһ тәгалә аны (изгелекне) югалтмый, бәлки аннан кабул итеп аның өчен савабын бирә**

---

**Төшенчәләр: (Мәгьфур)** ярлыканган, гафу ителгән **(Батыл)** Савапсыз, буш, файдасыз.

**Шәрех:** Сөннәт әһелләре иман исеменнән мәхрүм булмаган кешене, зур гөнаһ эшләүе белән Аллаһка итагатьтән чыксада, мәңгелек Утта калу белән әйтмиләр. Шулай ук, Сөннәт әһелләре мөрҗиʻәләр кебек, изгелек кылган кешенең изелекләре кабул, һәм гөнаһлары мәгьфур дип белдермиләр. Бәлки, Аллаһтан изгелекләрнең кабуллыгын һәм гөнаһларның ярлыкануын эстиләр. Мөэмин үзенең гамәленең кабул булуына имин була алмый. Пәйгамбәребез ﷺ болай диде:

***— «Ләкин алар ураза тоталар, намаз укыйлар, садәка бирәләр һәм ошбу изгелекләренең кабул булмавыннан куркалар. Бу кешеләр хәерле гамәлләрдә бер-берсе белән узышучылар»[112]***

Сөннәт әһелләре әйтәләр: «Әгәр дә мөэмин изгелекне барча шәргый шартлары белән үтәп, дөньядан хак мөэмин булып ахирәткә киткәнче, аны боза торган яки

112 Тирмизи 3175

рия кебек харап итә торган кимчелекләрдән читләшсә һәм *Аллаһ* Коръәндә әйткәнчә, көферлек вә мөртәдлек белән юкка чыгармаса:

وَمَنْ يَرْتَدِدْ مِنْكُمْ عَنْ دِينِهِ فَيَمُتْ وَهُوَ كَافِرٌ فَأُولَئِكَ
حَبِطَتْ أَعْمَالُهُمْ فِي الدُّنْيَا وَالْآخِرَةِ

Мәгънәсе: **«Кем дә кем сездән үзенең диненнән тайпылса һәм кәфер булган хәлдә үлеп китсә, аларның** изге **гамәлләре дөньяда да, ахирәттә дә юкка чыгар»**[113]

Шулай ук *Аллаһ* Коръәндә әйткәнчә, ул кеше яман әхләклар белән яки кабахәт сыйфатлар белән изгелекләрен юкка чыгармаса:

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا لَا تُبْطِلُوا صَدَقَاتِكُمْ بِالْمَنِّ وَالْأَذَى

Мәгънәсе: **«Әй иман китерүчеләр! Садәкаларыгызны битәрләүләр һәм рәнҗетүләр белән юкка чыгармагыз!»**[114]

Пәйгамбәребез ﷺ хәдисендә әйткәнчә, аның бу изгелекләре *Аллаһ* тәгаләнең фазыйләте вә рәхмәте белән кабул була, һәм Ул аны югалтмый вә аңа әҗер-савабын тиешлечә бирә:

***— «Кем үзенең яхшы-хәләл кәсебе белән тапкан малыннан һич югы ярты хөрмә бәясе кадәр генә садәка бирсә — дөреслектә, Аллаһ яхшыдан башка нәрсәне кабул итми — Аллаһ аны Үзенең уңы белән кабул итәр, аннан соң аны садәка хуҗасы өчен, сезнең берегез колынын үстергән кебек, тау зурлыгы булганчы үстерер»***[115]

Болар барысы да асылда, ләкин ахырда мәсьәләне *Аллаһ* хөкеменә кайтарып, бертөрле дә катгый хөкем чыгару тиешле түгел.

---

113 әл-Бәкара 217
114 әл-Бәкара 264
115 Бохари 1410

وَمَا كَانَ من السَّيِّئَات دون الشّرك وَالْكفْر وَلم يتب عَنْهَا صَاحبهَا حَتَّى مَاتَ مُؤمنا فَإِنَّهُ مُؤمن فِي مَشِيئَة الله تَعَالَى إِن شَاءَ عذبه بالنَّار وَإِن شَاءَ عَفا عَنهُ وَلم يعذب بالنَّار أصلا والرياءُ إذا وَقَعَ في عملٍ منَ الأعمالِ فإنَّه يُبْطِلُ أجرَهُ، وكذا العُجْبُ

**Ширектән һәм көферлектән башка гөнаһларга килгәндә, ул гөнаһларның хуҗасы мөэмин булган килеш алардан тәүбә итмичә үлеп китсә, ул мөэмин санала, һәм ул Аллаһ тәгаләнең теләгендә кала. Теләсә — аны Ут белән газаб кыла, теләсә — аны гафу итә һәм бөтенләй дә Ут белән газабламый. Әгәр дә гамәлләрнең берәрсе рия белән кылынган булса, рия — ул гамәлнең әҗерен юкка чыгара, һәм шулай ук, үз гамәле белән гаҗәпсенү дә**

---

**Төшенчәләр: (Рия)** Кешегә күрсәтер өчен эшләнгән эш, ясалмалык, күз буяу.

**Шәрех:** Мөэмин, ширектән һәм көферлектән башка гөнаһлар кылып алардан тәүбә итмичә үлеп китсә дә, аннан иман исеме җуелмый. Сөннәт әһелләре бу хакта: «Ул мөэмин, Аллаһ тәгалә Коръәндә әйткәнчә:

إِنَّ اللَّهَ لَا يَغْفِرُ أَنْ يُشْرَكَ بِهِ وَيَغْفِرُ مَا دُونَ ذَٰلِكَ لِمَنْ يَشَاءُ

Мәгънәсе: **«Дөреслектә, Аллаһ Аңа ширек кылуны гафу итми, ләкин аннан башкаларны (башка гөнаһларны) Үзе теләгән кешесенә гафу итә»**[116]

һәм пәйгамбәребез ﷺ хәдисендә әйткәнчә:

***— «Кем дә кем бу гөнаһларның берәрсен кылса, Аллаһ аның гөнаһын каплар һәм аның хөкеме Аллаһка калыр. Теләсә Ул аны гафу итәр, ә теләсә – җәзалар»***[117]

Аның ﷻ теләгендә кала. Теләсә Ул аны Ут белән газаблый, аннары аннан иманы белән чыгара; теләсә — гафу

116 ән-Нисә 48
117 Бохари 18

итә һәм бөтенләй дә газабламый», — диделәр. Бу караш, һичшиксез хак вә дөрес.

Әгәр дә гамәлгә рия керсә, аның әҗер-савабын юкка чыгара, ә инде кеше гамәлен коры риядан гына кылса, эшләгән гамәле үзе дә юкка чыга. Шулай ук, кеше үзенең кылган гамәле белән гаҗәпсенү-масаю, гамәлнең әҗер-савабын юк итә. Кеше үзенең кылган гамәлендә нәкыс вә кимчелек күреп, һәм һәрвакытта да Аллаһтан гамәлләренең кабуллыгын, аларда кимчелек-хаталар кылуда гафу итүне сорарга тиеш.

**Кыскача нәтиҗә:**

Сөннәт әһелләре читекләргә мәсех кылуны дөрес, Рамазан айларында тәраүих уку сөннәт, һәм игелекле вә гөнаһлы артыннан намаз уку ярый дип күрәләр. Алар: «Гөнаһлы кеше гөнаһ кылу сәбәпле көферлеккә чыгарылмый, ләкин ул Аллаһ тәгаләнең теләгендә», — диләр. Шулай ук, алар: «Гөнаһ иманга зыян итми дип», — әйтмиләр.

**Сораулар:**

1) Читекләргә мәсех кылуның, һәм Рамазан аенда тәраүих укуның хөкемнәре нинди?

2) Бозык-гөнаһ кылучы имам артында намаз укуның хөкеме нинди?

3) Иманлы кешегә гөнаһ зыян итәме?

4) Гөнаһ кылучы мөселманның хөкеме нинди? Аңа Ут белән катгый хөкем ителәме?

# Пәйгамбәрләрнең могҗизалары, әүлияләрнең кәрамәтләре — хак

والآيات ثَابِتَة للأنبياء والكرامات للأولياء حق واما الَّتِي تكون لأعدائه مثل ابليس وَفرْعَوْن والدجال فِيمَا رُوِيَ الْأَخْبَار أنه كَانَ وَيكون لَهُم لَا نسميها آيَات وَلَا كرامات وَلَكِن نسميها قَضَاء حاجاتهم وَذَلِك لِأَن الله تَعَالَى يقْضِي حاجات اعدائه استدراجا لَهُم وعقوبة لَهُم فيغترون بِهِ ويزدادون طغيانا وَكفرا وَكله جَائِز مُمكن

**Пәйгамбәрләргә бирелгән могҗизалар — сабит, һәм әүлияләргә бирелгән кәрамәтләр — хак. Ләкин, хәбәрләрдә риваять ителгәнчә иблис, фиргавен һәм дәҗҗәл кебек Аллаһның дошманнарында булган вә булачак нәрсәләрне — могҗизалар да, кәрамәтләр дә дип атамыйбыз, ә аларның хаҗәтләрен үтәү дип атыйбыз. Чөнки, Аллаһ тәгаләә Үзенең дошманнарының хаҗәтләрен, аларга истидраҗ вә җәза булсын өчен үти. Алар аның белән алданып тагын да күбрәк золымлыкка вә көферлеккә чумалар. Боларның һәммәсе дә ихтимал һәм мөмкин**

---

**Төшенчәләр: (Кәрамәт)** Аллаһ Үзенең юмартлыгы белән әүлияләргә биргән гадәттән тыш күренеш. **(Истидраҗ)** Аллаһ Үзенең колын кызыктыра: ягъни, кеше гөнаһ-хаталарын яңартып эшләп торган саен, Аллаһ аңа дөнья нигъмәтен арттыра һәм гөнаһлары өчен гафу вә ярлыкау эстәүне оныттыра, яки аны кинәт кенә җәзаламыйча әкрен генә җәзага тарта. Аллаһ Коръәндә: **«Аятьләребезне ялган диючеләрне, үзләре белмәгән яктан, истидраҗ (акрынлык) илә газабка тартырбыз»**[118] — диде, ягъни: Без аларны үзләре уйламаганда газабка

118 әл-Әгъраф 182

тотырбыз. Аллаһ аларга дөнья нигъмәтен ача, һәм алар шуңа кызыгып алданалар, күңел ачып рәхәтләнәләр, хәтта үлемне дә искә алмый башлыйлар. Һәм Аллаһ аларны иң гафил вакытта булган чакларында газабка тота. Шуңа да, Гомәр бин әл-Хаттабка ﵁ Кисраның хәзинәләре китерелгәч болай дип дога кылды: «Әй Аллаһ! Мин мөстәдриҗ булудан Сиңа сыенам! Дөреслектә, мин Синең болай дип әйткәнеңне ишетәм: **«Аятьләребезне ялган диючеләрне, үзләре белмәгән яктан, истидраҗ (акрынлык) илә газабка тартырбыз»**.

**Шәрех:** Пәйгамбәрләргә һәм расүлләргә бирелгән могҗизалар һичшиксез сабит вә дөрес. Могҗизалар, Аллаһ тәгалә тарафыннан аларның тугрылыкларына дәлил булып китерелгән гадәттән тыш күренеш. Мәсәлән, Салихның дөясе кебек:

هَذِهِ نَاقَةُ اللَّهِ لَكُمْ آيَةً

Мәгънәсе: **«Аллаһның бу дөясе сезгә могҗиза булып тора»**[119]

Ибраһимның уттан котылуы кебек:

قُلْنَا يَا نَارُ كُونِي بَرْدًا وَسَلَامًا عَلَى إِبْرَاهِيمَ

Мәгънәсе: **«Без әйттек: «Әй ут! Ибраһимга салкынча һәм имин бул!»**[120]

Мусаның таягы кебек:

وَأَوْحَيْنَا إِلَى مُوسَى أَنْ أَلْقِ عَصَاكَ فَإِذَا هِيَ تَلْقَفُ مَا يَأْفِكُونَ

Мәгънәсе: **«Без Мусага: «Таягыңны ташла!», — дип вахи кылдык. Һәм ул (еланга әйләнгән таяк) аларның ялган нәрсәләрен йота башлады»**[121]

Һәм Аллаһтан аларга пәйгамбәрлекләрен исбатлаучы башка могҗизалар кебек, алар барысы да хак вә дөрес.

---

119 әл-Әгъраф 73
120 әл-Әнбия 69
121 әл-Әгъраф 117

Шулай ук, әүлияләргә бирелгән кәраматләр хак вә чын. Моны исбатлауда *Аллаһ* тәгаләнең ошбу сүзләре килә:

كُلَّمَا دَخَلَ عَلَيْهَا زَكَرِيَّا الْمِحْرَابَ وَجَدَ عِنْدَهَا رِزْقًا قَالَ
يَا مَرْيَمُ أَنَّى لَكِ هَذَا قَالَتْ هُوَ مِنْ عِنْدِ اللَّهِ

Мәгънәсе: **«Һәрвакыт Зәкәрия аның янына бүлмәгә кергәч, ул аның алдында ризыклар тапты. Әйтте: «Әй Мәръям! Болар синдә кайдан?», — дип. Мәръям әйтте: «Алар — Аллаһтан...»**[122]

Изге-салих кешеләрдә булган һәрбер гадәттән тыш күренеш, ул аларга *Аллаһ*ның юмартлыгы белән бирелгән. Ә инде иблис, фиргавен (сихерчеләре таякларын ташлагач, ул таяклар кешеләргә йөри торган елан кебек күренде) һәм дәҗҗәл кебек (аның гүя тизлеге, үтерелгән кешене тергезүе һәм башка нәрсәләре кебек) *Аллаһ*ның кайбер дошманнарында күренгән гадәттән тыш нәрсәләр могҗизалар дип тә (чөнки алар пәйгамбәрләр түгел), кәраматләр дип тә аталмый (чөнки алар әүлияләр түгел). Бу нәрсәләр хаҗәтләрне үтәү дип атала. *Аллаһ* тәгалә дошманнарының хаҗәтен аларны кызыктыру өчен һәм газаб кылу өчен үти. *Алар* аның белән алданып үзләрен дөреслектә дип уйлыйлар, һәм золым кылуны вә көферлекне тагын да күбәйтеп, *Аллаһ*ның ачуына ирешәләр

فَلَمَّا نَسُوا مَا ذُكِّرُوا بِهِ فَتَحْنَا عَلَيْهِمْ أَبْوَابَ كُلِّ شَيْءٍ حَتَّى
إِذَا فَرِحُوا بِمَا أُوتُوا أَخَذْنَاهُمْ بَغْتَةً فَإِذَا هُمْ مُبْلِسُونَ

Мәгънәсе: **«Аларга искә төшергән нәрсәләрне алар оныткач, Без аларга барча нәрсәгә ишекләрне ачтык. Ә инде алар бирелгән нәрсәләргә шатлангач, Без аларны кинәт кенә җәзага тоттык, һәм алар төшенкелеккә вә хәсрәткә чумдылар»**[123]

Бу барча нәрсәләр дә — ягъни могҗизалар, кәраматләр һәм хаҗәтләрне үтәү — *Аллаһ* тәгалә тарафыннан булды-

122 әли Гыймран 37
123 әл-Әнгам 44

рылуы мөмкин. Чөнки Ул барча нәрсәләрне идарә итүче Мәлик-патша, һәм Ул бернәрсәдән дә гаҗиз түгел.

**Кыскача нәтиҗә:**

Пәйгамбәрләргә бирелгән могҗизалар, әүлияләрдә күренгән кәрамәтләр — хак вә дөрес. Мөэминнәрдән тыш башкаларда чагылган гадәти булмаган күренешләр, аларны кызыктыру өчен.

**Сораулар:**

1) Нәрсә ул пәйгамбәрләргә бирелгән могҗизалар? Өч мисал китер?

2) Әүлияләрдә чагылган кәрамәтләр хакмы? Сүзеңне дәлилләә?

3) Мөэминнәрдән тыш башкаларда чагылган гадәти булмаган күренешләрнең хөкеме нинди?

# Ахирәттә Аллаһны күрү

وكانَ اللهُ تعالى خالقاً قبلَ أنْ يَخْلُقَ، ورازقاً قبلَ أنْ يَرزُقَ. واللهُ تعالى يُرَى في الآخرَةِ، ويَراهُ المؤمنونَ وهُم في الجنةِ بأعينِ رؤوسِهِم بلا تشبيهٍ ولا كيْفِيَّةٍ ولا يكونُ بينَهُ وبينَ خَلقِهِ مسافَةٌ

**Аллаһ тәгалә халикъ кылганчы ук — Халикъ (халикъ кылучы) иде, һәм ризыкландырганчы ук — Разикъ (ризыкландыручы) иде. Аллаһ тәгалә ахирәттә күренә һәм мөэминнәр Аны Җәннәттә бернинди охшатусыз вә «ничек» дигән сораусыз (ничексез) үзләренең маңгай күзләре белән күрәчәк, һәм Аның белән мәхлуклары арасында бернинди дә аралык булмый**

---

**Төшенчәләр:**

**Шәрех:** Дөреслектә, Аллаһ тәгалә әл-Халикъ исеменә мәхлукларны халикъ кылганчы ук лаек иде.

Имам Тахауий үзенең гакыйдә китабында болай диде: ***«Ул халикъ кылудан элек, Аның барча сыйфатлары бар иде һәм халикъ кылганнан соң Аңа моңа кадәр булмаган сыйфат өстәлмәде. Бу сыйфатлар элек-электән Аныкы булган кебек, киләчәктә дә мәңге Аныкы булып кала».*** Шулай ук, әйтте: ***«Ул юктан халикъ кылганнан соң гына «әл-Халикъ» исемен алмады, һәм мәхлукларны булдырганнан соң гына «әл-Бәрий» исемен алмады».*** Аллаһ тәгалә Ризыкландыручы исеменә, шулай ук, мәхлукларны ризыкландырганчы ук ия иде, һәм Аның исемнәре вә сыйфатлары элек-электән мәңге.

Аллаһ тәгалә ахирәттә күренә, һәм Аны мөэминнәр маңгай күзләре белән чынлыкта күрәләр. Ул ﷻ кәферләр хакында болай диде:

كَلَّا إِنَّهُمْ عَنْ رَبِّهِمْ يَوْمَئِذٍ لَمَحْجُوبُونَ

Мәгънәсе: **«Юк! Дөреслектә, алар ул Көнне Раббыларыннан пәрдәләнерләр»**[124]

Аллаһ тәгалә кәферләрнең Аннан пәрдәләнүләре турында хәбәр биргәч, мөэминнәрнең Аннан пәрдәсез икәнлекләрен һәм Аны күрәчәкләрен белдерде. Пәйгамбәребез ﷺ үзенең хәдисендә болай диде:

***— Дөреслектә, сез тулган ай төнендә айны күргән кебек, Кыямәт Көнендә Раббыгызны күрәчәксез, һәм сез Аны (ачык) күрүдә кысырыкланмаячаксыз»***[125]

Бу чын-хакыйкый күрү, һәм без аның мәгънәсен бетергән вә хакыйкатеннән чыгара торган тәэүилләр белән сөйләмибез, «ничек» дип тәгаенләмибез, мәхлукларны күргән кебек күрүгә охшатмыйбыз һәм җәһмияләр, мөгтәзиләләр вә башка адашкан төркемнәр күрүне инкяр иткән кебек, инкяр итмибез. Ә инде **«һәм Аның белән мәхлуклары арасында бернинди дә аралык булмый»** дигән сүз, Әбү Хәнифәгә ялган рәвештә япсарылган сүз булса кирәк. Чөнки, бу гыйбарә мөтәкәллимнәр сүзе, һәм ул, моңа кадәр ничеклекне инкяр итеп килгән, күрүнең ничеклеген аңлата. Бу мәсъәләдә сак булу тиешле! Имам Тахауий үзенең гакыйдә китабында болай диде: ***«Раббыбызның китабы тасвирлаганча, Җәннәт әһелләре өчен Аллаһны күрү бернинди чик-чолгаусыз һәм ничеклексез — хак:***

وُجُوهٌ يَوْمَئِذٍ نَاضِرَةٌ ۞ إِلَى رَبِّهَا نَاظِرَةٌ

Мәгънәсе: **«Кыямәт Көнендә кайбер йөзләр шатлыктан агарырлар. Ул йөзләр Раббыларына багарлар»**[126]

124 әл-Мутаффифин 15
125 Бохари 554
126 әл-Кыямәһ 22,23

**Кыскача нәтиҗә:**

Аллаһ тәгаләнең сыйфатлары элек-электән мәңге, һәм Ул Кыямәт Көнендә «ничек» дигән сораусыз чынлыкта да күзләр белән күрелә.

**Сораулар:**

1) Халикъ кылу һәм ризыкландыру сыйфатлары элек-электән мәнгеме, әллә яңадан барлыкка килгәнме?

2) Кыямәт Көнендә Аллаһ тәгаләне күрү чын-хакмы, әллә кинаямы?[127]

---

127 Метафора. туры мәгънәдә килмичә, читләтеп, күчмә мәгънәдә килгән сүз

# Иманның төшенчәсе

والإيمانُ هوَ الإقرارُ والتصديقُ. وإيمانُ أهلِ السماءِ والأرضِ لا يزيدُ ولا ينقُصُ من جِهَةِ الْمُؤمَنُ به وَيزيد وَينْقص من جِهَةِ الْيَقِين والتصديق والمؤمنون مستوون فِي الْإِيمَان والتوحيد متفاضلون فِي الأَعْمَال

**Иман, ул — тел белән икърарлау һәм йөрәк белән тәсдыйклау. Күкләр һәм җир әһелләренең иманнары ышана торган зат ягыннан караганда — артмый да, кимими дә, ә йәкыйн һәм тәсдыйк ягыннан караганда — арта һәм кими. Мөэминнәр иманда һәм тәүхидтә — бертигезләр, гамәлләрдә бер-берсеннән өстенлек белән аерылалар**

---

**Төшенчәләр: (Икърарлау)** Тану, әйтү. **(Тәсдыйклау)** Раслау **(Йәкыйн)** Катгый рәвештә инану, тәсдыйклау.

**Шәрех:** Монда, Әбү Хәнифә ﵁ иман мәсьәләсендә үзенең гакыйдәсен бәян итә. Аның аңлатуынча иман, ул — тел белән икърарлау вә калеб белән тәсдыйклау, һәм күкләр вә җир әһелләренең иманнары артмый да, кимими дә. Сөннәт әһелләренең имам Әгъзамнан башка күпчелегендә, иман ул — тел белән икърарлау, калеб белән тәсдыйклау һәм тән белән гамәл итү, ул арта вә кими. Пәйгамбәребез ﷺ әйтте:

***— Сез Бер Аллаһка иманның нәрсә икәнен беләсезме? ... Намаз торгызу, зәкәт бирү, Рамазанда ураза тоту һәм ганимәт малының биштән берен бүлеп чыгаруыгыз»[128]***

Иманның артуы һәм кимүе хакында Аллаһ тәгалә болай диде:

---

128 Бохари 53

وَيَزْدَادَ الَّذِينَ آمَنُوا إِيمَانًا

Мәгънәсе: **«һәм мөэминнәрнең иманнары артсын өчен»**[129]

Моңа кагылышлы дәлилләрнең хисап-саны юк, һәм бу мәсьәләдә Әбү Хәнифәнең ﵁ карашы күпчелек Сөннәт әһелләренең карашына туры килми. **«Ышана торган зат ягыннан караганда — артмый да, кимими дә»** дигән сүзләр, мөтәкәллимнәрнең яңалык булык кергән гыйбарәсе, чөнки сәләфләр мондый өлешкисәкчәләргә төрләндерү вә бүлүгә кермиләр иде, бәлки алар: **«Иман арта һәм кими, итагатьләр белән арта, гөнаһлар белән кими»** дип кенә әйтәләр иде. Шулай ук, мөэминнәрне иман буенча бертигезләү сүзләре дөрес булмаганлыгын билгеләп үтү кирәк, чөнки фәрештәләрнең, пәйгамбәрләрнең иманнары гомуми мөэминнәрнеке кебек түгел, бу мәсьәләдә игътибарлы булу тиешле.

**Кыскача нәтиҗә:**

Сөннәт әһелләрендә иман — икърарлау, тәсдыйклау һәм гамәл белән билгеләнә. Итагать белән арта, гөнаһлар белән кими һәм мөэминнәр иманда да, гамәлләрдә дә бер-берсеннән өстенлек белән аерылалар.

**Сораулар:**

1) Имам Әбү Хәнифәдә иман төшенчәсен әйтеп уз?

2) Сөннәт әһелләрендә иман төшенчәсен әйтеп уз?

3) Аларда иман артамы һәм кимиме? Аның артуы һәм кимүе ни сәбәпле була?

4) Мөэминнәр иманнарында бертигезме?

---

129 әл-Мүдәссир 31

## Ислам белән Иманның бәйләнеше

والاسلام هُوَ التَّسْلِيم والإنقياد لأوامر الله تَعَالَى فَمِن طَرِيق اللُّغَة فَرْق بَين الْإِسْلَام وَالْإِيمَان وَلَكِن لَا يكون إِيمَان بِلَا اسلام وَلَا يُوجد إِسْلَام بِلَا إِيمَان وهما كَالظهر مَعَ الْبَطن وَالدّين اسْم وَاقع على الْإِيمَان وَالْإِسْلَام والشرائع كلهَا

**Ислам, ул — Аллаһ тәгаләнең әмерләренә бирелү һәм буйсыну. Тел төшенчәсе ягыннан Ислам белән Иман арасында аерма бар, ләкин Исламсыз Иман булмый һәм Имансыз Ислам булмый, алар икесе дә** бер әйбернең **тышкы һәм эчке ягы кебек. Ә Дин — Иманга да, Исламга да һәм барча шәригатькә дә кулланыла торган исем**

---

**Төшенчәләр:**

**Шәрех:** Исламның мәгънәсе, Аллаһ тәгаләгә бирелү һәм Аның әмерләрен үтәп буйсыну. Ислам иң күркәм сыйфатта булсын өчен, мөселман Аның вә расүленең әмерләренә бернинди икеләнүсез буйсынырга тиеш. Тел ягыннан караганда Ислам белән Иман арасында аерма бар, чөнки бу яктан аларның асыл кулланылуы төрле. Ләкин, хакыйкатьтә, алар икесе бик нык бәйләнештә булган һәм бер әйбернең тышкы вә эчке ягы кебек бер-берсеннән аергысыз нәрсәләр. Әгәр дә алар аерым-аерым килсәләр, берсе аңлаткан нәрсәне — икесе дә аңлата һәм алар икесе дә икърарлау, тәсдыйклау һәм гамәл кылу мәгънәсендә була. Ләкин, әгәр алар бергә искә алынсалар, Ислам тышкы гамәлләргә , ә Иман эчке гамәлләргә хас була. Бу: **«Әгәр кушылсалар — аерылалар, ә аерылсалар — кушылалар»,** — дигән әйтемнең мәгънәсе була, һәм бу мәсьәләдә дөресе шушылай.

Әмма, Дин сүзенә килгәндә, ул Исламны да, Иманны да һәм барча Ислам шәригатен дә үз эченә ала. Чөнки пәйгамбәребез ﷺ Җибрил хәдисендә Исламны, Иманны һәм Ихсанны искә алып узганнан соң, Җибрил хакында: ***«Ул сезгә, сезнең динегезне өйрәтергә килде»,*** — диде, һәм боларның барысын да Дин дип атады. Моннан билгеле булганча, Дин сүзе барча шәригатьне үз эченә ала.

**Кыскача нәтиҗә:**

Ислам, ул — бирелү һәм буйсыну. Тел ягыннан караганда, Ислам Иманнан аерыла, ләкин хакыйкый мәгънәдә алар әгәр кушылсалар — аерылалар, ә аерылсалар — кушылалар. Дин исеме Исламны да, Иманны да һәм барча шәригатьне дә үз эченә ала.

**Сораулар:**

1) Нәрсә ул Ислам?

2) Ислам белән Иманның нинди бәйләнеше бар?

3) Нәрсә ул Дин?

# Аллаһ тәгаләгә мәгърифәтебез[130]

نَعْرِف الله تَعَالَى حق مَعْرفَته كَمَا وصف نَفسه فِي كِتَابه بِجَمِيع صِفَاته وَلَيْسَ يقدر أُحُدُ ان يعبد الله حق عِبَادَته كَمَا هُوَ أهل لَهُ وَلكنه يعبده بِأَمْره كَمَا امْرَهْ بكتابه وَسنة رَسُوله وَيَسْتَوِي الْمُؤْمِنُونَ كلهم فِي الْمعرفَة وَالْيَقِين والتوكل والمحبة وَالرضاء وَالْخَوْف والرجاء وَالْإِيمَان فِي ذَلِك ويتفاوتون فِيمَا دون الْإِيمَان فِي ذَلِك كُله

**Без Аллаһ тәгаләне, Ул Үзен Китабында сыйфатлаган барча сыйфатлары белән, Аны белергә тиешле белем белән беләбез. Беркем дә Аллаһка, Ул гыйбадәткә ия булганча, Аңа тиешлечә гыйбадәт кыла алмый. Ләкин Аңа, Ул Үзенең Китабында һәм расүленең сөннәтендә әмер иткәнчә, Аның әмере белән гыйбадәт кылалар. Мөэминнәр барысы да мәгърифәттә, йәкыйндә, тәвәккәллектә, мәхәббәттә, ризалыкта, куркуда, өметтә һәм боларга иманда бертигезләр. Ләкин Иманнан башка боларның барысында да аерылалар**

---

**Төшенчәләр:**

**Шәрех:** Мөэмин Аллаһ тәгаләне, Ул Үзен Китабында сыйфатлаган барча сыйфатлары вә исемнәре белән, Аны белергә тиешле белем белән белә һәм Аллаһ Үзеннән кире какканнарны, кире кага. Ләкин, бу мөэминнең Аңа тиешле рәвештә, Ул гыйбадәткә ия булганча гыйбадәт кылуы дигән сүз түгел. Чөнки, Аллаһ тәгаләнең хокукы зур, һәм мәхлук аларны тиешле рәвештә үтәп бетерә алмый. Бәлки, кеше аңа бирелгән күз нигъмәте өчен генә

130 Аны танып белүебез

җитмеш ел буена бертуктамыйча Аллаһка гыйбадәт кылса да, ул нигъмәт өчен шөкерен үтәп бетерә алмый.

Шуңа да, пәйгамбәребез ﷺ болай диде:

***— «Белегез! Дөреслектә, берегезне дә гамәлләре Җәннәткә кертмәячәк!»[131]***

Мөэмин, Раббысының рәхмәтенә ирешер өчен, Аллаһ тәгалә Үзенең Китабында һәм пәйгамбәренең ﷺ сөннәтендә кушканча гыйбадәт кыла.

**«Мөэминнәр барысы да иманның гамәлләреннән булган тәвәккәллектә, мәхәббәттә һәм башка нәрсәләрендә бертигез булган кебек, мәгъърифәттә һәм йәкыйндә дә бертигезләр, ә моннан тыш нәрсәләрдә аерылалар», —**дигән бу караш, әлбәттә һичшиксез дөрес түгел караш.

Хакыйкатьтә, мөэминнәр барча нәрсәләрдә дә аерылалар. Ничек инде пәйгамбәребезнең ﷺ йәкыйне белән, безнең йәкыйн бертигез булсын?! Аның ﷺ тәвәккәллеге белән, безнеке бер булсын?! Әлбәттә, болай була алмый! Мөэминнәр, һичшиксез, Иманда да, гамәлләрендә дә аерылалар.

**Кыскача нәтиҗә:**

Аллаһ тәгаләнең гыйбадәттә булган хокукын беркем дә үти алмый. Мөэминнәр Иманда да, гамәлләрендә дә бер-берсеннән аерылалар.

**Сораулар:**

1) Аллаһ тәгаләнең хакын тиешлечә берәрсе үти аламы?

2) Мөэминнәр Иманда һәм аның гамәлләрендә аерылалармы, әллә бертигезләрме?

---

131 Мөслим 2816

## Пәйгамбәрләрнең шәфәгате, Мизан һәм Хәүдъ

وَالله تَعَالَى متفضل على عباده، عَادل قد يُعْطي من الثَّوَاب أَضْعَاف مَا يستوجبه الْعَبْد تفضلا مِنْهُ، وَقد يُعَاقب على الذَّنب عدلا مِنْهُ، وَقد يعْفُو فضلا مِنْهُ وشفاعة الأَنْبِيَاء عَلَيْهِم السَّلَام حق، وشفاعة النَّبِي صلى الله عَلَيْهِ وَسلم للْمُؤْمنِين المذنبين وَلأَهل الْكَبَائِر مِنْهُم المستوجبين الْعقَاب حق ثَابت، وَوزن الأَعْمَال بالميزان يَوْم الْقِيَامَة حق، وحوض النَّبِي عَلَيْهِ الصَّلَاة وَالسَّلَام حق

**Аллаһ тәгалә колларына шәфкатьле, гадел. Ул Үзенең шәфктьлегеннән чыгып, кол лаек булганнан тыш аңа савабны күпкә күбрәк арттырып бирүе мөмкин. Шулай ук, Үзенең гаделлеге белән җәзаларга, һәм Үзенең шәфкатьлеге белән гафу итүе мөмкин. Пәйгамбәрләрнең ﴿عليهم السلام﴾ шәфагатьләре — хак, һәм пәйгмбәребезнең ﷺ гөнаһлы мөэминнәргә вә алар арасыннан җәзага лаек булган зур гөнаһ эшләүчеләргә шәфәгать кылуы — сабит хак. Кыямәт Көнендә гамәлләрнең Мизан белән үлчәнүе — хак, һәм пәйгамбәребезнең ﷺ Хәүды — хак**

---

**Төшенчәләр: (Шәфәгать)** Башканың хокукын үтәүне сорау. **(Мизан)** Үлчәү. **(Хәүдъ)** Сулык.

**Шәрех:** Дөреслектә, Аллаһ тәгалә кешеләргә Үзенең нигъмәте, ихсанлыгы, гафу итүе, йомшаклыгы белән шәфкатьле. Ул гадел һәм золым итми, бәлки колга савабны тиешлесеннән арттырып бирә. Аллаһ Коръәндә әйткәнчә, бу Аның юмартлыгы һәм мәрхәмәтлеге:

إِنَّ اللَّهَ لَا يَظْلِمُ مِثْقَالَ ذَرَّةٍ وَإِنْ تَكُ حَسَنَةً يُضَاعِفْهَا وَيُؤْتِ مِنْ لَدُنْهُ أَجْرًا عَظِيمًا

Мәгънәсе: **«Дөреслектә, Аллаһ кечкенә бөртек кадәр дә золым итми, әгәр дә изгелек булса, Ул аны арттыра һәм Үзеннән олуг әҗер-савап бирә»**[132]

Шулай ук, Аллаһ тәгалә гөнаһ өчен җәза кылуы мөмкин. Әгәр Ул шулай эшләсә, колның гөнаһ кылу сәбәпле җәзага лаек булганы өчен, Үзенең гаделлеге белән эшли. Аллаһ тәгалә гөнаһ кылучыны Үзенең шәфкате белән гафу итүе мөмкин, һәм бу зур нигъмәт өчен Ул шөкер итүгә лаек.

Кыямәт Көнендә пәйгамбәрләрнең ﷵ шәфәгать кылулары Коръән, Сөннәт һәм иҗъмәгъ белән сабит-ныгытылган. Аллаһ тәгалә әйтте:

مَنْ ذَا الَّذِي يَشْفَعُ عِنْدَهُ إِلَّا بِإِذْنِهِ

Мәгънәсе: **«Кем Аның каршысында, Аның рөхсәтеннән башка шәфәгать кыла алыр?»**[133]

Пәйгамбәрләрнең шәфәгать кылулары сабит, ләкин ул Аллаһ тәгаләнең рөхсәте белән генә була. Шулай ук, хәдистә риваять ителгәнчә, зур гөнаһ эшләп җәзага лаек булган мөселманнар өчен пәйгамбәребезнең ﷺ шәфәгать кылуы — хак: ***«Өммәтемнән зур гөнаһ эшләүчеләргә минем шәфәгатем була»***[134]***,*** — диде расүлебез.

Кыямәт Көнендә гамәлләрнең Мизан белән үлчәнүләре Коръән, Сөннәт һәм иҗъмәгъ белән сабит-ныгытылган. Шулай ук, пәйгамбәребезнең Хәүды да. Ул — зур сулык, буе бер айлык юл булса, киңлеге дә шулай ук бер айлык. Аның суы сөттән ак, балдан ләззәтлерәк, исе хушбуй кебек һәм аның янында булган, су эчә торган савытлар, күктәге йолдызлар кебек күп. Кем дә кем аннан бер йотым эчсә, беркайчан да сусамас. Ул Сулыкка Кыямәт Көнендә мөэминнәр килер, ә бидгать әһелләре вә адашканнар аннан читләштерелер[135].

132 ән-Нисә 40
133 әл-Бәкара 255
134 Әбү Дауыд 4739
135 Бохари 6579

## Җәннәт һәм Җәһәннәм бетмәячәкләр

وَالْقصاص فِيمَا بَين الْخُصُوم بِالْحَسَنَاتِ يَوْم الْقِيَامَة حق وَإِن لم تكن لَهُم الْحَسَنَات فَطرح السَّيِّئَات عَلَيْهِم حق جَائِز وَالْجنَّة وَالنَّار مخلوقتان لَا تفنيان أبدا، ولا تموت الحور العين أبدا، وَلَا يفنى عِقَاب الله تَعَالَى وثوابه سرمدا وَالله تَعَالَى يهدي من يَشَاء فضلا مِنْهُ ويضل من يَشَاء عدلا مِنْهُ وإضلاله خذلانه وَتَفْسِير الخذلان ان لَا يوفق العَبْد إِلَى مَا يرضاه وَهُوَ عدل مِنْهُ وَكَذَا عُقُوبَة المخذول على الْمعْصِيَة

**Дөреслектә, Кыямәт Көнендә, бәхәсләшүчеләр арасында изгелекләр белән исәп-хисап түләнүе — хак. Әгәр дә аларның изгелекләре булмаса, аларга явызлыклар йөкләнүе хак һәм мөмкин. Җәннәт һәм Җәһәннәм халикъ кылынганнар һәм беркайчан да бетмәячәкләр. Хур кызлары беркайчан да үлмәячәк. Аллаһ тәгаләнең җәзасы бетмәячәк, һәм савабы мәңге булачак. Аллаһ тәгалә Үзенең шәфкатьлеге белән теләгән кешесен һидәятле итә, һәм Үзенең гаделлеге белән теләгән кешесен адаштыра. Аны адаштыруы — тәүфыйктан калдыруы. Тәүфыйктан калдыруы дигәннең тәфсире; Үзе риза булган нәрсәгә колны муафыйк кылмауы, һәм бу Аның гаделлегеннән. Менә шулай, тәүфыйксызны гөнаһлары өчен җәзалауы**

---

**Төшенчәләр: (Тәүфыйк)** Аллаһ тәгалә Үзе яраткан вә риза була торган гамәлгә колын муафыйк итүе (шул гамәлгә аны туры китерүе)

**Шәрех:** Дөреслектә, Кыямәт Көнендә, бәхсләшүчеләр арасында рәнҗетүченең изгелекләреннән алып рәнҗетелгәнгә бирелеп исәп-хисап кылына. Әгәр дә аның изгелекләре булмаса, бу хакта хәдистә риваять

ителгәнчә, рәнҗетелгән затның явызлыкларыннан алынып рәнҗетүчегә йөкләнә: ***«Моңа аның изгелекләреннән бирелер, һәм моңа аның изгелекләреннән бирелер. Ә инде аларның хакларын кайтарып түләгәнче аның изгелекләре бетсә, ул вакытта рәнҗетелгәннәрнең гөнаһ-хаталары алынып аңа йөкләнер, һәм шуннан соң ул Утка ыргытылыр»[136].***

Бидгать әһелләренең карашларыннан аермалы буларак, Сөннәт әһелләре инануынча, Җәннәт белән Җәһәннәм халикъ кылынганнар һәм хәзерге көндә барлар вә беркайчан да бетмәячәкләр.

Хур кызлары да беркайчан да үлмичә, мәңге калучылар. Бәлки, Җәннәтләрнең мәңге булуы белән, алар да мәңге калучылар.

Шулай ук, Җәһәннәм, һәм аның газабы да мәңге бетмәячәк. Һәм Аллаһ тәгаләнең җәзасы да, савабы да даими-өзлексез, беркайчан да киселми вә туктамый.

Дөреслектә, Аллаһ тәгалә Үзенең шәфкатьлеге белән теләгән кешесен һидәятле итә, һәм гаделлеге белән теләгән кешесен адаштыра;

وَلَكِنْ يُضِلُّ مَنْ يَشَاءُ وَيَهْدِي مَنْ يَشَاءُ

Мәгънәсе: **«Ләкин, Ул кемне теләсә – адаштыра, һәм кемне теләсә – һидәятле итә»[137]**

Адаштырылу, ул — тәүфыйктан калдырылу, ягъни, Аллаһ тәгалә риза булган вә яраткан нәрсәне эшләүдән мәхрүм булу, гамәлнең Ул яраткан вә риза булган гамәлгә туры килмәүе. Әгәр дә Аллаһ тәгалә колны тәүфыйктан мәхрүм итсә, бу Аның гаделлегеннән, чөнки ул кол тәүфыйксызлыкка лаек. Шулай ук, тәүфыйксызның үз гөнаһлары өчен Аллаһның җәзасына дучар булуы, Аның гаделлегеннән.

136 Мөслим 2581
137 əн-Нәхел 93

**Кыскача нәтиҗә:**

Аллаһ тәгалә гөнаһ өчен җәзаларга яки гафу итәргә мөмкин. Ул шулай ук, изгелекләрне арттырып бирүе мөмкин. Пәйгамбәрләрнең шәфәгать кылулары хак вә дөрес, Мизан — хак, Хәүдъ — хак, мәхлукларның арасында исәп-хисап — хак, Җәннәт белән Җәһәннәм — хак вә бетмәячәкләр, шулай ук, тәүфыйксызның гөнаһлары өчен Аллаһның җәзасына дучар булуы, Аның гаделлегеннән.

**Сораулар:**

1) Пәйгамбәрләрнең عليه السلام шәфәгать кылулары хакында нинди караш?

2) Хәүдъ белән Мизан хакында нәрсә беләсең?

3) Кыямәт Көнендә мәхлукларның бер-берсе арасында исәп-хисап буламы?

4) Җәһәннәмнең бетүе вә мәңге калмауы дөресме?

# Кабер газабы

وَلَا يجوز أن نقُول: إِن الشَّيْطَان يسلب الْإِيمَانِ من العَبْد الْمُؤمن قهرا وجبرا وَلَكِن نقُول العَبْد يدع الْإِيمَان فَحِينَئِذٍ يسلبه مِنْهُ الشَّيْطَان

وسؤال مُنكر وَنَكِير حق كَائِن فِي الْقَبْر وإعادة الرّوح إِلَى الْجَسَد فِي قَبره حق وضغطة الْقَبْر وعذابه حق كَائِن للْكفَّار كلهم ولبعض عصاة الْمُؤمنِينَ حق جَائِز وكل شَيْء ذكره الْعلمَاء بِالْفَارِسِيَّةِ من صِفَاتِ الله عز اسْمه فَجَائِز القَوْل بِهِ سوى الْيَد بِالْفَارِسِيَّةِ وَيجوز أن يُقَال (بَرُوىء خُدَا) أي – عز وَجل – بِلَا تَشْبِيه وَلَا كَيْفِيَّة

**Безгә: Шәйтан мөэмин колның иманын көчләп вә мәҗбүриләп тартып ала, дип әйтергә ярамый, ләкин: кол иманны ташлагач, шул вакытта аннан аны шәйтан тартып ала, дип әйтәбез.**

**Мөнкәр белән Нәкирнең кабердә сорау алулары — хак, кабердә җанның тәнгә кайтуы — хак, барча кәферләр өчен һәм кайбер гөнаһлы мөселманнар өчен кабернең кысуы вә газабы — хак һәм мөмкин. Галимнәр фарсы телендә, кулдан башка Аллаһ тәгаләсыйфатларыннан искә алган барча нәрсәләрне дә — әйтергә мөмкин. Шулай ук, (Куәтле һәм Кодрәтле) ягъни — Гәззә вә Җәллә — дип, бернинди охшатусыз вә «ничек» дигән сораусыз әйтергә мөмкин**

---

**Төшенчәләр:**

**Шәрех:** Дөреслектә, Шәйтан мөэмин колның иманын көчләп вә мәҗбүриләп тартып ала алмый, ләкин әгәр дә кол иманыннан, йәкыйненнән һәм изге гамәл кылуыннан туктаса вә баш тартса, һәм шик-шөбһәләргә, гөнаһларга вә шуның кебек башка нәрсәләргә авышса, бу вакытта шәйтан аның иманын тартып ала.

Кабердә соралу һәм анда сорауны — ике фәрештә — Мөнкәр белән Нәкирнең алуына иман китерү, Сөннәт әһелләренең гакыйдә асылыннан булып тора. Алар хакында күп кенә дөрес хәдисләр билгеле булды, шуларның берсендә пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Мәет кабергә куелгач, аның янына Мөнкәр исемле һәм Нәкир исемле кап-кара, зәп-зәңгәр (күзле) ике фәрештә килер, һәм аннан: «Бу ират хакында нәрсә әйтә идең?», — дип сорарлар»[138].***

Дөреслектә, кабердә соралу өчен җанның тәнгә кайтуына Сөннәт әһелләре шиксез иман китерәләр, һәм бу дөрес хәдисләр белән ныгытылган хак. Шулай ук, кабернең кысуы вә газабы — хак. Болар барысы да кәферләр өчен булачак, һәм анда бернинди дә шик юк. Бу хакта Коръәннән һәм хәдисләрдән күп кенә дәлилләр билгеле. Шулай ук, билгеле булганча, Аллаһ тәгалә Үзе теләгән бәндәләрен гөнаһлары өчен кабердә газаплавы ихтимал.

Аннары имам Әбү Хәнифә галимнәрнең гарәп телендә булмаган фарсы яки башка телләрдә, Аллаһ тәгаләнең сыйфатларын искә алуларын мөмкин дип аңлатып китте. Иллә-мәгәр кул сыйфатын гына фарсы телендә әйтергә ярамаганлыгын белдерде, ләкин кеше, куәтле һәм кодрәтле сүзен яки башкасын фарсыча әйтсә, рөхсәт ителә.

---

138 эт-Тирмизи 1071

# Якынлык һәм ераклыкның мәгънәсе

وليسَ قربُ اللهِ تعالى ولا بُعدُهُ منْ طريقِ طولِ المسافةِ وقِصَرِها، ولكن على معنى الكِرامةِ والهوانِ، والمطيعُ قريبٌ منهُ بلا كيفٍ، والعاصي بعيدٌ عنهُ بلا كيفٍ. والقُربُ والبُعدُ والإقبالُ يقعُ على المنَاجي. وكذلكَ جِوارُهُ في الجنةِ، والوُقوفُ بينَ يَدَيهِ بلا كَيْفيَّة

**Аллаһ тәгаләнең якын булуы да, ерак булуы да араның озынлыгыннан һәм кыскалыгыннан билгеләнми, ләкин ул абруйлык һәм хурлык белән билгеләнә. Итагатьле Аңа «ничек» дигән сораусыз якын, ә итагатьсез Аннан «ничек» дигән сораусыз ерак. Якынлык, ераклык һәм якынлашу, яшерен мөраҗәгать итүчегә кагыла. Һәм шулай ук, Җәннәттә Аңа янәшә булу һәм Аның ике кул арасында басып тору, «ничек» дигән сораусыз**

---

**Төшенчәләр:**

**Шәрех:** Дөреслектә, Аллаһ тәгалә мөэминнәрдән Үзе теләгән бәндәсен якынайта, һәм Ул аңа юмартлык күрсәтеп абруйлый, ярдәм итә һәм туры юлга юнәлтә. Ә кәферләрдән һәм гөнаһ кылучылардан теләгән бәндәсен ерагайта, түбәнсетә, хур кыла һәм адаштыра. Болар һәммәсе дә «ничек» дигән сораусыз була. Шулай ук, Җәннәттә Аллаһка янәшә булу һәм Аның ике кулы арасында басып тору, болар барчасы да — хак, һәм без аларга «ничек» дигән сораусыз ышанабыз, чөнки «ничек» дигән сораугa керү, ул — адашу.

**Кыскача нәтиҗә:**

Кабердә соралу һәм андагы газаб — хак. Кол иманны ташласа, аны шәйтан тартып ала. Кул сыйфатыннан башка, Аллаһ тәгаләне фарсы телендә зикер итү рөхсәт ителә. Аллаһ тәгаләнең колларга якынаюы вә ерагаюы, аларның Аллаһның ике кулы арасында басып торулары һәм Аңа янәшә булулары, болар барчасы да «ничек» дигән сораусыз.

**Сораулар:**

1) Кабер сорауы һәм газабы турында нәрсә беләсең?

2) Шәйтан колның иманын беренче булып тартып ала аламы?

3) Аллаһ тәгаләгә якынаюның һәм Аннан ерагаюның ничеклеген тасвирларга мөмкинме?

# Коръән аятьләре арасында фазыйләтлелек хакында сүз

والقرءانُ منَـزَّلٌ على رسولِ اللهِ وهوِ في المُصْحَفِ مكتوبٌ، وءاياتُ القرءانِ كلُّهَا فِي معنى الكلامِ مستويةٌ في الفضيلةِ والعظَمَةِ. إلا أنَّ لبعضِهَا فضيلَةُ الذكرِ وفضيلَةُ المذكورِ مثلُ ءايةِ الكُرسي. لأنَّ المذكورَ فيها جلالُ اللهِ وعظمتُهُ وصِفَتُهُ، فاجتمعتْ فيها فضيلَتانِ: فضيلةُ الذكرِ، وفضيلةُ المذكورِ، ولبعضها فَضِيلَةِ الذّكر فَحسب مثل قصَّة الْكفَّار، وَلَيْسَ للمذكور فِيهَا فضل وهم الْكفَّار، وَكَذَلِك الأَسْمَاء وَالصِّفَات كلهَا مستوية فِي العظمة وَالْفضل لَا تفَاوت بَينهَا

**Коръән *Аллаһның* расүленә ﷺ иңдерелгән һәм ул мосхафларда язылган. Коръән аятьләре сүз мәгънәсе ягыннан фазыйләттә һәм олуглыкта барысы да бертигез, иллә-мәгәр аларның «аять әл-Көрси» кебек кайберләренең зикер кылу һәм (анда) зикер кылынганның фазыйләте бар. Чөнки, анда *Аллаһ* тәгаләнең кодрәте, бөеклеге һәм сыйфатлары зикер кылынган, һәм шуңа анда ике төрле фазыйләт тә бергә җыелган: зикер кылу фазыйләте һәм зикер кылынганның фазыйләте. Кайбер, кәферләр хакындагы хикәя ителгән аятьләрдә зикер кылу фазыйләте генә бар, ә анда зикер кылынган кәферләрнең бернинди фазыйләте дә юк. Исемнәр вә сыйфатлар барысы да олуглыкта һәм фазыйләттә бертигез, һәм алар арасында аерма юк**

---

**Төшенчәләр:**

**Шәрех:** *Аллаһ* тәгалә әйткәнчә, Коръән ул, *Аллаһ* расүленә ﷺ иңдерелгән *Аллаһның* сүзе:

إِنَّا أَنْزَلْنَا إِلَيْكَ الْكِتَابَ بِالْحَقِّ لِتَحْكُمَ بَيْنَ النَّاسِ بِمَا أَرَاكَ اللَّهُ

Мәгънәсе: **«Дөреслектә, Без сиңа Китапны кешеләрнең араларын Аллаһ күрсәткәнчә хөкем итү өчен хаклык белән иңдердек»**[139]

Барча галимнәрнең дә бердәм карашы буенча, нәкъ Аллаһ тәгаләнең сүзе булган Коръән, бездә булган мосхафларда язылган.

Коръән аятьләре Аллаһ тәгаләнең сүзе буларак, фазыйләт һәм олуглык буенча барысы да бертигез. Шулай да, «аять әл-Көрси» кебек кайбер аятьләрнең Аллаһ сүзе буларак һәм анда искә алынган нәрсәләрнең аерым өстенлекләре буларак, фазыйләтләре артыграк. «Аять әл-Көрси» ул — Аллаһ сүзе, шулай ук анда Аллаһ тәгаләнең кодрәте, бөеклеге вә башка сыйфатлары зикер ителә, һәм аның башкаларга караганда фазыйләте бар. Кәферләр искә алынган аятьләр кебек, кайбер аятьләрнең Аллаһ сүзе буларак зикер итү фазыйләтләре бар, ләкин анда искә алынганнарның фазыйләте юк. Ул аять Аллаһ тәгаләнең сүзе, ләкин анда искә алынган кәферләрнең бер фазыйләте дә юк.

Шулай ук, Аллаһның исемнәре вә сыйфатлары асылында фа-зыйләт һәм олуглык буенча бертигез, ләкин хәдистә риваять тиелгәнчә, бу исемнәр бер-берсеннән фазыйләтлерәк, дип әйтәбез: ***«Аллаһ исеме өч аятьтә олуграк...»***[140]. Алар, сүз кебек үк, бер-берсеннән фазыйләтлек белән аерылулары мөмкин. Аллаһу әгъләм.

**Кыскача нәтиҗә:**

Коръән аятьләре фазыйләт һәм олуглык буенча барысы да бертигез, илләмәгәр кайберләренең фазыйләте артыграк. Аллаһның исемнәре вә сыйфатлары фазыйләттә һәм олуглыкта бертигез, ләкин кайберләре өстенрәк.

**Сораулар:**

1) Коръән аятьләре өстенлектә аерылалармы?

2) Исемнәр вә сыйфатлар өстенлектә аерылалармы?

---

139 ән-Нисә 105

140 Сахих әл-Җәмигь әс-Сагыйрь 979

## Аллаһ расүленең ﷺ уллары һәм кызлары

وقاسِمٌ وطاهِرٌ وَإِبْرَاهِيمُ كَانُوا بني رَسُولِ اللهِ صلى الله عَلَيْهِ وَسلم، وَفَاطِمَةُ ورُقَيَّةُ وَزَيْنَبُ وَأُمُّ كُلْثُومَ كُنَّ جَمِيعًا بَنَاتِ رَسُولِ اللهِ صلى الله عَلَيْهِ وَسلم. وإذا أشْكل على الإنسانِ شيءٌ مِنْ دقَائِق علم التوحيدِ فإنَّهُ يَنْبَغِي لهُ أنْ يعتَقِدَ في الحالِ ما هوَ الصوابُ عندَ اللهِ تعالى، إلى أنْ يجِدَ عالماً فيسألُهُ، ولا يسعُهُ تأخيرُ الطَّلبِ، ولا يُعْذَرُ بالوقفِ فيهِ، ويَكفُرُ إنْ وَقفَ. وخَبَرُ المعراجِ حقٌّ، فمنْ ردَّهُ فهوَ مبتدِعٌ ضالٌّ

**Касим, Таһир һәм Ибраһим — Аллаһ расүленең ﷺ уллары иделәр, Фәтыймә, Рукаййә, Зәйнәб һәм Үммү Күлсүм — барысы да Аллаһ расүленең ﷺ кызлары иделәр. Әгәр дә кешегә тәүхид гыйлеменең нечкәлекләре мөшкелләнсә, ул очракта галимне табып аннан сораганчы Аллаһ тәгаләдә дөрес булганына ышанырга тиеш. Аңа җавап эзләүне соңлатырга ярамый, һәм аны эзләүдән туктау акланылмый, ә инде туктаса — көферлек кыла. Мигъраҗ хакындагы хәбәр — хак, һәм кем аны инкяр итсә, ул — адашучы бидгатьче була**

---

**Төшенчәләр: (Мөшкелләнсә)** авырайса. **(Нечкәлекләр)** Нечкә мәсьәләләр, аңлашылмаганары, авырлары. **(Мигъраҗ)** Күккә күтәрелү.

**Шәрех:** Пәйгамбәребезнең ﷺ уллары: Касим һәм расүлебез ﷺ аның белән куньяләнә иде; Таһир шулай ук аңа Тайиб һәм Габдуллаһ дип тә әйтелә иде, болар икесе дә пәйгамбәребезнең ﷺ Хәдиҗә радый Аллаһу ганһәдән булган уллары. Ибраһим, ул пәйгамбәребезнең ﷺ , Мисыр патшасы Мүкаукыйс бүләк иткән, Мәрия кәнизәктән туган улы. Расүлебезнең ﷺ башка уллары юк иде. Ләкин,

кызларга килгәндә: Гали бин Әбү Талибның ؓ хатыны һәм Хәсән белән Хөсәеннең ؓ анасы — Фәтыймә; Госман бин Гаффанның ؓ хатыны — Рукаййә; шулай ук Рукаййә вафат булганнан соң Госман бин Гаффан ؓ өйләнгән — Үммү Күлсүм һәм Әбү әл-Гас бин әр-Рабигьның ؓ хатыны — Зәйнәб; алар барчасы да пәйгамбәребезнең ﷺ Хәдиҗә радый Аллаһу ганһәдән булган кызлары.

Моннан соң, имам Әбү Хәнифә ؓ башка мәсьәләгә күчте. Әгәр дә кешегә тәүхиднең кайбер нечкә мәсьәләләрен аңларга авыр булса, ул бу мәсьәләнең Аллаһта дөрес дип саналганына ышанырга тиеш. Ягъни, бер төрле мәсьәләдә соралганнан соң авыр дип тапкан надан-җәһел кеше, галимне табып аннан сораганчы, үзенең нәфесен бу мәсьәлә Аллаһ тарафында шушылай дөрес дип тынычландырган кебек. Ләкин, аңа сораугa җавап эзләүне соңлатырга вә тыелырга ярамый.

Әмма, имам Әгъзамның: «**һәм аны эзләүдән туктау акланылмый»,** — дигән сүзләре, алдагы фикерләргә капма-каршы килә, иллә-мәгәр туктауның максаты хәбәрне яки әмерне кабул итүдә тукталу, инкяр итү дип аңлаганда гына. Бу чыннан да иманны юкка чыгару була.

Мигъраҗ хакындагы хәбәр — хак вә дөрес, һәм аны адашучы бидгатьчедән башка беркем дә инкяр итми.

**Кыскача нәтиҗә:**

Пәйгамбәребезнең ﷺ өч улы һәм дүрт кызы бар иде. Кеше үзенә авыр булган тәүхиднең нечкә мәсьәләләрендә бик тә сак булып, гыйлем ияләреннән сорарга тиеш. Мигъраҗ хакындагы хәбәргә иман китереп, аның хаклыгына инану тиешле.

**Сораулар:**

1) Расүлебезнең ﷺ улларын һәм кызларын әйтеп уз?

2) Берәр мәсьәлә авыр күренсә нишләргә кирәк?

# Кыямәтнең билгеләре

وَخُرُوج الدَّجَّال ويأجوج ومآجوج وطلوع الشَّمْس من مغْربهَا ونزول عِيسَى عَلَيْهِ السَّلَام مِنَ السَّمَاء وَسَائِر عَلامَات يَوْم الْقِيَامَةِ على مَا وَرَدَتْ بِهِ الأَخْبَارُ الصَّحِيحَةُ حَقٌّ كَائِنٌ وَاللهُ تَعَالَى يَهْدي مَنْ يَشَاء إِلَى صِرَاطٍ مُسْتَقِيم

**Дәҗҗәлнең һәм йәҗүҗ белән мәҗүҗнең чыгуы, кояшның мәгърибтән чыгуы, Гыйсәнең күктән төшүе һәм дөрес хәбәрләрдә килгәнчә барча Кыямәт Көненең билгеләре дә — хак вә булучы. Аллаһ тәгалә теләгән кемсәсен туры юлга сала**

---

**Төшенчәләр:**

**Шәрех:** Сөннәт әһелләре, Дәҗҗәлнең һәм йәҗүҗ белән мәҗүҗнең чыгуы, кояшның көнбатыштан чыгуы, Гыйсәнең күктән төшүе кебек барча Кыямәт Көне хакында Коръәндә вә Сөннәттә килгән билгеләргә дә иман китерәләр. Боларның барысын да пәйгамбәребез ﷺ үзенең хәдис-шәрифендә искә алып узды: ***«Сез Кыямәткә кадәр ун галәмәт күрмичә, ул булмаячак: Төтен, Дәҗҗәл, Хайван, Кояшның мәгърибтән чыгуы, Гыйсә бин Мәръямнең төшүе һәм Йәҗүҗ белән Мәҗүҗ»[141].*** Дөрес хәбәрләрдә килгән бу һәм башка галәмәтләр барчасы да хак вә булучы. Без боларның барсына да ышанып, тәсдыйкларга тиешлебез. Аллаһ тәгалә теләгән кемсәсен туры юлга сала.

---

141 Мөслим 2901

**Кыскача нәтиҗә:**

Сөннәт әһелләре Кыямәт Көне хакында Коръәндә вә Сөннәттә килгән барча билгеләргә дә иман китерәләр.

**Сораулар:**

1) Дөрес хәбәрләрдә килгән Кыямәт галәмәтләренә иман китерү тиешлеме?

2) Кыямәтнең кайбер галәмәтләрен әйтеп уз?

*Әлхәмдулилләһ! Аллаһның теләге вә ярдәме илә изге гамәлләр тәмамлана*

*Әй, Исламның һәм мөселманнарның Вәлие!*
*Синең белән очрашканга кадәр безне Исламда ныгыт!*

# ЭЧТӘЛЕК

Кереш сүз..............................................................3
Иманның нигезләре..................................................14
Аллаһ тәгаләнең берлеге..........................................30
Зат һәм фигыль сыйфатлары....................................33
Аллаһның сыйфатлары әзәлге..................................36
Коръән хакында сүз................................................39
Сыйфатлар хакында сүз..........................................50
Тәкъдир хакында сүз..............................................53
Аллаһ кешеләрне фитрый кылган хәләт....................56
Итагатьләр – Аллаһка сөйкемле, гөнаһлар – тәкъдир кылынган һәм алар Аллаһка сөйкемле түгел.................62
Пәйгамбәрләрнең мәгъсум булулары хакында сүз....65
Пәйгамбәр ﷺ хакында сүз.........................................67
Сахәбәләр арасында өстенлек...................................69
Мөселман гөнаһны хәләл кылмаса, аны эшләгән өчен генә көферлеккә чыгарылмый..........................................71
Сөннәт әһелләренең гакыйдәләреннән кайбер мәсьәләләр............................................................................74
Пәйгамбәрләрнең عليهم السلام могҗизалары, әүлияләрнең кәраматләре – хак....................................................81
Ахирәттә Аллаһны күрү............................................85
Иманның төшенчәсе.................................................88
Ислам белән Иманның бәйләнеше.............................90
Аллаһ тәгаләгә мәгърифәтебез...................................92
Пәйгамбәрләрнең шәфәгате, Мизан һәм Хәүдъ.........94
Җәннәт һәм Җәһәннәм бетмәячәкләр........................96

Кабер газабы....................................................................99
Якынлык һәм ераклыкның мәгънәсе........................101
Коръән аятьләре арасында фазыйләтлек................103
Аллаһ расүленең ﷺ уллары һәм кызлары..................105
Кыямәт билгеләре..........................................................107